# Казан утлары

11

НОЯБРЬ

1968

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

11

НОЯБРЬ
1968

## Бу санда:

Повесть, хикәя, шигырь

Ленин — бөек якташыбыз . . . . . . . . . . 3
Ялкынлы елларда . . . . . . . . . . . . 12
Л. ИХСАНОВА. Ана көндәлеге. Повесть . . . 15
ГӘРӘЙ РӘХИМ. Октябрь; Мин бит җирдә яңа кеше әле; Ник; Бер көн сиңа үлем килсә; Урам буйлап килә идем; Мәхәббәттә синең беләи; Без бары тик Җирне яраттык; Сез геп сынап карамагыз; Кайчагында; Ул мәҗлес. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 62
РӘСТӘМ МИНГАЛИМОВ. Сүзләр эзлим; Раузага; Без бер дөнья; Шулай кирәк; Хәтерләү; Сорама; Камышлы; Шигырьләрем белән сөйләшү. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 66
И. САЛАХОВ. Иртәнге очрашулар. Этюдлар . . . 70

Яшьләр иҗаты

М. ӘГЪЛӘМОВ. Еракка китеп кара. Шигырьләр . 77

Замандашыбыз

А. ХӘСӘНОВ. Йолдызлар сүнәр өчен кабынмый. Очерк . . . . . . . . . . . . . . . 85

Татарстанның 50 еллыгына

Р. ХӘЙРЕТДИНОВ. «Чулпан» — беренче совет газетасы . . . . . . . . . . . . . 91
М. ГАЙНУЛЛИН, М. ҺАДИЕВ. Шагыйрь һәм революционер . . . . . . . . . . . . . 95

Язучының күңел дәфтәреннән

И. ГАЗИ. Су шигърияте. Тирәкләр. Яңгыр астындагы мәхәббәт. Мунчада. Профессорда кунакта. . . . . . . . . . . . . . . 101

Батырлар китабына

М. ГЫЙМАДИЕВ. Утлар-сулар кичкән кеше . . 107

«Совет мәктәбе» журналына 50 ел

Ф. ИБРАҺИМОВ, Ф. ШӘРИФУЛЛИН. Данлы юл . 114

Публицистика

Б. ӘХМӘТОВ. Хәзерге гарәп дөньясында . . . 119

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Әдәби тәнкыйть

М. МӘҺДИЕВ. Халык әдәбиятыбызга бер караш 127

Түгәрәк өстәл янында

Г. БӘШИРОВ. Без кем идек, кем булдык! . . 141

Шагыйрьләр турында шагыйрь

Н. ДӘҮЛИ. Олы юлга чыкканда . . . . . . 146

Китап күзәтү

В. НУРУЛЛИН. Җир хуҗасы . . . . . . . 150
Р. ГӘРӘЙ. Җырлар аша сөйли күңелләр . . . 151

Елмаеп-көлеп кенә

Ә. ФАЗЫЛҖАНОВ. Алтын. Хикәя . . . . . 153
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . 156

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 15/IX-1968 ел. Басарга кул куелды 23/X-1968 ел. ПФ 15246.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 64 646 экз.
Заказ Д-1480. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1968 ел.




# ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘН, ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘН

**Назыйм Хикмәт,**
төрек шагыйре

## Владимир Ильич белән сөйләшү

Владимир Ильич!
Әгәр дә Л е н и н дисәм мин —
Үземә,
Кешеләргә
Һәм җиргә
Тирәнрәк ышана төшәм мин.
Куанычларым йолдызы калка минем,
Тынычлыкларым арта минем.

Владимир Ильич!
Исемеңне синең әйткән чагымда,
Кызыл роза булып,
Байраклар балкый тирә-ягымда,
Кызарып пешкән алмалар коелалар кебек,
Ак, кара һәм сары тәнле балалар
Алма чүпләргә җыелалар кебек.

Ленин дип әйтәм мин!
Һәм менә кырык елдан артык
Кесәмдә партбилет йөртәм,
Йөрәгемнең барлык хисләрен
Ленинга илтәм.
Аның белән киңәшләшергә килә м мин,
Ләкин алларында аның
Һич тә тез чүгәргә теләмим.

Ул — чиксез-чамасыз бөек зат,
Ләкин ул бөеклек мине дә зур итә.
Ул мина кул суза,
Ул мине күтәрә,
Йөрисе юлымда иң алдан ул үтә.

Владимир Ильич!
Мин беләм: мактауга каршы син,
Мәдхия шигырен син санламыйсың,
Һичкайчан, һичкайда үзеңне
Санам дип санамыйсың.

Ләкин үзеңнең Советлар Союзын,
Үз Польшаларыңны күргәндә,
Бөтен кешелек сине тыңларга килгәндә,
Үзеңнең туган көнеңдә,
Куанганым кебек минем дә,
Сокланганым кебек минем дә,
Син дә куаныр идең шулкадәр,
Син дә сокланыр идең шулкадәр,
Үзең, Владимир Ильич,
Ленин булмасаң әгәр!

## Степан Щипачов,

рус шагыйре

### Һәйкәл

Матур бакча. Бронза гәүдәле
Ленин тора бакча түрендә.
Гитлерчылар шушы һәйкәлне
Аудардылар көннең берендә.

Полковник шат. Бу эш янәсе
Күтәрәчәк данын аның да.
Кат-кат төшә фашист сурәткә
Җирдә яткан Ленин янында.

Гөне буе шашып эчте ул
Һәм мактанды шуның турында...
Ә таң аткач күреп каушады:
Ленин баскан шул ук урынга!

Гитлерчылар әле белмиләр:
Миналанды бакча юллары.
Партизаннар уза һөҗүмгә,—
Юл күрсәтә Ленин куллары.

**Антон Белевич,**

белорус шагыйре

## Ленинга хат

Мин хәтерлим, бөек Ленин, сезгә
Хат яздылар безнең авылдан.
Чакырдылар безнең туган якка,
Ул, дип, кинәт каты авырган.

Хат яздылар: — Шифа булыр сезгә
Безнең Неман, безнең җилебез.
Саулык теләп сезне һәркем көчәр,
Кадерлебез, безгә килегез!

Сезнең өчен яшел наратлыкта
Сагыз исе, ылыс исе бар.
Күңелләрнең сезне якын итеп
Кочар өчен якты хисе бар.

Умартачы әйтә: — Быел бал күп,
Кортлар быел шундый эреләр!
Шушы балны ашап бездә торса,
Юлбашчыбыз тизрәк терелер.

Ә итекче әйтә: — Шундый шәп күн
Табармын мин аңа итеккә,
Аяклары аның чыланмаслар
Бөтен сазлар аша үтеп тә!

Ә тегүче әйтә: — Бер тун тегеп
Бирер идем авыл халкыннан.
Ильичыбыз шуны киеп алса,
Курыкмас иде кышкы салкыннан.

Бер кыз әйтә: — Минем сүз дә керсен,
Башлап китим әле шуннан мин:
Бәйлим аңа җылы бияләйләр,
Мена дигән яхшы йоннан мин...

Тезелделәр сүзләр, тезелделәр,
Ак кәгазьгә күчеп йөрәктән.
Әйткән һәр сүз юлбашчыга китте,
Бөтенесе, димәк, кирәккән.

Хат язылды: — Үзең хәл алып кит,
Безнең хәлне кил дә белергә!
...Юлбашчыга шундый хат киткәнен
Онытасым юк гомер-гомергә.

**Зәки НУРИ тәрҗемәләре.**

**В. Сидоров,**

рус язучысы

# УЛЬЯНОВЛАР СЕМЬЯСЫНДА



Кич белән Ульяновларның өй эче шау-гөр килеп тора иде. Балалар гимназиядән күптән кайтканнар инде, дәресләрен дә әзерләп бетергәннәр. Хәзер инде ял итәргә, берәр партия шахмат уйнап алырга да була.

Шахмат уенын алар барысы да яраталар. Бигрәк тә Володя белән Саша һәм этиләре Илья Николаевич бик яратып, бирелеп уйныйлар. Кайчак алар беренчелеккә ярыш та оештыралар. Илья Николаевичка шахмат уйнаганда авыргарак туры килә: һәр фигураны уйлап йөрергә кирәк, чөнки Володя көчле уенчы.

Шимбә көннәрне өй эче аеруча җанлы була. Бу көнне балалар үзләренең атналык журналларын чыгаралар.

Журнал шимбә көннәрендә чыга, шуңа күрә аның исеме дә «Суботник» дип атала.

Журналның баш редакторы — Саша. Ул тышлыкка буяу карандашлары белән рәсем төшергән, зур-зур матур хәрефләр белән журналның исемен язып куйган.

Журналга балаларның барысы да катнаша. Һәр шимбә көн алар баш редакторга үзләренең хикәяләрен, табышмакларын, ребусларын бирәләр. Саша аларны алып, бер җирен дә үзгәртмичә, тышлык эченә салып куя.

Шулай итеп журнал әзер була.

Әле беренче класста гына укыса да, Володяның олылардан калышасы килми. Ул да гимназия турында, иптәшләре турында хикәяләр яза.

Менә алар бөтенесе дә эш бүлмәсенә җыелалар. Журналны беренче битеннән ахырына кадәр тантаналы бер төс белән укып чыгалар. Аннары ул кулдан-кулга күчә башлый. Саша энеләрен, сеңелләрен мәзәк итеп рәсемгә төшергән, шуларны көлә-көлә карыйлар.

Кичләрен эниләре рояль уйнарга утыра. Ульяновлар семьясында бөтен кеше музыка ярата иде. Мария Александровна балаларына яшьтән үк музыка өйрәтте.

Күңел кузгаткыч кайгылы көйләрне Володя яратмый, аның каравы, батырлык турында күтәренке рухлы, киң колачлы җырларны ул рәхәтләнеп җырлый иде.

Бигрәк тә ул «Безнең дингез — аулак дингез»не әйбәт җырлый иде.

Дулкыннар батыра алмый
Тик көчле кешеләрне...
Әйдә, кыю ишик, дуслар!
Дустым, давылда нык тор!
Безнең җилкәннәр ныктыр!

Җәй көннәрендә Ульяновлар семьясы Кокушкино авылына бара. Бу авыл текә ярлы елга буена утырган. Тирә-ягында борылмалы-борылмалы тирән-тирән чокырлар. Чокыр битләрендә куе кычыткан, крыжовник, карлыган куаклары, кура җиләге үсә. Чокырлар бетү белән урман башлана. Ульяновлар анда җиләк, гөмбә җыярга йөриләр.

Нинди күңелле урманда! Балалар шаяралар, куышып уйныйлар, кычкырып шигырь укыйлар. Алан уртасына учак ягып, бәрәңге, урман алмасы пешерәләр. Алмалары авызга алгысыз әче. Ашап карарга берсенең дә кыюлыгы җитми.

Кокушкинода Володя йокысыннан бик иртә уяна. Ул, тиз генә торып, ашык-пошык ашый да урамга йөгерә. Анда аны иптәшләре көтеп тора. Йөгерү-уйнау башлана. Лапта, әбәк-әбәк уеннарын да, юлбасар һәм атлы казак булып та уйныйлар. Атаман итеп гел Володяны куялар.

Бервакыт Володялар кәгазьдән зур очыргыч ясарга булалар. Аны бик тырышып, озаклап ябыштыралар. Очыргыч чыннан да зур, матур килеп чыга. Бу әкәмәтне карар өчен бөтен авыл баласы җыела. Барысы да болынга китәләр. Җил очыргычны күтәреп ала да биеккә-биеккә очырып менеп китә. Балалар «ура» кычкыралар. Һәркемнең җеп очын тотып карыйсы килә. Балалар аңа барысы берьюлы килеп ябышалар, һәм каты тартуга, очыргыч ватылып та китә.

Кич җиткәч, өйдә табын янында Володя үзенең башыннан кичкән кызыклы хәлләрне әнисе белән әтисенә сөйли. Көн буена шул чаклы күп хәлләр булган! Әгәр очыргыч ватылмаса, болытларга кадәр очып менгән булыр иде! Сүз кич буе сөйләшергә җитә.

**Н. Богданов,**

рус язучысы

## КЕШЕНЕҢ ЭЗЕ

Бервакыт Володя белән абыйсы Саша урманда адашалар. Гөмбәгә алданалар болар. Була бит шулай: бер гөмбәне өзеп саласың, икенчесе ерактан ук синең кәрзингә керәм дип тора. Менә шулай, каен гөмбәсеннән усакныкына, нарат гөмбәсеннән татлы гөмбәгә йөгерә-йөгерә, болар абыйлы-энеле урман эченә үк керәп китәләр.

Кәрзиннәрен тутыралар, кайтыр вакыт та җитә, ләкин кая таба кайтасын белмиләр.

Кычкырып та карыйлар — җавап бирүче юк.

Шундый хәл чыга калса, кайсысы адашса да урман каравылчысы өе янына килсен дип, алдан сүз куешкан булалар. Бөтен семьялары белән гөмбә җыярга килгән Ульяновлар атларын туарып үләнгә утларга җибәргәннәр, ә арбаларын шунда, урман аланында калдырган булалар. Урман каравылчысының хатынына самовар куеп торырга кушалар.

Менә барысы да чәй эчәргә җыелалар, ә ике гөмбәче юк.

Саша урман каравылчысы йортына тизрәк алып чыга торган турырак сукмакны эзли башлый. Урманда сукмак күп, тик кирәге генә табылмый.

Берсеннән китеп карыйлар: анысы аю сукмагы булып чыга: әнә кура чыбыкларын аю ничек сындырып бетергән.

Икенчесеннән китәләр — бусы пошиныкы: әнә бит ул агач кайрыларын куптарып, ботакларын сындырып ташлаган.

Җәнлек-киек эзеннән барсаң, эчкәре үк кереп китүең бар.

Саша кайгыга төшә.

Шунда Володя:

— Саша, Саша, менә кеше эзе! — дип, кинәт кычкырып җибәрә.

Чыннан да, абыйлы-энеле икәү килеп карасалар — сазламыкка әйләнә башлаган чишмә аша колгалар салынган. Бу эз фәкать кеше эзе генә булуы мөмкин, башка бер җан иясенекенә дә охшамаган.

Чишмә суы аша аякларын да чылатмыйча чыгалар да беленер-беленмәс яткан сукмактан алга атлыйлар болар.

Бу сукмактан күптән кемдер үткән. Эзләренә үлән үскән, ылыс коелган. Кеше калдырган билгеләр булмаса, алар күренмәс тә иде.

Әнә бер ботакта каен тузыннан ясалган тустаган эленеп тора, аста тар гына булып чишмә чылтырап ага, яхшы күңелле берәү аны әйбәтләп чистарткан. Арыган юлаучы шуннан салкын су эчсен дә юлын дәвам итсен, дигән.

Әнә бер кырыйда очлы башлы имән ботагы ята. Давыл вакытында сынып, ул сукмак өстендә эленеп калган булган. Кемдер аны кисеп алып читкә ыргыткан: юл өстендәге хәвефне алып ташлаган.

Саша әнә шул тамгаларга карана-карана атлый, үзе кашларын җыера. Әтисе-әнисе аларның юклыгын белеп хафага төшсәләр, әйбәт булмас бит. Хәер, нигә куркырга, тиздән алар каравылчы йортына килеп чыгарлар инде,— тик менә Володя гына кызганыч, кечкенә бит әле, арыр.

Саша артка борылып карый, урман эчендәге бөркүлектән кызарынган, әлсерәгән Володя елмаеп атлый бирә.

Саша гаҗәпләнеп:

— Нигә шатланасың? Нигә шул хәтле күңелең күтәрелеп китте? — ди.

— Ә сиңа шундый эздән баруы күңелле түгелмени? — дип сорый Володя.— Кара әле, бездән алда нинди яхшы кеше үткән. Үз юлында нихәтле изгелек калдырып киткән!

Саша як-ягына карана: әйе шул, барлык билгеләр сукмак салучының әйбәт кеше булуын әйтеп тора.

Алар кинәт туктап калалар, башларына бер уртак фикер килеп, йөзләре яктырып китә.

— Менә тормышыңны да шулай итеп яшәргә кирәк — изге эшләреңнең эзе кала барсын! — ди Саша.

Володя соңыннан бу сүзләрне, абыйсының васыяте итеп, күңел дәфтәренә язып куя.

**С. Антонов,**

рус язучысы

# ТӨН КУНА БАРУ



Кокушкино балалары Володяны төнлә ат сакларга алып барудан баш тарттылар...

— Юк, Володя, сорама да...— диде Гриша, юл тузанына тал чыбыгы белән сугып.

Башка малайлар да аның белән бер сүздә иде булса кирәк, эндәшмәделәр. Федя булып хәтта Федя да якламады: Володяны аеруча дус итә иде бит ул.

— Булмый... Сорама да....— диде Гриша һәм малайларны иярте китеп тә барды.

Иске картуз, киндер күлмәк, сәләмә балаклы озын ыштан кигән, чебиләп беткән ялан аяклы малайлар җыйнаулашып кайтып киттеләр. Ә Володя, Ушнә елгасының текә ярына урнашкан өйләренә таба борыласы урында, кузгалмыйча, алар артыннан карап калды.

Алар бергәләп кузна уйныйлар, балык тоталар, көймәдә йөриләр, куышып уйныйлар иде бит... Дус иделәр... Шулай да менә төнлә ат сакларга алып барасылары килмәде.

«Нигә алай? Әллә, чит кеше дип, минем өчен җавап бирүдән куркалармы?» — дип уйлады Володя.

Алай дисән, Ульяновлар семьясыннан берәүне дә Кокушкино крестьяннары чит итмиләр иде. Крестьяннар аның әтисен, әнисен бик ихтирам итәләр, Володя моны көн саен диярлек күреп тора. Билгеле, андый ихтирамны казана белергә дә кирәк.

«Төнлә мин куркып, бер-бер хәл булмагае дип шикләнгәннәрдер... Куркудан йөгереп китәрмен дә, тешен ыржайтып торган бүре авызына барып керермен, шуннан бүре мине урманга алып китәр, дигәннәрдер...» — дип, Володя үзсүзләнеп күзләрен кысты да елмаеп куйды.

Кичке аш ашаганнан соң, тәмам караңгы төшкәч, ул посып кына урамга чыкты.

Менә иске өй, ишек алдындагы флигель, бакча һәм коймалар артта калды. Кайдадыр еракта болын, анда малайлар, атлар бар, анда шүрәлеләр, су анасы һәм тагы әллә нәрсәләр бар, дип куркыныч әкиятләр сөйлиләр.

Салкын, тирә-юнь тып-тын. Куаклар әллә нинди зур бүрек кигән, кулларын як-якка җәйгән кеше кебек, яки арт аякларына басып, менә-менә синең өскә ташланырга торган аю сыман, яисә әкиятләрдә дә булмый торган коточкыч бер нәрсә булып күренәләр. Биредә, төнге болын уртасында, урман эчендә, чокырлар арасында, шулай да үзеңне ялгыз сизәсең икән.

Володя үзенең бераз шикләнгәнен сизде. Аяклары үзеннән-үзе әкренрәк атлый башлады.

Әллә нинди бүрекле юлбасарларга охшаган куак кинәт кул-ботакларын селкеп куйды: якынрак кил әле, кил, янәсе! Күрсәтермен мин сиңа күрмәгәннәреңне! Әнә теге куак артында, текәлебрәк карасаң, ике кеше посып тора... Әлбәттә, явыз бәндәләр инде алар, кеше җанын бер тиенгә куймый торган әдәмнәр... Моннан ерак түгел, күрше урманда, сай гына бер чокыр уртасыннан ага торган чишмә буенда кеше талаучылар урман каравылчысын үтереп ташлаганнар бит әле. Үтерүчеләр аны карт агачка бәйләп куйганнар, ул агач әле дә булса бар, тик корыган инде. Кайчан корыган, нигә корыды икән? Бәлки кайгыдандыр?

Ульяновларның балалары шул урманга барып йөриләр иде. Володя теге шомлы чишмә янына да барырга курыкмый иде. Ә менә хәзер кот очарлык ук булмаса да, ничектер куркыныч...

Алда уннарча чакрымга сузылган кап-караңгы әрәмәлек, урманнар...

Ичмасам менә бу тынлыгы булмасын иде: әйтерсең, дөньядагы бөтен җан иясе үлеп беткән һәм берәүнең дә синдә эше юк.

Алда, куаклар артында, зур гына бер карамчык күренде. Аның өстендә нәрсәдер ялтырап-ялтырап китә иде. Ул шәүләдән тагын берсе аерылды. Атлы арба икән... янышнан кеше атлый! Володя җиңел сулап куйды. Ул инде ат пошкыруын да ишетте. Тик менә ялтыраганы нәрсә икән соң аның? Володя арба өстендә яткан тәгәрмәчне, артта эленеп торган дегет чиләген күреп алды... Әһә! Дегет ялтырый икән. Кешесе дә күренә башлады, ул уң яктагы арт тәгәрмәч урынына кыстырган колгаты рәтләп маташа.

— Әй, акыллым, кил әле! — дип кычкырды бу кеше Володяга.

Володя арба янына йөгереп килде.

— Булыш әле, энекәш...— диде бу кеше һәм, Володяга әйбәтләп карап алгач, кинәт гаҗәпләнеп: — Ульянов малае түгелме соң син?! Владимир түгелме? — диде.

— Әйе, Владимир...

Володя аны белми иде. Бу агай Кокушкино кешесе түгел, берәр

күрше авылдан булса кирәк. Бераз яктырак булса, Володя аны таныган да булыр иде, бәлки.

— Мин сезне танымыйм, исемегезне дә белмим,— диде Володя.

— Ә мин сине менә мондый вакытыннан беләм,— дип, агай сөялләнеп беткән юан бармакларын, иелеп, җиргә үк тидерә язып күрсәтте.— Матвей атлы мин. Синең бабаң, мәрхүм, мине корсак чиреннән коткарып калган иде... Бернича тапкыр әле...

— Хәзер белдем инде. Ни булды соң болай?

— Арбам иске... Таудан төшкәндә чыдамады... Менә шуның белән җәфаланам. Бирерәк кил әле, Владимир! Мин арбаны күтәреп торырмын, син бу колганы урынына куй, балакаем... Булдыра алырсыңмы? Я, бир әле кулыңны.

Зур сакаллы, таза гәүдәле, кырык биш яшьләрендәге бу кеше Володяның кулын тотты да арба астына тыкты:

— Менә колганың очы шунда. Таптыңмы? — диде агай, колганы капшатып.

— Таптым...— диде Володя һәм бу кыска сүзне яратып: — Таптым,— дип, тагын кабатлады.

— Менә монда мин аны бау белән каты итеп кысып бәйләп куйган идем, нык иттереп... Сизәсеңме?

— Сизәм, сизәм, Матвей агай!

— Колгасы ычкына торган түгел. Тик очын менә монда кертмәсәң, читкә авышуы бар,— дип, Матвей агай Володяга очны кая кертергә икәнен күрсәтте.— Сизәсеңме?

— Сизәм, Матвей агай!

— Менә шулай. Хәзер инде мин арбаны күтәреп торыйм, ә син кертергә тырыш.

Матвей учына төкереп, кулларын ышкып алды да: «Раз-два! Взяли!!» — дип, арбаның артын җиңел генә күтәрде.

Володя бөтен көче белән колганың очына ябышты һәм бераздан:

— Булды, Матвей агай! Төшерегез! — диде.

Матвей арбаны төшереп, булдымы икән дип тикшереп караганнан соң, хуплап:

— Нәкъ эзенә басkансың! Менә хәзер тәмәке кабызып җибәрергә була,— диде.

Ул чакма ташын сугып, тәмәкесен кабызды да:

— Ә син болай кая барасың соң, Владимир? Төн житкән ич инде! — диде.

Тавыклар кунаклаганда ук йокларга ятмый торган тынгысыз кешеләрне яратканга булса кирәк, Матвей агай болай дип шаярып, хуплап әйтә куйды:

— Әллә йөреп керергә дип чыктыңмы? Йөрердәй-карардай нәрсәләр бар шул: кичен бөтен нәрсә икенче төрле күренә, көндезге кебек түгел. Иртә таңда да бөтен нәрсә башкача була. Менә шулай, бу тормышта өч төрле яшисең булып чыга. Шулай да кая җыендың соң, Владимир?

— Малайлар янына ат сакларга барам...

— У-у! Бик хуп,— диде Матвей ага.— Мин дә төнлә ат сакларга барырга ярата идем... Алары бүгенгедәй хәтеремдә, ә менә шуннан соңгы хәлләрнең күбесен онытып бетергәнмен... Я ярый, утыр алайса, алып барыйм.

— Рәхмәт, мин җәяү генә барам,— диде Володя.

— Сиңа кай якка барырга кирәк соң? Кокушкинонықылар гадәттә атларын менә бу чокырлардан ары көтәләр... Ә сиңа кай якка?

— Шунда, Матвей агай. Нәкъ эзенә бастың!

Матвей елмаеп куйды.

— «Нәкъ эзенә» дисеңме?! Миңа әллә ни әйләнеч түгел. Юлдан

бераз борылам да сине малайлар янына илтеп куям. Утыр! Утыр! Кеше белән бергә күңеллерәк була ул.

— Кеше белән күңеллерәктер анысы,— диде Володя, аның сүзен җөпләп,— шулай да мин җәяү генә барам.

Матвей гаҗәпләнеп кулларын җәеп җибәрде.

— Нигә? Бурычлы булып калырмын дисеңмени? Мин бит сине булышуың өчен илтәм, мин барыбер сиңа бурычлы. Әйдә киттек!

— Рәхмәт. Бик риза булыр идем дә, ләкин миңа китәргә кирәк — бер ялгызым барырга кирәк.

Матвей агай гаҗәпләнеп:

— О-о! — дип кенә әйтә алды.

Шуннан соң Володя малайларның аны төнлә ат сакларга алып бармауларын һәм шуңа төнлә берүзе генә барырга чыкканын сөйләп бирде.

Матвей агай, малайның бу эшен хуплап, зур авыр кулы белән сүзсез генә аның җилкәсеннән каккалап алды. Аннары арбасына утырды да аның дилбегәсен кагып, китеп барды.

Володя тагын ялгызы калды.

Уң якта да — куаклар, сулда да — куаклар, каеннар. Алда чокырлар, урман. Алар барысы шомлы, кап-караңгы.

Володя еракта тәгәрмәч шыгырдавы, туры атның пошкырган тавышы тынганын көтеп торды да алга таба атлады.

Малайлар учак тирәсенә чикмәннәрен җәеп ятканнар. Якында гына, муеннарында кыңгырауларын ялкау гына чыңгылдатып, тышаулы атлар утлап йөри иде.

Башта янган учакка карап торып, аннары күк йөзенә күз салсаң, бер мәл йолдызларны күреп булмый. Күккә учак янынннан торып карасаң да йолдызлар күренми. Гриша уттан читкә борылып карады да:

— Кара әле! — дип кычкырып җибәрде.

Ул үзләренә таба нинди шәүлә килүен озак вакыт аера алмый торды.

Ниһаять, ул танып алып:

— Володя! Ялгызыңмы? Бер үзеңме? — дип шатланып сорады.

— Ялгызым. Бер үзем,— дип җавап бирде Володя.

Р. САБИРОВ
тәрҗемәләре.

# ЯКЫНЛЫ ЕЛЛАРДА

*Даhи юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССРга 50 ел тулу көннәренә әзерлек уңае белән, Татарстан китап нәшрияты «Укучының музыкаль альбомы» дигән ноталы җырлар сериясе бастырып чыгарырга әзерли. Шул сериядән беренче китап «Революцион җырлар» исеме белән чыгачак. Анда Октябрь социалистик революциясенә кадәр һәм революция елларында, шулай ук граждannар сугышы чорында чыккан рус һәм татар җырлары үрнәкләре биреләчәк.*

*Без шул беренче китапка керәчәк рус җырларының берничә тәрҗемәсе белән таныштырабыз.*

## Кара козгын

Кара козгын, кара козгын,
Баш очымда чуалма,
Өметләнмә, кара азгын,
Сиңа табыш булалмам.

Тырнагымны батырам, дип,
Табышым, дип, шушында,
Ерткаларга тотынам, дип,
Очма башым очында.

Бүләк яулык туктатмасмы
Авыр ярам каннарын,
Әлек ярам тынычлансын,
Сөйләшербез аннары.

Очып кит тә туган якка,
Сөйлә, белсен әнкәем,
Туган илен яклап сакта
Ауды, диген, бәбкәең.

Канлы яулык барып җитсен
Минем сөйгән ярыма;
Инде башканы яр итсен,
Кайта алмыйм янына.

Кәләш тапты миңа кылыч,
Өйләндерде үлемгә,
Борчылмасын — миңа тыныч
Кырда, куак төбендә.

Кара козгын, ташлан инде,
Дошман угы йөрәктә.
Корбан булдым яклап илне,
Соңгы хәтәр көрәштә.

## Озату[1]

Газиз әнкәй зур юлга озатканда,
Шомландылар кардәшләр минем янда.

«Ашыгасың, егеткәй, кай якларга?
Юкка йөрмә, китмә син еракларга!

Кызыл гаскәргә көчләр киләчәкләр,
Большевиклар синсез дә җиңәчәкләр.

Үзең теләп саласың башың утка?
Югалырсың, Ванюша, бер дә юкка.

Әнкәң чәче кайгыдан гел агара,
Эшләр көтә, син бераз уйлап кара!

Тормыш көйле, эшебез бик яхшырды,
Дәүләт безгә никадәр җир тапшырды.

Яңа тормыш гөрли бит һәр тирәндә,
Китеп йөрмә, авылда кал өйлән дә!

Килен белән яшәрсез эшләп кенә!..»
Әнием баш идем иплән кенә.

Башны иеп әйттем һәр туганыма:
«Шыңшып-шыңшып тимәгез сез җаныма!

Гамьсез булса сезнеңчә һәрбер кеше,
Шәп булырмы Россия, Мәскәү эше?

Бетәр иде кояшлы бәхет, шатлык,
Китәр иде безнең җир һәм азатлык!»

## Яшь бөркет

Яшь бөркет, яшь бөркет, кояштан югары
Оч та далага күз ташла,
Корбан булды чибәр егетләрнең бары,
Кем дә юк, бер миннән башка.

Яшь бөркет, яшь бөркет, канатыңны җәй дә
Бөтен дөньяны син капла.
Үлем турында уйлыйсы килми бер дә,
Яшь кенә бер малай чакта.

Яшь бөркет, яшь бөркет, дошманның туплары
Кырды яшьләрне бер тауда.
Мине яшь бөркет дип йөрттеләр дусларым,
Бөркет диде дошман яуда.

---

[1] Шагыйрь Демьян Бедный шигыре.

Яшь бөркет, яшь бөркет, безгә очып бар да
Әниемә әйт, туганым
Үлмәс, диген, яуда төзәп атсалар да,—
Күңелкәен юат аның.

Яшь бөркет, яшь бөркет, гадел безнең эшләр,
Утлар күренә далада,
Алмашка килә комсомол — яшь бөркетләр,
Тормыш башлана яңадан.

Яшь бөркет, яшь бөркет, яна эшелоннар
Җиңү юлларын кабатлый,
Бөркетләр илендә яшьләр — миллионнар,
Яшьләрне бөтен ил мактый.

## Атлы гаскәр

Кояш чыгып якты көн килеп җитә,
Фронт буйлатып кавалерия үтә.

Җитез атлар ут уйната тоякта,
Үткен кылычлар ялтырый кояшта.

Командирлар үзебезнең егетләр,
Барысы да батырлар, ут кебекләр.

Алар белән җиңү яулап алабыз,
Утлар аша һаман алга барабыз.

Атлы гаскәрнең җиңү даны гөрләр,
Ак генерал да сызганын хәтерләр.

Һаман сафта, уяу сакта илдә без,
Совет илен һичкемгә дә бирмәбез!

**Мөхәммәт САДРИ** тәрҗемәләре.

Лəбибə Ихсанова

# АНА КӨНДƏЛЕГЕ

Повесть

## I



Рөстəм, Казанка буеннан əйлəнеп менгəч, Светлананы автобуска утыртты да өйлəренə йөгерде. Анын күтəренке күңелен əбисенен шелтəле каршылавы да бозмады. Карлы өс-башын салмыйча, сумкасын да куймыйча, туп-туры кухняга килеп керде дə өстəлдəн зур гына кабым икмəк тешлəп алды, плитə өстендə кайнап утырган мискинең өстен ачып карады. Гомере буе аш-су тирəсендə кайнашкан, оныгын һəм кызын тəрбиялəүдəн башка шатлыгы калмаган йомры гəүдəле бу карчык Рөстəмне кухнядан залга куды.

— Бу нинди əдəпсезлек. Сал өслəреңне. Утыр. Хəзер ашарга бирəм.

— Əй, əби, карыным ачты да соң.

— Пөрмəссең шул гомер. Иптəшлəрең сабактан кайтканга əллə ни гомер инде. Əниеңə əйтермен əле менə.

Аның бар белгəне шул инде. Оныгы чиктəн тыш шаярып китсə дə, дəреслəрен əзерлəми башласа да, сүз тыңламаса да, əнисеңə əйтермен əле, дип кенə куркыта. Бер кайчан да əйтми тагын үзе. Киресенчə, я мəктəптəн, я урамнан улы турында берəр нəрсə ишетеп кайткан əнисе малайны ачулана башласа, шул əбисе үк арага керə:

— Я инде, малай кеше шаярмый булмас. Кəефеңне бозма. Син киткəч, үзем иплəп кенə сөйлəшермен əле.

Шуның белəн малайның баш очына җыела башлаган болыт та тарала. Хəер, мондый көннəр сирəк була аларда. Əбисе ничек булса да өйдə тавыш чыгармаска тырыша. Малайның əнисе рəтлəп өйдə тормый, башы эштəн кайтып керми. Кай көннəрне аяк өстеннəн генə капкалап ала да əле бер җиргə, əле икенче җиргə чыгып йөгерə. Ир урынына да, хатын урынына да үзең калгач, шулай икəн ул дип, Хəдичə əби кызы артыннан кызганып карап кала.

Кайвакытларда əнисе Рөстəм янына килеп утыра. Утыра да сораштыра башлый:

— Рөстəм, синең хəллəрең ничек?

— Норма-льно! — ди малай.

— Сиңа бар да нормально инде. Икеле алсаң, шул житкəн дип уйлыйсың. Белеп тор, малай, мəктəбеңə барып бер тикшерəм əле мин синең укуыңны. Отметкаларыңның рəте булмаса, кара аны.

— Бүтəннəр дə өчкə укый əле. Əллə алардан артыкмы мин?

— Ә мин синең яхшырак укуыңны телим. Син әйбәт үссен дип, син рәхәт яшәсен дип, мин барын да эшлим бит. Шуның өчен генә дә син тырышып укырга тиеш идең.

— Ә мин тырышам.

— Бик тырышканың күренми шул...

Шулай ди ул. Әмма улы белән бәхәскә кереп, артык сүз көрәштерерлек көче юк үзенең. Санитар врачына болай да көне буе бик күп кешеләр белән сөйләшергә, бәхәсләшергә, кайвакытларда ут чыгарып ачуланышырга да туры килә. Шуның өчен ул өйдәге тынычлыкны бик тансыклап кайта, әз генә бәхәс кузгалса да, кәефе кырыла. Андый чакта һич урынсызга кычкырып ташлый.

Сәгать тугызлар бардыр инде. Әнисе һаман кайтмый да кайтмый. Тагын берәр җыелыш булгандыр әле. Ә Рөстәмнең бүген аны тизрәк кайтарасы килә. Ә ни өчен? Ансын ул үзе дә белми. Күңелендәге шатлыгын сөйләр өченме? Юк, Светлананы яратуы турында Рөстәм аңар әйтә алмас иде, ахры. Әнисен ул бик яратса да, нигәдер эчке тойгыларын аңар сиздерергә ояла иде. Әгәр этисе, мөнә шушында, үзләре белән бергә яшәсә, сөйли алыр иде микән ул аңар? Рөстәмнең этисен бик кечкенә чагында гына күргәне бар. Соңгы елларга кадәр ул аны ничектер исенә дә төшермәде, сагынмады да. Ә менә иске йортта торган чакта аларның Хәсән исемле күршеләре бар иде. Ул әле хәзер дә Рөстәмнәр мәктәбендә укыта. Шул Хәсән абыйсына бик ияләнгән иде ул. Аның өенә кергәләп йөри иде. Кайвакытларда Хәсән абыйсының маҗаралы сәяхәтләр турында сөйләгән сүзләрен тыңлый-тыңлый төн житкерә. Шул вакытны әбисе эзләп, артыннан керсә, Рөстәм эченнән генә, бу Хәсән абый нигә минем этием түгел икән? Ул безнең белән бергә торса, мин аның сөйләгәннәрен туйганчы тыңлар идем, дип уйлап куя иде. Хәзер менә әллә ничек, ара ераклашкач, барып йөрүе уңайсыз кебек. Ә мәктәптә элеккечә озак итеп сөйләшеп торганнары юк. Эх, менә хәзер, шушы минутта, өйләренә килеп керсен икән ул. Рөстәм аңа Светаны яратуы турында сөйләп бирер иде. Сөйли алыр иде микән? Яратуны бит бер кешегә дә сиздермиләр, сер итеп саклыйлар, ди. Җитмәсә, укытучы кеше бит әле ул. Андый сүзне укытучыга сөйләве оят. Ә булса соң? Хәсән абыйсын Рөстәм этисе кебек күрә иде бит. Шулай булгач, берсен дә яшермичә сөйләшер кешесе дә Хәсән абыйсы бит инде. Ә мәхәббәт турында ул матур итеп сөйли белә. Быел укулар башлангач та алар класслары белән бергәләп, «Пигмалион» спектаклен карап кайтканнар иде. Икенче көнне әсәрнең исеме турында бәхәс купты. Автор аны ни өчен «Пигмалион» дип атаган? Һәм шунда Хәсән абыйлары аларга борынгы бер легенданы сөйләп бирде.

Бик борынгы заманнарда Пигмалион исемле Кипр патшасы булган. Бик шәп скульптор да булган икән ул. Искиткеч гүзәл Галатея сынын ясаган, ди бу кеше. Һәм үзе ясаган Галатеяга акылдан шашар дәрәҗәдә гашыйк булган, ди. Шулкадәр яраткан ул аны, янган утларга сикереп төшкәндәй газапланган. Бу хәлне күргән мәхәббәт алласы Афродита, Пигмалионны кызганып, сынга җан иңдергән, һәм салкын мәрмәр таш бик матур бер кызга әйләнгән. Соңыннан ул Пигмалионның хатыны булган, ди.

Менә бу мәхәббәт, ичмасам. Салкын ташларга җан иңдерерлек көчле мәхәббәт! Рөстәм дә бит Светлананы, Светаны шулай ярата. Тик аның зәңгәр күзләре һаман салкын, ярату юк аларда. Ул күзләр Рөстәмне үртиләр һәм аның саен үзләренә ныграк тарталар. Эх, Афродита, нигә син юк икән безнең заманда! Таштай салкын бәгырьле шул кызга әз генә җылыңны өрсәң икән. Зәңгәр күл төсле шул гамьсез күзләрдә дә аз гына кояш нуры чагылыр иде, бәлки. Ул нурлар егет күңелен җылытыр иде бераз. Аһ, булса икән шундый көч!

Әле күптән түгел генә шулай уйлый, шундый өзгәләнә иде Рөстәм. Әллә чынлап та бар микән ул мәхәббәт алласы? Әйт, ишеттеңме әллә син йөрәк тавышын, Афродита. Менә бүген, Казанка буендагы әче салкында да Рөстәм аның күзләрендә синең җылыңны күрде. Чәчәкләр генә җыеп йөрердәй нәфис бармаклар ана кагылды. Өшеп ташка әйләнә язган бит алмаларында аның утлы сулышын сизде. Җүләр дә инде бу Рөстәм. Тотарга иде шунда аның туңган кулларын, сулышы белән җылытырга иде ул бармакларны.

«Света-Светка, кулларың туңган идеме, әйт, минем өчен туңдымы ул матур бармакларың? Ә мин тагын белмәдем дә. Менә хәзер мин сиңа шигырь язам. Кояшка тиңләп языйммы үзеңне? Шагыйрьләр гомер-гомергә үзләренең сөйгәннәрен кояшка тиңләп язганнар. Әгәр тауга охшатсам мин сине? Тау биек, ләкин тәкәббер ул, салкын һәм сүзсез. Әллә көчле, шаулы ташкын димме үзеңне? Ташкындай ярсу күңелең дигән юлларны укыганым бар минем. Юк, чит кеше сүзләрен әйтәсем килми минем сиңа. Үземнекен, бары тик үзем генә уйлап тапкан сүзләрне ишеттерәсем килә, Светка! Ишетәсеңме, үземнең сүзләремне генә!»

Утырды да утырды ул бүген өстәл артында. Әбисе бүлмә ишеген ачып карады да шыпырт кына кире китте:

— Рәхмәт төшкере, каян килгән бу тырышлык. Дәресләрен гомер шулай озак караганы юк иде. Күзем тия күрмәсен тагын.

## II

Фәһимә ул көнне бик соң кайтты. Эше беткәч, депутатлар бүлмәсендә сайлаучылар кабул итте. Кайбер көнне йомыш белән килүчеләр бөтенләй булмый. Ә бүген, үч иткәндәй, берсе артлы берсе кереп кенә торды. Ә бит аның иртәнге самолет белән Мөслимгә очасы бар. Бүген генә иртәрәк кайта алса, улы Рөстәмгә әйтеп калдырасы сүзләре дә күп иде. Бигрәк көтелмәгән һәм кинәт кенә җыенып чыгып китәргә туры килгән командировка булды ла бу. Бармыйм дип баш тартсаң да уңайсыз. Тотып күрсәтерлек зур гына сәбәбең дә булмагач. Ярый әле: өйдә әнисе бар. Фәһимәнең бар ышанганы, таянган кешесе шул инде. Бөтенесен дә ул рәтләп тора. Рөстәмне карап үстерүче дә шул әнисе булды. Тугызынчы класска җитсә дә, бала бит әле. Һаман күз-колак булу кирәк, ди әнисе. Дөресе дә шулай. Менә Фәһимә аны рәтләп күрмичә дә китеп барачак. Вакыты булып, мәктәпкә кереп чыкса, өйдә тора алмыйм, Рөстәмне күздән җибәрә күрмәгез, мөмкин булса, дәресләрен еш-рак сорагыз, дип әйтә алса, күңеле тынычланып китәр иде дә бит.

Хәер, мәктәпкә бармыйча да бу мәсьәләне хәл итү җае чыккан иде чыгуын. Әмма кешеләр барысы да Фәһимә кебек түгел шул. Ялының да, вакытының да кадерен беләләр.

...Депутатлар бүлмәсен бикләп куйгач, ул үзенә килгән сайлаучыларның өйләренә барып килергә булды. Командировкадан кайтканчы атна-ун көн үтәчәк, аннан соң да әллә вакыт була, әллә юк әле. Ә бит ул кешеләр җавап көтә. Көткән кешегә аның көне дә күп. Югалган кич югалган, бер-ике сәгатьтә әйләнеп чыгарга була, дип киткән иде, кергән өйләренең берсендә Рөстәмнең класс җитәкчесен очратты.

Култыксалары сырлап ясалган сап-сары буяулы борынгы баскычтан югары катка менгәндә, бу квартирның хуҗасын күз алдына китереп, елмаеп куйды. Бөдрәләткән сары чәчле, зәңгәрләнеп торган зәһәр күзле бу хатын үзенең йомышы белән дә, килеш-килбәте белән дә ничектер күңел кайтаргыч һәм кызганыч бер тойгы калдырган иде аңарда. Ә бит синең каршыңа йомыш белән нинди генә кеше килсә дә, тыңларга, аңлатырга, юатырга, эшли алырдаен эшләргә кирәк. Галимә исемле бу

хатынның тавышы Фәһимәнең колак төбендә әле дә яңгырап тора сыман:

— Үләрсең гарьләнеп, мәчеләре ишек төбемә килеп балалаган бит,— дип, күршеләрен тиргәде ул.— Теләсә кая куегыз бу шакшыларыгызны дип көн дә әйттем. Мал иясенә охшый, диләр, мәчеләренә хәтле үчле бит аларның. Икенче җиргә күчерүгә, балаларын сыртыннан әләктерә дә, тагын ишек төбемә китереп куя. Әйтеп чыктым бүген үзләренә. Тагын бер күземә күрсәтсәгез, мәйтәм, песи балаларыгызны сулы чиләккә тутырам. Билләһи, иптәш депутат, батырам мин аларны.

— Соң сез шул турыда сөйләр өчен генә килмәгәнсездер лә, апа. Нинди йомышыгыз бар соң?

— Иптәш депутат, минем ишек яныннан үтеп йөрмәсеннәр. Шакшок аяк тавышына кызымның да, үземнең дә нерваларыбыз түзми. Үзләренә икенче ишек ачсыннар.

— Андый мөмкинлек бармы соң?

— Анысында минем эшем юк. Теләсә каян алсыннар. Урталай бүлдерәм дә куям коридорны. Мәчесенә хәтле мыскыл итә башлагач, ничек түзмәк кирәк.

— Алай ашыгырга ярамый, апа. Техниклар белән барып карарбыз. Мөмкин дисәләр, эшләрләр. Әгәр яңа җирдән ишек ачарлык җай юк икән, күршеләрегез белән килешеп, тату гына яшәргә туры килер.

— Килешәмме соң? Аллам сакласын. Алар белән каберең якын булмасын.

Менә хәзер шул Галимәләргә килеше инде аның. Галимә күршеләре турында дөнья хәтле яман сүз сөйләп китте. Кем сөйләсә, шуныкы дөрес, ди. Күршеләрен тыңласаң, алары да сүз сорап кешегә кермәсләр. Менә аер инде араларын.

Парадныйның калын имән ишеген ачып керүгә, уң кул якта кечкенә генә чолан шикелле бер корылманы шәйләп алды Фәһимә. Бик теләсәләр, шул турыдан ишек ачарга мөмкин икән дип, үзенчә бер әзер тәкъдим белән эчкә үтте.

Кыйммәтле люстраның бер генә лампасы белән яктыртылган иркен генә бүлмәгә килеп керде. Бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәл янында ашап утыручы кешене күргәч, Фәһимә өзелеп карыны ачканын сизде. Ишеккә арты белән утырган әлеге яшь ханым керүченең исәнмесез дигән сүзенә әйләнеп карады да, ни өчендер тарелкасын күтәреп, түр якка кереп китте.

— Әнә кеше бар, каршыла,— дигән тавышы ишетелде аның эчке бүлмәдән.

Фәһимә гаҗәпләнеп тә, шатланып та куйды: менә көтелмәгән очрашу! Рөстәмнең класс җитәкчесе Ләбаса бу. Куктән көткәнең җирдән бирде, дигәндәй, менә хәзер Рөстәм турында да сөйләшеп китәр. Ләкин түр бүлмәдән чәчрәп килеп чыккан Галимә депутатны шунда ук коридорга әйдәде. Күршеләре белән үзләренең ишек араларын адымлап үлчи-үлчи, Фәһимәгә аңлатырга тотынды. Депутатның сүзне озынга сузасы килми иде. Килде, күзе белән күрде, техниклар җибәрер, алар хәл итәрләр. Шуның өстенә ул үзенең тәкъдимен дә әйтергә ашыкты:

— Теге чоланны сүтсәгез, ишек ачып була инде.

Әмма чолан Галимәнеке булып чыкты. Аны сүтү турында ишетергә дә теләмәде ул. Баягыдан да ныграк тузынырга тотынды. Фәһимә, ник әйттем, дигән көнгә төште. Галимә тавышына күршеләре килеп чыкты. Ак йөзле, юка гәүдәле карчык белән сары читле түгәрәк күзлек кигән, пеләш башлы бер карт икән аның күршеләре. Алары да, бик озын итеп, тәфсилләп, депутат иптәшкә үзләренең хаклыкларын раслый башладылар. Фәһимә аларны сүздән ничек туктатырга белми, аптырап тора иде, бу гауганың бер сәбәпчесе булган әлеге дә баягы балалы мәче коткарды. Аяк астында буталып йөргәндә, кайсыдыр берсе аның койры-

гына китереп басты, ахрысы, мәче бик яман тавыш белән мыраулап җибәрүгә, барысы да сискәнеп, тынып калдылар. Фәһимә шул тынлыктан файдаланырга ашыкты.

— Техник килеп карамыйча, бер сүз дә әйтеп булмый монда. Берике кеше җибәрермен, өйдә булырга тырышыгыз,— дип, бу турыда сүзне очлап куйды.

— Кѳтәбез, иптәш депутат, җибәрә күрегез инде, болай яшәп булмый бит,— дип тәмле телләнеп, ишек тоткасына тотынды депутатны чакырган ханым.

Фәһимә аңа уңайсызланыбрак сүз кушты:

— Галимә ханым, Ләлә Зариповнада йомышым бар иде минем.

Галимә аны яңадан бүлмәгә чакырып торуны кирәк тапмады:

— Нинди йомыш ие соң, әйтеп карармын? — диде.

— Рөстәм Шабаев турында сөйләшергә теләгән идем. Аның укуысы ул...

Галимә аны тыңлап бетермәде, кѳтеп торыгыз дип, кереп китте һәм озакламый әйләнеп тә чыкты.

— Иртәгә мәктәпкә килсен, шундый сөйләшербез дип әйтеп әйтте. Ял итәргә яткан шул. Борчыганны бер дә яратмый. Сез, иптәш депутат, гафу итегез инде, эше бик авыр бит аның, нервынный эш,— дип калды ул, бер сүз дә әйтми борылып чыгып киткән Фәһимәнең артыннан кала-кала.

Ял итә, имеш! Борчыганны яратмый, дип куйды Фәһимә урамга чыккач. Аның ачуы чиктән ашкан иде. Синең генә ул ялың да юк, балаң белән сөйләшергә вакытың да юк, кешеләрнең мәчеләре балалаган урыннарын карап йөрергә этем кушамы сиңа. Кайт та өеңдә утыр, ичмасам, дип, Фәһимә үзен дә бик яман тиргәп ташлады. Тимер ташкын булып гөҗләп килгән колоннаның узганын көтеп, туктап торды. Өзлексез агылган бу ташкынга карап, ул бүген үзенә кереп чыккан икенче бер сайлаучыны күз алдына китерде. Менә шушы машиналар ташкынын икенче урамнан җибәреп булмас микән, биредә бит мәктәп, балалар, бәла-каза чыкмагае дип, борчылып килгән ул. Үз баласы өчен түгел, бѳтенләй чит-ят балалар өчен йөрәге авыртканга килгән. Эше дә бардыр югыйсә, аңа да ял итәргә кирәктер, өйдә семьясы да кѳтәдер. Ә ул эштән кайтышлый депутатка чират тора. Галимәләре генә түгел, әнә бит кемнәре бар бу дөньяның. Нигә соң әле бер кеше өчен кәеф бозып торырга.

Инде өенә кайтырга дип борылган Фәһимә, юлыннан туктап, блокнотын ача да, фонарь яктысында яңа бер адресны карап ала.

Монысы да юл өстендә генә икән. Бу адресны аңа сәер генә бер ханым биреп чыкты. Озын буйлы, ябык гәүдәле, тавышы ирләр тавышыдай калын. Маңгаена төшереп кигән түгәрәк бүрек читеннән колагына чал чәчләре төшеп тора.

— Исәнмесез, Иванова булам мин,— диде ул һәм депутат каршына шундый бер кыяфәт белән килеп утырды, әйтерсең лә Фәһимә шәһәрдәге барлык Ивановаларны да белергә тиеш иде. Шулай да ул бик ачык йөз белән:

— Бик әйбәт, утырыгыз, иптәш Иванова. Ни йомыш? — диде.

— Сез менә бу мәкаләне укыдыгызмы? — Иванова кесәсеннән газета чыгарып Фәһимә алдына салды да «Батырлар үлмиләр» дигән зур гына бер очеркка төртеп күрсәтте.

Әле узган атнада гына Фәһимәләр эшләгән урыннарында бу мәкаләне кулдан-кулга йөртеп укыганнар иде. Ватан сугышында һәлак булган Казан егете турында иде ул.

...Газетада язылган ул юллар, әле яңа укыган кебек, Фәһимәнең күңеленнән үттеләр. Ул, кызыксынып, каршында утырган ханымга карады. Кем ул? Викторның әнисе дип әйтер иде, фамилиясе башка.

Берәр туганымы әллә? Ни эш белән йөри ул? Депутатка ни йомышы төшкән?

Ул арада Иванова газетаны җәһәт кенә җыеп кесәсенә тыкты да:

— Әнә шул егетнең күршесе булам инде мин,— дип куйды.— Витя минем күз алдымда үскән иде. Улым Саша белән бер класста укыдылар. Бергә армиягә киттеләр. Елларын тутырып кайталар гына дигәндә, сугыш башланды. Минем бәхеткә Сашам исән-сау әйләнеп кайтты. Ә Витя, менә үзегез күрәсез... Узган ел Чернигов өлкәсеннән каберен табып, пионерлар хат язып җибәргәннәр. Инде менә газетага да язып чыктылар. Александра Петровнаның, Витяның әнисе була инде ул, өч улы тиң фронттан кайтмады. Узган ел карты үлеп китте. Хәзер япаялгыз калды. Менә шул карчыкны бер әйбәтрәк фатирга урнаштырасы иде, иптәш депутат. Ул үзе аның артыннан йөри алмый инде. Улым Саша да әйтеп караган иде, йөреп карыйк, Шура түтәй, синең күкләр күптән әйбәт фатирларда тора бит дигән иде. Ә ул бичара, тыйнак карчык. Күпме гомерем калгандыр, улларым үскән нигездә үләрмен инде, дип әйтә.

— Торган җире ничегрәк соң? Бик начармыни? — дип сорап куйды Фәһимә.

— И, иптәш депутат, иске йортта тора инде, бер уңайлыгы да юк. Аннары, иптәш депутат, сугышка өч егет биргән ананың адәм рәтле бер фатирда торырга хакы бардыр бит инде.

— Хакы бар, әлбәттә. Бик бар,— диде Фәһимә.— Мин, иптәш Иванова, шушы көннәрдә барып чыгармын. Карарбыз, ничек тә ярдәм итәргә тырышырбыз.

Ул инде кулыннан килгәнне генә түгел, ә булдыра алмастайны да эшләп, карчыкка ярдәм итәргә дип, күңеленә беркетеп куйган иде. Шул ук вакытта теге Галимә ханым турында да уйлап алды. Андыйлар өлешемә тигән көмешем дип тора торганнардан түгел. Теләгәнен бирсәң, биреп, бирмәсәң, тартып ала торган бәндәләр. Ни кешегә, ни күршегә, дигәндәй, гел мин-мин генә дип яшәүче мондыйлар үз балаларына югары мораль сабакларын бирә алалармы икән? Кечкенә балаларын конфет тоттырып урамга чыгарсалар, кешегә бирмә дип, башына тукучы аналарны күргәне бар Фәһимәнең. Баласы янына килгән иптәшен өйгә кертмичә, борын төбендә ишегеп шап итеп ябып куйган кешеләрне дә очраткалады. Бар, әнә шуның янагына менеп төш әле, дип, улын «геройлыкка» өйрәткән аталарны да белә ул. Кайбер шундый семьяларда да әйбәт кенә балалар үсә, югыйсә. Күрәсең, мәктәп тәрбиясе, кино карау, китаплар уку, әйбәт кешеләр белән аралашу бала күңеленә аз тәэсир итми торгандыр. Гаҗәп катлаулы бу кеше дигәнең.

## III

Рөстәм тыныч холыклы иде. Әйбәт билгеләр алып кайтып, өйдәгеләрне бик еш куандырмаса да, укытучылардан шелтә ишетмәде, әнисен мәктәпкә чакырган язулар алып кайтмады. Бер кемгә дә артык мәшәкать тудырмыйча, уртача гына укучы булып, тугызынчы класска килеп җитте. Җәмәгать эшләренә катнашып, түгәрәкләргә йөреп азапланмады. Алай гел читләшеп, иптәшләреннән аерылып, бер үзе йөри торганнардан да түгел ул. Чакырган җиргә бара, кушканны эшли торган гадәтләре дә бар. Моннан бер-ике ел элек алар классыннан өч малай пионерлар сараенда ачылган яшь космонавтлар түгәрәгенә язылырга йөрделәр, Рөстәмне дә өндәделәр. Мәктәптән характеристика кирәк булып чыкты. «Тыныч. Сабыр. Зурлар алдында үзен тәртипле тота. Кушкан эшне җиренә җиткереп үти. Укуы уртача гына. Тырышса, яхшырак укырлыгы да бар» дигән характеристика бирделәр. Ә түгәрәккә алмадылар үзен.

Укуын йомшаграк икән диделәр. Шундый җаваптан соң читенсенгән иде бераз, тора-бара онытылды тагын.

Бүген Рөстәм дәрестән нәкъ вакытында кайтты.

— Анаң, Мөслимгә киткәндә, дәресләрен онытмасын дип әйтеп китте. Син, улым, урамга бик чыгып йөрмә инде,— диде әбисе, оныгының аркасыннан йомшак кына кагып.

— Ярар,— диде дә малай, китап алып, эчке бүлмәгә кереп утырды. Бүген куып чыгарсалар да урамга ике аягының берсен атламас иде ул. Бүген анның бернигә күңеле бармый. Бүген Света дәрескә килмәде. Алар белән бер йортта торучы Нажия генә Светага салкын тигән, авырый, дип әйтте. Ни эшли икән хәзер Светка? Ут янып, кызышып ятадыр бәлки. Врач чакырганнардыр инде, нәрсә дип әйтте икән? Света батыр кыз ул. Юк-бар авыруга гына бирешмәс. Нигә шулай читен икән бу ярату? Әле узган ел Рөстәм Светлана турында уйламый да, зәңгәр күзле бу иркә кызны бар дип тә белми иде. Бер вакыт, Светлана калын чәч толымнарын кистереп килгәч, кырыкмыш тай дип кыздан көлгән иде әле ул. Дөрес, артык авыз җәергә ирек бирмәде Света, спортчыларча, абыйсы өйрәткән юл белән муен тамырына берне кундырды. Тыннары кысылды малайның. Шуннан соң классташына әллә никадәр үпкәләп йөрде ул.

Бер вакыт Светлана Рөстәмгә рус теленнән булыша башлады. Көн саен, дәрестән калып, берәр сәгать үткәннәрне кабатлап утыралар иде. Дөресрәге, Света сөйли, ә Рөстәм аның чигәсенә бөдрәләнеп төшкән сары чәчләрен карап утыра. Шундый йомшактыр инде алар, җиңелдер. Кызык, менә ничә көн инде Рөстәмнең әнә шул чәч бөдрәләренә өреп карыйсы килә. Ачуланыр иде микән Светка? Ачуланды бит әй! «Ахмак!» — дип бер генә сүз әйтте дә, ишекне шап итеп ябып, чыгып та китте. Рөстәм авызын ерып парта арасында утырып калды. Шул көннән соң Света Рөстәм белән калмый башлады. Малай аңа әйтеп-әйтеп тә карады. Әмма кыз якын да килмәде. Берсендә ул нәни йодрыгы белән маңгаена, аннары партага шакып күрсәтте. Барыбер файдасы юк, янәсе. Кызлар көлделәр. Рөстәмнең тагын ачуы килде. Шунысы гаҗәп, ачуланса да ул Света турында гел уйлый башлады. Үзе дә теләми, әмма кызның кыяфәте күз алдына килә дә баса. Яратуның башы шул булды микән әллә? Алай дисәң, ни өчен ул Светаның кайгысына шатлана иде соң? Быел беренче ярты еллыкта Светлана химиядән өчле алды. Кыз бик хурланды. Өчле икәнен белгәч, кызарып китте. Сез миннән бер генә кат сорадыгыз, тагын сорасагыз, мин аны бишкә төзәтә идем, дөрес түгел бу дип, Ләлә Зариповна белән бәхәсләшеп тә йөрде әле. Бервакыт аны ялгызын гына очраткан иде Рөстәм:

— Менә күп мактанып йөрсәң, шулай була ул. Гел һавада гына очарга димәгән, җиргә төшеп, безнең иш урта хәлләрнең дә язмышын бел әзрәк,— дип, үртәп алды.

Света аңа ачулы итеп карап алды да:

— Кысылып тормасана! Я койрыгың өзелер, кәлтә елан! — дип кычкырды, гарьләнүдән күзләренә яшь килде. Шул чагында Рөстәмнең йөрәген сәер бер тойгы телеп үтте. Нишләптер шунда Светаны кызганып куйды. Нигә бер дә шатлыгы юк икән, һаман газап кына китерә икән ул мәхәббәт? — дип уйлый иде Рөстәм кайчакларда. Аның әнисе дә шулай газаплы, үкенечле мәхәббәт белән яратты микән әллә Рөстәмнең әтисен? Әтисе икенче җиргә китеп тора башлаган көннәрдә бик еш кына Рөстәм әнисенең сулыгып елаган тавышына уянып китә иде. Уянганын әнисенә сиздермәскә теләп, одеялын башыннан ук ябынып иде, үз тынына үзе буылып, мышкылдап ята торгач, янадан йоклап китәр иде. Иртәгесен, әнисе эшкә китеп, әбисе белән икәүдән-икәү генә калгач, сорар иде:

— Әбием, бүген әнием тагын елады. Нигә икән?

— Шул юньсез өчен күз яшен сыга инде. Күзсез калыр әле менә,— ди иде әбисе.

Юньсез дигәне Рөстәмнең этисе була инде. Бу өйдә аның исемен телгә алучы юк хәзер. Бик күптәннән шулай. Рөстәм кечкенә чактан бирле. Ул чагында әле малай берни дә аңламый иде. Этисен сагынып берәр нәрсә әйтсә, энисенең йөзе кырыслана, тавышына ачу чыга. Күп вакыт улының сүзен ишетмәгән булып кылана. Рөстәм үзсүзләнеп этисен таптыра башласа, җилтерәтеп әбисе янына чыгарып җибәрә дә, үзе ишекне шап иттереп ябып куя.

— Исемә төшермә шул юньсезне! — дип кычкыра иде ул. Аптырый иде Рөстәм энисенә. Өйдә ире турында сөйләшергә дә кушмый. Исемен дә ишетәсем килми, телгә алмагыз шуны, дип ачулана. Ә үзе ялгыз калдымы, елый да елый. Никадәр генә сиздермәскә тырышса да, Рөстәм барыбер белә: энисенең зур соры күз тәпләре кызарган, керфекләре чыланып беткән була. Юньсез кешеләр өчен елыйлар димени. Аларны тиргиләр генә бит. Әбисен бик яхшы аңлый малай: юньсез булгач, Рөстәмнең этисен гел тиргәп тора ул.

Менә хәзер генә аңлый башлады бугай ул энисен. Аның шулай төннәр буе әрнеп чыгуы шул ярату аркасында булган икән. Тик шунысы гына сәер: бер-берсен яраткан кешеләр нигә аерылышалар соң? Рөстәмнең этисендә әллә шундый зур ярату булмаганмы? Элекке шикелле көчләп бирү дә юк бит хәзер. Кешеләрнең матур торуы бары тик үзләреннән генә булырга тиеш. Кызык, өйләнешсәләр, Рөстәм Светаны шулай ташлап китә алыр иде микән? Кара инде, нинди уйлар килә бит бу тиле башка.

— Рөстәм, шикәргә генә барып кайтчы, улым. Чәй куям.

— Хәзер.

Әбисе канәгать: бу килешкән оныгым бик тыңлаулы әле. Урам бетереп чаба торганнардан булмады. Ничә карасаң, өстәл янында утырыр. Шулай да гел уку да уку булырмыни? Күз бетереп. Ун яше тулмады, күзлек кия башлады. Үзем күзлек дигән нәрсәне белмәдем, житмешнен өстенә чыккач кына кия башладым, анда да инә күзләгәндә генә.

— Рөстәм дим, кибеткә барып кайт инде, чәем кайнап чыкты.

— Хә-әзер...

Әбисе өченче тапкыр дәшүгә, Рөстәм урыныннан купты. Ул кухняга килеп керде дә әбисен шаккатырып:

— Әбием, син яшь чакта берәр кешене яраттыңмы? — дип сорады.

— Тәүбә, әстәгфирулла! Бу нинди сүз тагын. Олы кеше белән шулай сөйләшәләрмени?

— Ник, әби, аның нәрсәсе бар?

— Бар, бар, күп сөйләшмә. Тиз генә барып кайт. Ишетсен колагың, бер аягың монда, икенчесе кибеттә булсын!

— Яра-ар,— диде Рөстәм, иренеп кенә киенде дә чыгып китте.

— Әллә бу бәхетсезең дә гыйшык тота башлаганмы тагын?

Таһир — Зөһрә, Йосыф вә Зөләйха әкиятләрен ишетеп үскән, ләкин үзенең әле мәхәббәт бөреләре уянырга да өлгермәгән житәр-житмәс кыз чагында атасы шикелле кешегә кияүгә чыккан, соңыннан бере арты бере балалар табып, дөнья мәшәкатьләренә күмелеп, артык хәсрәт тә күрмичә, зур шатлыклар да кичермичә генә гомер иткән карчык мәхәббәт дигән нәрсәгә бары тик бәхетсезлек китерүче бер чир дип кенә карый иде. Әнкәсенә киңәш итмичә кияүгә чыгып та кызы Фәһимәнең унмавы, аерылганнан соң да аһ-уһ килеп, төннәр буе күз яше түгеп чыгуы, әле шушы көнгә кадәр теге юньсезне оныта алмавы аның йөрәген сызлата.

Оныгының әле генә әйткән сүзен ул чынга алмады алуын, торыптороп шулай әбисе белән бер шаярып куя торган гадәте бар аның, әле

дә шулай гынадыр. Алай да дөнья хәлен белеп булмый, мыек чыгып килә торган баланың күңеле айда-шайда булып куюы бар, белмәссең. Анасына әйтеп куярга кирәк, күз-колак булсын. Тездә чакта сөйдерә, тездән төшкәч көйдерә, дип белеп әйткәннәр шул борынгылар.

Рөстәм бер кило шикәр тотып кибеттән чыгуга, унбишенче автобус килеп туктады. Автобус бөтенләй буш дип әйтерлек. Утыручылар да бер-ике генә булды. Әллә шуның белән Светкаларга барып кайтырга микән? Ерак түгел бит, ике генә тукталыш. Ул, әле бер уйга килергә дә өлгермәде, лепелдәп ябыла башлаган ишекне каерып, автобуска кереп тә китте. Светаның әнисе ни йомыш дип сораса, Ләлә Зариповна җибәрде, диярмен. Светаның хәлен белеп кайтырга кушты, диярмен. Өз генә сөйләшеп утырырмын да чыгып китәрмен дип, батырланып барды ул барганда. Таныш өйнең икенче подъездына туктап, күрсәткечләр тактасыннан таныш фамилияне эзләп торганда да тыныч иде аның күңеле. Әмма баскычтан менә башлауга, егетнең йөрәге кагарга тотынды. Ул шундый кага, хәтта тын алырга комачаулый. Менә дүртенче кат. Менә алар ишеге. Ишектә ялтырап торган звонок төймәсе. Шуны гына басасың да... Әллә кирәкмәс микән? Иртәгә кадәр көтәргә микән әллә? Әйбер күтәргән көе килеп керү дә уңайсыз бит. Света иртәгә дә дәрестә булмаса, килер ул. Торган җирен белә бит инде хәзер. Рөстәм звонокка кулын бер сузып, бер алып, таптанып торды, торды да, башын иеп, әкрен генә түбән төшеп китте. Әй куркак та инде син, Рөстәм, шушында хәтле килдең. Ишек төбеннән кире борылып китәсеңме инде? Тотып асмаслар иде әле. Светаның күңеле булыр иде. Бәлки ул үзе дә синең килүеңне көтеп ятадыр, дип үзен тирги-тирги малай икенче катка төшеп җитте, менә беренче кат, урамга чыгасың да...

Рөстәм, ялт итеп борылды да, бер тын алуда югарыга менеп тә җитте. Уйланып-икеләнеп торырга вакыт калдырмыйча, звонокка басты һәм шул вакытта гына ишеккә кадакланган номерны күрде. Куырылып китте ул. Кабаланып, бөтенләй башка кешеләргә шалтыратып ята бит. Әнә эчтән аяк тавышы да ишетелде. Хәзер ачарлар. Әллә йөгереп төшеп китәргә микән? Ярамас. Хулиган диярләр дә тотып алырлар.

Ишек ачылды. Чуар халатлы, тәбәнәк буйлы бер хатын сүзсез генә аңа төбәлде.

— Миңа Светлана Мансурова кирәк иде.

— Алар югары катта торалар.

— Рәхмәт.

Ишек ябылды. Ләкин Рөстәмнең дүртенче катка менеп, үзенә кирәк ишекне кагарлык кыюлыгы калмаган иде инде. Ничек менгән, шулай атылып урамга төште дә автобуска таба йөгерде.

Ятып ук авырырлык эше дә юк иде Светлананың. Кичә, үләм, үләм, аягым туңды, дип кайтып керүгә, өйдәгеләр аны күтәреп кенә алмадылар. Әнисе аспиринын, норсульфазолын, тагын нәрсәләрнедер эчерде дә, урынга яткырып, өстенә кат-кат япты. Һәм чыннан да туңып кайткан кыз изрәп йокыга китте. Шул килеш ул караңгы төшкәнче йоклады. Соңыннан да торасы килмәде. Әнисенең йомшак, җылы куллары белән маңгаен тотып торуын, ишектән башын тыгып карап торган әтисенә борчып йөрмә дигәндәй кул селтәвен, аннары юрган кырыйларын кыстыргалап, аяк очына гына басып китүен күзен ачар-ачмас күзәтеп ятуы кызык иде аңа. Чыннан да авырый дип беләләрме алар Светлананы, авырып китмәсен тагын дип куркуларымы, кызга барыбер рәхәт. Баш очында гына төнге лампа яна. Күзне кисми торган тонык кына яктылык лампа тирәсенә генә таралган. Якынрак тартып куйсаң, китап укып

ятарга да мөмкин. Светлананың узган атнада укый башлаган китабы да әнә шунда гына тора. Ул үрелеп кенә өстәл өстеннән шул китапны алды да яңадан юрган астына чумды.

Икенче көнне ул дәрескә бармады. Авырудан түгел. Кичә, кичен дәресен хәзерләмәгән иде. Укытучылар сораса, җавап бирә алмам да начар билге куярлар, дип курыкты. Төшкә хәтле ул яткан җиреннән тормады, китабын укып бетерде. Өй җыештырып, аш-су хәзерләп торучы Нәгыймә апасы чәйне дә кызның караваты янына гына китереп куйды. Төштән соң университетта укучы абыйсы кайтты. Сеңелесенең әле һаман урында аунавын күргәч, сызгырып куйды:

— Әле һаман йокы симертәсеңмени, йокы чүлмәге? Кузгал, хәзер аягыңнан өстерәп торгызам.

Ул кичә кичке биләмнән кайткач, сеңелесенең энеләреннән яшеренеп кенә китап укып ятуын, һәм аның авырган кешегә әз генә дә охшамавын күргән иде.

— Тор, дим, хәзер үк.

— Торам бит инде.

Абыйсы юрганын тарткан саен кыз көлә, тибешә, шулай шаяра торгач ул урын-җире белән идәнгә килеп төшә. Шуннан соң, кинәт абыйсына үпкәләп, авызын турсайтып, торып кинә. Тәрәзә янына килеп баскач, йөзе яңадан ачылып китә:

— У-у, нинди якты! Бүген урамны күргәнем юк бит әле минем. Тышта салкынмы, абый?

— Салкын. Ә җиле юк. Чаңгыда шуа торган гына көн. Әйдә, чыгабыз!

Света аңа җавап бирми. Ул тәрәзәдән кемнедер күреп, урамнан күзен алмыйча гына абыйсын үз янына чакыра:

— Абый, абый, дим, кил әле монда. Әнә теге малайны күрәсеңме? Әнә бит инде, автобуска таба йөгерә.

— Шул көзге чебешнеме?

— Булыр чебеш,— дип әйтә кыз, үпкәләгән булып.— Безнең класс егете әле ул беләсең килсә. Син аның бәләкәйлегенә карама, ул шундый көчле.

Абыйсы әллә үртәп, әллә чынлап, Светагага гел киресен әйтеп тора:

— Шул чебенме? Соң бит аны бер тотсаң, син дә сытасың.

— Сытарсың! Кичә Казанка елгасы буенда бер егет мине төртеп еккан иде. Менә шул «чебен» килеп аралап калды әле сеңелеңне.

— Шушы малай араларлык егеттән ектырып яткач, нинди сеңел син миңа. Нәрсәгә дип өйрәттем мин сиңа самбоны?

— Ә мин юри егылдым. Ул килеп якласын дип егылдым.

— Шәп рыцарь, сөйлисе дә юк. Туңып беткәнче Казанка буенда шуның белән йөрдеңме?

Абыйсы мыскыллап борынын җыера да тәрәзә янынннан китеп бара. Кушеткага кырын яткан көе, үрелеп, гитарасын ала һәм иренеп кенә чиртә башлый.

Светлананың Казанка буенда булган хәлне абыйсына сөйләве юкка гына түгел иде. Кичә Рөстәмнең һич курыкмыйча үзенә ярдәмгә килүе кызның күңелен йомшарткан иде. Хәзер ул абыйсының да Рөстәмне мактавын, классташы турында абыйсының да берәр җылы сүз әйтүен тели. Әмма абыйсы Рөстәмнән көлде генә. Тик шунысы гаҗәп, Светлананың абыйсына бу сүзләре өчен ачуы килмәде, бөтен гарьләнүе, хурлануы, ачуы каты бер төен булып укмашты да гашыйк егетнең үзенә төште. Шундый юаш булуы өчен, көчсез һәм көрәксез булуы өчен һәм шулай була торып та Света шикелле Светаның артыннан йөрергә эрсезлеге житкәне өчен ачуы чыкты Рөстәмгә. Буйга да әллә ни зур булмаган, укуы да уртача гына, бер эшкә дә кушылмый, беркем белән дә

бәйләнми, каршы сүз әйтми, кул күтәреп сукмый торган бу мыштым егет әйтерсең лә үзенең шулай булуы белән Светлана алдында зур гаепле иде.

## IV

Ләлә Зариповна, мамык шәленә төренә төшеп, диван почмагында ял итеп утыра иде, бер малай укытучылар бүлмәсенең ишеген ачты да:

— Апа, тугызынчы «А» да сугышалар,— дип кычкырды.

Ишек ябылуга бүлмәдәгеләрнең барысы да класс житәкчесенә борылып карадылар. Әйтерсең, анда нәрсә булганын ул гына белергә тиеш. Барысы да тугызынчыда укыталар, балаларны ул белгән кадәр үк беләләр, димәк, алар өчен укытучылар барысы да җаваплы. Ә менә андый-мондый хәл чыкса, класс житәкчесенә әйтәләр.

Ләлә Зариповна урыныннан теләр-теләмәс кенә кузгалды. Кайсыдыр аның артыннан, ни чыкса шул югары класслардан чыга, дип калды. Тугызынчы класстан дип кенә әйтеп бетермәде инде.

Чыннан да авыр класс иде ул. Беренчедән башлап бергә укып килгән, бер-берсенең холкын, гадәтен, уку сәләтен — барын да белеп бетергән коллективка, шәһәрнең сигезьеллык мәктәпләреннән бөтенләй ят укучылар килеп керде. Алар үзләре белән күп кенә мәшәкатьләр алып килеп, класста беркадәр ыгы-зыгы тудырдылар. Читтән килгән укучыларның бер ишеләре яңа иптәшләренә тиз генә ияләшеп китә алмыйча, үз эчләренә бикләнеп, яшь бирделәр. Икенчеләренең холкында артык үзгәреш сизелмәде, алар коллективка тиз генә кушылып, тыныч кына укый башладылар. Яңа класска килеп керү белән үзләренең кемлеген күрсәтергә теләгәндәй, иптәшләренә дә, укытучыларга да артык баш бирмичә, үзләрен бик һавалы тотучы авыр холыклы балалар да бар иде биредә. Менә шушы чуар классны, әзерлекле, житди укытучы дип, Ләлә Зариповнага биргәннәр иде. Зур коллективны никадәр каты тотсаң, шул чаклы яхшы була, балаларны кырыслык белән алдырырга кирәк дигән караштагы бу укытучыга кырык кешедән торган классны бер эзгә салганчы шактый кыен булды. Ләлә Зариповна дәресләрне дә начар алып бармый үзе. Кайда-кайда, бу өлкәдә тәжрибәсе дә, осталыгы да бар аның. Бик күп белә. Белгәнен укучыга бирергә тырыша. Балаларны ул үзенчә бер сәер ярату белән ярата. Дәрескә төннәр буе әзерләнеп утыра, кергән саен яңарак, кызыграк материал алып керергә тырыша. Ул укымаган китап, ул алдырмаган журнал калмагандыр бу елларда. Шулай тырышып, бөтен күңелен биреп әзерләнгән дәресендә инде ул укучының кечкенә генә игътибарсызлыгын да кичерми. Тыңнарын да алмый тыңлап торсыннар да аны, сораган минутында, сикереп торып, җавап та бирсеннәр. Шулай булмаса, якты йөз күрмәссең Ләлә Зариповнадан. Аның законы бер — укучы мәктәптә бары тик фән турында гына уйларга, бары тик укырга гына тиеш. Башкасын ул башына да китерә алмый. Яхшылап тыңлап торган укучыга материалны аңлату өчен кырык биш минут вакыт житә, дип карый ул. Шуның өчен кайбер укытучыларның, өстәмә дәресләр биреп, укучыларны өйләренә чакырып, азапланып йөрүләрен аларның булдыксызлыгыннан, эшне оештыра белмәүләреннән күрә. Коллегаларыннан кайберләре аны артык кырыслыкта, җан жылысы житмәүдә гаеплиләр. Бу турыда алар бигрәк тә Хәсән белән бик еш бәрелешкә керәләр.

— Сез, Ләлә Зариповна, каршыгызда тере җан ияләре утырганны онытып җибәрәсез бугай. Бала бит ул алдан билгеләнгән программа белән эшли торган кибернетик машина түгел,— ди аңа Хәсән.

— Ә сез аларның һәр кыланышларына ирек куеп торыгыз әле, хөрмәтле коллега, алар муеныгызга менеп атланырга да күп алмаслар.

Укучының бер кечкенә генә кырын эшен гафу итсән, ул икенчесен эшли, аннан өченчесеннән дә тартынып тормый. Шулай итеп, әкрен-әкрен сез аның характеры бозылуга юл куясыз.

— Аңлы рәвештә либераллык күрсәтү турында сүз бармый бит. Баланың күңелен аңлый белү, аның йөрәгенә ачкыч табу турында әйтәм мин. Кеше күңеле бит ул. Төрле чагы бар. Кайчагында әнә шул бәләкәй кешенең икеле алуын да гафу итәргә туры килә.

— Элек заманнарда ата-аналар балаларын каты тотып, ялгышмаганнар.

— Ә Макаренко?

— Һәр тәрбиячenең үз методы була, иптәшкәем. Күбрәк аның нинди нәтиҗә бирүе белән кызыксыналар.

Укучылар Ләлә Зариповна фәннәреннән начар бармыйлар. Дәресләрдә дә тын утыралар, ләкин, хөрмәт итүдән бигрәк, аннан куркалар. Кызлар, малайлардан җәбер күрә башласалар, Ләлә Зариповнага әйтәм дип кенә котылалар. Алай да ычкынып киткән чаклары була бу классның. Тәнәфес вакытларында, җыелышларда укытучылар әле бер, әле икенче уңай белән тугызынчылардан зарлангалап алалар. Менә тагын нәрсәдер булган. Ни җитмәде икән үзләренә?

Укытучыны класс ишеге төбенә җыелган бер төркем бала каршы алды.

— Апа, сугышалар анда.

Класс ишеге эчтән бикле, ә бүлмәдә ыгы-зыгы, чыр-чу ишетелеп тора. Укытучы ишекне тартып та, шакып та карады, ачмадылар. Аның тирәсендәге малайлар, ярарга тырышкандай, хор белән:

— Ачыгыз, Ләлә Зариповна килде,— дип кычкырдылар. Ул да ярдәм итмәде.

Класс житәкчесе бер төркем бала алдында шулай көчсез калуына хурланып, нинди дә булса бер карарга килә алмыйча тора иде, әлеге бикле ишек шартлап ачылды да биш-алты малай, әүмәкләшеп, коридорга килеп төште. Класс житәкчесе чак кына читкә тайпылып өлгерде. Һәм, көтелмәгән хәлдән аптырап, ишек төбендәгеләр дә тын калдылар. Укытучы ни әйтер дип аңа карап алдылар да, бу хәлне күрмичә, әле һаман аунап яткан иптәшләрен тарткалый башладылар.

Төркемнең иң астында калган Рөстәм ничектер шуып чыкты, уктай атылып, ишеккә ташланды. Күзлеге кайдадыр төшеп югалган, житмәсә күзләрен яшь баскан. Егетнең тирә-ягын тоташ томан каплагандай булды. Ул, баскыч тимерләренә, капка баганаларына, кешеләргә бәреләсугыла урамга чыкты да, өйләренә таба йөгерә башлады. Таеп егылды, торды, өелеп торган көрт өстенә килеп керде. Ул баштанаяк карга батты. Кыскарып калган пиджак җиңеннән күренеп торган беләге, куллары салкын карга чыланып, кып-кызыл булды. Рөстәм, ак томанда йөзгәндәй, берни күрмичә, бәрелә-сугыла өенә таба йөгерде. Юл аркылы чыкканда, йөрәкне ярып янында ук машина кычкыртты. Егет, каушап, юл уртасында туктап калды. Шунда аны берәү җитәкләп алды. Кем икәнен танымады Рөстәм, ә тавышын ишетүгә куырылып китте. Хәсән абыйсы! Үзләренең элекке күршеләре, укытучы Хәсән абыйсы!

— Рөстәм, ни булды сиңа? Нигә өстеңә кимәдең? Бөтен җирең кар, күзлегеңне югалткансың, ахрысы? Ни булды?

Рөстәм аңа җавап бирә алмады, бугазына каты төер тыгылды һәм, ике битен яндырып, күз яше тәгәрәп төште. Укытучы артык сорашып тормады, Рөстәмне өйләренә алып керде. Кушеткага яткырып, өстенә җылы одеал япты. Нәрсәгә барып тотынырга, ни эшләргә белми аптырап калган, каушаган карчыкка, чәй кайнатып, онытына кайнар чәй эчерергә кушты. Аннары, дәресләр беткәч керергә булып, мәктәбенә ашыкты.

Күңеле тәмам ярсыган, тулып ашкан иде малайның. Укытучы артыннан ишек ябылуга, мендәргә капланды да үксеп елап җибәрде. Чәй куеп маташкан җиреннән әбисе йөгереп чыкты.

— Ай, улым, ни генә булды соң сиңа? Бер-бер җирең сырхауладымы әллә, балакаем? Анаң да өйдә юк, ичмасам.

Ул оныгының чәченнән, иңбашларыннан сыйпый, тегесе аның саен катырак үкси. Тәмам борчуга төшкән әби, бөтенләй хәлсезләнеп, ни эшләргә дә белми.

— Духтыр чакырырга микән әллә? Хәсәне дә, чәнчелеп, ашыгып китте бит, ни булганын да сорап калмадым.

Ни булганын Хәсән үзе дә белми иде. Әмма Рөстәм сөйли алыр иде микән бу хурлыклы хәлне? Әле кайчан гына күрәсе килеп, күңелен бимазалаган татлы да, авыр да хисне бүлешәсе килеп йөргән, гомерендә беренче серен сөйләргә теләгән кешесенә дә әйтә алмас иде ул бүген булган хәлне. Сөйләү түгел, ул аны хәзер исенә төшерергә дә оялә. Ой! Никадәр оят, нинди хурлык! Кемне яратам дип йөргәнмен бит. Шул колга буйлы, пыяла күзле Светлананы. Төннәр буе утырып, шуның өчен шигырь яздым. Ә ул... Ә ул... Шулай уйлагач, малайның бөтен тәне буйлап нииндидер кайнар дулкын менгәндәй була да, бугазыннан буып, тынын кыса, күзеннән кайнар яшь булып түгелә. Кызга һәм үзенә булган ачу, әрнү һәм оялу хисен әнә шулай авыр кичерә ул.

Света, Света! Нигә син шулай иттең? Нигә дип аның беренче, саф хисләреннән көлдең? Шуның белән үзеңнең класста беренче кыз булуыңны күрсәтергә уйладыңмы? Бүе житмәс җиргә үрелгәннәрнең мәхәббәтен без әнә шулай аяк астына салып таптыйбыз дип әйтәсең килдеме? Юктыр, андый мәкер юктыр синдә. Бары тик уйлап җиткермәгәнлектән килеп чыккан эштер ул. Бары тик шаяртасың, иптәшләрең алдында егетне бер чәнчеп аласың гына килгәндер. Азмы шулай шаярдың син аның белән. Сиңа булган мәхәббәте хакына рәнҗемәде ул бу шаяруларга. Ә бүген... ә бүген син арттырып җибәрдең, аның бары тик үзең генә ишетергә хаклы булган йөрәк авазын, бары тик үзеңә генә атап әйтелгән кадерле сүзләрен, икәү генә белергә тиеш булган тирән серләрен бөтен класс алдында кычкырып укыдың. Кичә кичен, ничә кат күчереп язып, кадерләп кенә төргән, бүген көне буе сиңа бирергә кыймыйча күкрәк кесәсендә йөрткән иде ул аны. Кулларыңны пешерергә тиеш иде ул кайнар хисле кәгазь, ә син аны салкын кан белән иптәшләреңә фаш иттең. Агарынган йөзен, гаҗәпләнүдән зур булып ачылган күзләрен күрмәдең син аның. Башта ул ни эшләргә белми аптырап калды. Аннары, тиз генә сикереп торып, синең кулдан шул хәерсез кәгазь кисәген йолкып алырга теләде. Кайбер укучы егетләр шуннан кызык тапты. Ни хәл итәсең, аларда әле бу хис уянмаган, ул газапны татымаганнар, алар моңа бары уен итеп, Рөстәм һәм синең арада булган мәхәббәт уены итеп карадылар. Ярсудан ыргылган егетне эләктереп алдылар да кыймылдарга да ирек бирмәделәр. Ә син, артистларга охшатырга теләп, кылана-кылана укыдың. Ярый әле, Нажия синең кулдан тартып алды ул кәгазьне, ярый әле берничә иптәше Рөстәмгә ярдәмгә ашыкты, ярый әле алар сине тиргәп ташладылар, оялттылар. Юкса бу хурлыклы вакыйгада син үзеңне җиңүче дип санаган булыр идең. Әйе, класс икегә аерылды. Иптәшләреңнең яртысы Рөстәмне яклады. Ә икенче яртысы үзләре өчен кызык булган бу хәлдән ахырына кадәр киңәнергә ирек бирмәгәннәргә каршы төштеләр. Класста ыгы-зыгы китте, сугыш башланды. Ә Рөстәм... ул хәзер, бөтен дөньясына үпкәләп үксеп ята.

Аның хәзер беркемне дә күрәсе килми. Классташларын да, әбисен дә, хәтта иң яраткан укытучысы Хәсән абыйсын да. Ә Хәсән абыйсы кичен керәм дип китте. Нәрсә кирәк аңа? Нигә дип аны тынычлыкта калдырмыйлар. Мәктәптә калган сумкасын һәм күзлеген алып, Нажия

килеп китте. Аларга ни кирәк инде? Юк, Рөстәмнең аларны күрәсе дә, сөйләшәсе дә килми. Алар барысы да дошман аңа хәзер. Бу хәлдән соң мәктәпнең янынннан да үтеп китәргә теләми ул.

Мендәргә капланып яткан көе бүген булган хәлләрне тагын бер тапкыр уеннан кичерде дә үзен бик мескен, көчсез, ялгыз калган бер кешедәй хис итте. Юк, ул хәзер мәктәпкә бармаячак. Ник әллә ниләр эшләтмиләр шунда. Директорга чакыртсыннар, комсомол җыелышына куйсыннар, класс җыелышында тикшерсеннәр — барыбер. Ләлә Зариповна гына түгел, әлә кемнәр килеп тиргәсен шунда, аяк та атламаячак хәзер ул анда. Бер дә булмаса, эшкә керер. Кичке мәктәпкә йөрер. Кайда укысаң да барыбер түгелмени?

Бу хәлләрдән соң өч көн үтте. Өч көн инде Рөстәм укырга бармый иде.

— Рөстәм Шабаев бүген дә килмәгән. Кичә өенә барган идем, өендә дә юк. Көн дә, дәрескә барам дип, чыгып китә икән.

Әле генә укытучылар бүлмәсенә килеп кергән Хәсәннең бу сүзләренә өстәл артында расписание рәтләп утырган завуч Фатыйма кушылды:

— Ләлә Зариповна, әнисен чакыртмадыгызмы? Әнисе белән сөйләшеп карарга иде.

Ләлә Зариповна завучка тиз генә җавап кайтармады. Хәсәнгә ачуы килеп утыра иде аның: ниемә дип әле ул кеше эшенә тыкшынып йөри? Рөстәм аңа тапшырылган класста укымый, кирәк булса, Ләлә Зариповна үзе дә аның өенә барып кайта ала. Дәресен генә әйткәндә, әллә ни дау куптарырлык нәрсә күрмәгән иде әле ул. Өенә барган иптәшләре Рөстәмне авырый дип кайтып әйттеләр. Сәламәтләнгәч килер, дип уйлады класс җитәкчесе. Хәсәннең әйткәннәрен мәсьәләне юри куертып, коллегасының авторитетын төшерү өчен әйтелгән сүзләр дип кенә карады. Бер үк эштә эшләсәләр дә, икесе ике төрле, ике караш, ике характер кешесе иде алар. Ләлә Зариповна заманында аның белән тормыш корып җибәрү турында да хыялланып йөргән иде. Ә Хәсән аның күп сыйфатларын хөрмәт итсә дә, бөтенләйгә йөрәгенә алып, үз итеп, яратып китә алмады. Шуңа, күрәсең, Ләлә Зариповна хәзер Хәсәннең исемен генә ишетсә дә, тыныч кала алмый. Гел аның белән бәхәсләшергә, гел аңа каршы әйтергә генә тора. Соңгы вакытларда Хәсәннең кечкенә генә уңышсызлыгыннан да тәм табарга өйрәнеп китте ул: үзе белән бәхәстә җиңелсә дә, Хәсән берәр дәресеннән канәгатьсезлек тойгысы белән чыкса да, завучтан, я директордан шелтә ишетсә дә, тагын башка төрле эреле-ваклы борчулары булса, Ләлә Зариповнаның уртәүле күз карашы һәм салкын елмаюы җәелгән юка иреннәре эзәрлекли Хәсәнне. Әле хәзер дә ул завучка җавап бирү белән бергә үк күңелендәге үпкәсен Хәсәнгә дә белдерми кала алмады:

— Үз классыгыз гына житмәгәнмени сезгә, Хәсән Кәбирович, бүтән класс балаларының да өйләренә йөрмәсәгез. Мәктәптәге биш йөз баланың барысы өчен дә сезгә генә янып-көяргә димәгәндер бит.

— Ничек шул сүзне әйтә аласыз, Ләлә Зариповна? Безнең мәктәп ич ул, үзебезнең балалар, һәркем үз классы өчен генә кайгырса ничек була инде ул? Хәер, урамда бер-берсен дөмбәсләгән балалар янынннан ваемсыз гына үтеп киткән кешеләр азмыни? Берәр малай килеп, тәмәке төпчеге сораса, бер сүз әйтмичә биреп китүчеләр юкмы әллә? Бар бит. Янмый да, көйми дә андыйлар, үз баласы түгел ич, кешенеке. Мин сезне андыйлар белән чагыштырырга теләмим, Ләлә Зариповна, шулай да...

Шактый кызып китә башлаган иде бәхәс, сүзгә рус теле укытучысы Зоя Ивановна кушылды.

— Хәсән Кәбирович, җан кисәгем, нервларыгызны саклагыз, ул бары тик яхшы нияттән генә әйтә бит, үз классыгыздагы балаларның мәшәкате дә бик җиткән сезгә.

Рөстәм белән булган бу вакыйгадан ничә көннәр хафаланып йөргән Хәсәннең кайнар канын Зоя Ивановнаның юатып әйткән сүзләре бераз сүрелдерә төште. Чыннан да, нигә дип әле ул һәр кешедә битарафлык, сүлпәнлек, ваемсызлык кына күрә. Шул ук укытучылар, аның хезмәттәшләре бөтен барлыкларын биреп эшлиләр түгелме соң. Әйтерсең лә ул гына яна, ул гына көя.

— Рөстәм бит ул минем элекке күршем дә әле, Зоя Ивановна,— диде Хәсән, гафу үтенгән тон белән.— Мин аның язмышы белән кызыксынмый кала алмыйм.

— Әйе, Фәһимә Шабаева сезнең күршегез иде бугай шул.

Хәсән Лалә Зариповнаның төртгереп әйткән сүзләрен аңламамышка салынды.

— Әйе, Фәһимә ханым белән без элек бер йортта яшәгән идек.

Ике укытучының шулай чәкешеп алуы мәсьәләне завуч биргән сораудан читкә алып киткән иде. Бәхәснең бераз тынып торуыннан файдаланып, Фатыйма класс җитәкчесенә янадан мөрәҗәгать итте.

— Лалә Зариповна, Шабаевның әнисен күреп сөйләшегез. Кирәк булса, мәктәпкә чакыртыгыз. Рөстәмнең үзе белән дә сөйләшмәгәнсез бит әле сез!

— Шабаеваны өйдә туры китерүе кыен. Тагын командировкага киткән, диләр.

— Әтисен күрергә иде.

— Алар бергә тормыйлар.

— Соң шәһәрдәдер бит ул?

— Шәһәрдәсен шәһәрдә...

Зоя Ивановна, тикшереп утыра торган дәфтәреннән башын күтәрми генә:

— Ни чыкмаса, шундый семьялардан чыга инде,— дип куйды.

— Зоя Ивановна, билләһи дип әйтәм, сез анда үзегез хата ясап утырасыздыр әле?

Укытучы, гөнаһсыз зәңгәр күзләрен күтәреп, Хәсәнгә карады.

— Нигә?

— Нигә дип, үзегез дәфтәр тикшерәсез, үзегез әйткән бер сүзгә колак саласыз.

— Мин инде, җан кисәгем, кайсы баланың нинди сүздә хата ясавын күземне йомып та әйтә алам. Ә менә авыр холыклы балалар, ни әйтсәң дә, җимерелгән-ватылган семьяларда булалар. Анысы факт.

— Анысы дөрес аның. Сүз юк. Әмма андый балаларга без үзебез дә әһәмият биреп җиткермибез түгелме соң?

Завуч, карандашын эшләнеп бетмәгән расписание өстенә салып, өстәл артыннан чыкты. Ике укытучы арасында кабынып киткән бәхәс аны да дулкынландырган иде. Тик Лалә Зариповна гына артык дәшмичә, зифа буен җылы мамык шәленә төреп, стенага сөялгән көе, сын кебек торды. Үзенең Хәсәнгә төрттереп әйткән сүзләрен тегесенең аңламаганга салышуы ачуын кабартты аның.

— Рөстәм шикелле юаш, аның сыман карусыз малайның мәктәпкә килми качып йөрүен берничек тә аңлый алмыйм,— диде завуч, бәхәсләшүчеләр янына килеп.— Дөрес, яхшы яктан күзгә ташланган малай түгел, тик начарлыгы белән дә телгә керми иде бит. Урталыкта бара торган бер малай. Әзмени андыйлар мәктәптә...

Хәсән авызын ачып сүз әйтим генә дигәндә, аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торган Лалә Зариповна бүлдерде:

— Фатыйма ханым, Хәсән Кәбирович сезгә хәзер бик акыллы

кинәш әйтә. Утыз биш ел эшләгән карт укытучының башына да килмәгән бер киңәш. Фикер нясе бит, ни әйтәсен, тыңлагыз.

— Мин әйтәсе сүзләр Фатыйма ханыма яңалык булмас ул, шулай да әйтәм, Ләлә Зариповна. Бәлки сезгә файдасы тияр. Без менә яхшы укучылар белән эшлибез. Аларны түгәрәкләргә тартабыз, чыгышлар ясарга өйрәтәбез, ярышларга җибәрәбез, вожатый, түгәрәк җитәкчесе, кырыкмаса кырык төрле комиссия члены, шайтан белсен, тагын әллә кайларга сайлыйбыз. Җыелыш саен аларны мактыйбыз. Ата-аналарына рәхмәт яудырабыз. Инде берәр бала яман ат алса, аның белән дә кайнашабыз. Ата-аналар җыелышында тикшерү кирәкме, өенә барумы, милиция бүлеге белән сөйләшүме, эти-энисенең эшләгән җире белән элемтәгә керүме, нинди генә мәшәкатьләр тудырмый ул малайлар безгә!

— Соң, нигә зарланасыз? Гөнаһсыз бер бәндәне әле генә ваемсызлыкта гаепләп утыра идегез түгелме соң. Күрәсен, эшлибез икән бит.

— Сез, Ләлә Зариповна, тыңласагыз тыңлап бетерегез, аннан соң фикерегезне әйтерсез.

— Педсовет түгел ләбаса бу.

Хәсән, дулкынланып, сүзен әйтеп калырга ашыкты:

— Педсоветларда гына уйларга, фикер йөртергә тиешме әллә без. Ә менә минем хәзер әйтеп каласым килә. Бик яхшы һәм бик начар укучылар белән генә эшләп, урталыкта баручыларны онытуыбыз турында әйтәсем килә. Андыйлар минем үз классымда да бар, сездә дә житәрлек алар. Мәшәкатьсез, мыштым балалар, сүз дә юк. Икеле алмыйлармы, алмыйлар. Тәнәфестә кеше башыннан йөрмәсәләр, без тыныч. Качып-посып тәмәке тарталар икән, бу безне аз борчый. Ә менә нинди уйлар белән яшиләр алар? Хыяллары нинди? Концертларда классташлары шартлатып шигырь укыганда, очынып-очынып биегәндә, кызыгып карап тормыйлармы соң алар? Бу «урталарның» да кеше сайланган жиргә сайланасы, иптәшләре ярышкан вакытта ярышасы килмимени? Аларның да үз куллары белән ясаган әйберләрне күрсәтеп мактылырга хаклары юкмы әллә? Әнә, күрәсезме, никадәр сорау билгесе. Ә шуна җавап эзләгәнебез бармы? Әнә шулай үзләренең урталыкта баруларына иялэнеп беткән, алга үрмәләргә теләкләре сүнгән, инициативасыз, сүлпән кешеләр тәрбияләмибезме соң? Күпме андый кешеләрне мәктәп эскәмиясеннән тормышка озатабыз.

Инде бер сүрелә башлаган бәхәс тагын кабынып китәргә торганда, бүлмәдә Зоя Ивановнаның тыныч тавышы ишетелде:

— Тормыш катлаулы ул, җан кисәгем, мәктәптә алган тәрбия генә житми. Тормыш үзе кеше холкына коррективалар кертә.

Ләлә Зариповна, ниһаять, стена яныннан купты. Мамык шәленә тагын да төренә төшеп, диван читенә килеп утырды.

— Фатыйма ханым, безнең коллективта менә дигән фикер ияләре бар. Куйыйк әле бер лекция,— диде ул, күзенең кырые белән генә Хәсәнгә карап.— Безнең кебекләргә дә файдасы тиеп куяр.

— Уйларга кирәк булыр,— диде завуч аның кинаясенә игътибар итмичә һәм жәһәт кенә кул сәгатенә карап алды. Тиздән дәрескә керергә звонок булачак иде. Бәхәснең тәмамлануын белдергәндәй, янадан өстәл артына кереп утырды. Кулына карандашын алды.

— Шулай да Рөстәмнең ата-анасы белән сөйләшүне сузмагыз әле сез, Ләлә Зариповна.

Бер тәнәфестә тугызынчы «А»га җилтерәп Ләлә Зариповна килеп керде.

— Дәресләр беткәч, берегез дә таралмагыз. Класс җыелышы була,— диде ул.

Аның каршына шунда ук Нажия килеп басты.

— Ләлә Зариповна, без бүген комсомол җыелышы үткәрәсе идек.

— Алай булгач, бигрәк тә яхшы. Җыелышка Рөстәмне чакырган-сыздыр бит?

Рөстәмнәрнең өенә барып килделәр. Ләкин ул, беркая бармыйм, укырга да йөрмим, мин ул мәктәптән киттем инде, дигән. Ә иптәшләре класс җитәкчесенә, ул өйдә юк иде, дип кенә әйттеләр.

— Ярый, аның белән сөйләшер вакыт алда әле,— диде Ләлә Зариповна. Аның йөзе һәм тавышы бүген гадәттәгегә караганда да кырыс-рак иде.

Нажия тугызынчы «А» комсомолларының җыелышын ачып җибәрде һәм беренче сүзне Ләлә Зариповнага бирде.

Класс җитәкчесе ярты сәгать буена аларга дуслык һәм мәхәббәт турында сөйләде, мәхәббәт дигән нәрсәнең урыны мәктәп түгел, укучы-лар бередә бары тик уку турында гына уйларга тиешләр, әгәр инде арада үзенең төп бурычы — укуны онытып, Рөстәм шикелле, мәхәббәт тотып йөрүчеләр бар икән, аларны, һичшиксез, тәнкыйть уты астына алырга кирәк диде. Аннан соң ул стена газетасын да телгә алды. Мондый фактлар газетада яктыртыла барырга тиеш, иде диде. Светла-наның юк-барга күңел бирмичә, гел уку турында гына уйлавын макта-ды, башкаларны да аның шикелле, бары тик бишкә генә укырга чакырды.

Укучылар Ләлә Зариповнаны тавышсыз-тынсыз гына тыңлап утыр-дылар. Ләкин йөзләреннән һәм артык бер киеренкелек белән утырула-рыннан нидер әйтәсе килүләрен, борчылуларын, укытучының сүзләре белән килешмәүләрен сизәргә мөмкин иде. Хәтта Ләлә Зариповна белән янәшә утырган комсорг үзе дә кинәт-кинәт нәрсәдер әйтергә теләп омтылып карый, тик класс җитәкчесен бүлдерергә генә уңайсызлана иде. Ахырдан ул түзми, укытучысы фикер туплар өчен сүзеннән туктап торган арада, урыныннан күтәрелә.

— Ләлә Зариповна, Олег Кошевойның Нина Иванцовага булган мәхәббәтен ничек аңларга соң болай булгач?

Шуны көткәндәй, арттагы партадан нәзек озын буйлы Шамил дә:

— Ә нигә Космодемьянская үзенең көндәлегенә: «Ул, ләкин ярат-маган кешеннән үптермә»,— дип язып куйган. Ул да укучы булган бит,— ди.

Класс җитәкчесе Шамилгә төбәп карап торды. Аның шундый гадәте бар: дәрес биргән җиреннән дә бүленеп, әчен пошырган берәр укучысына эндәшми кадалып карап тора. Укучы тынычланып утыра баш-лагач кына дәресен дәвам итә. Әле хәзер дә шулай итте ул. Аның күз карашына ияреп, алдагы партада утыручылар да артка борылып карый башладылар. Шамилнең ак чырае уңайсызланудан кып-кызыл булды. Ул әкрен генә урынына утырды. Ләлә Зариповна, бирелгән сорауларга җавап кайтармыйча, сүзен дәвам итте. Ләкин аның бөтенләй игътибар-сыз калуы түгел иде бу. Һәрберсенең тәртибе, үз вакыты бар, укытучы сөйләгәндә бүлдермиләр аны, дип күрсәтергә теләве генә иде. Һәм чыннан да, ниндидер китаплардан алынган бер сүз белән әңгәмәсен тәмамлап куйгач, әлеге сорауларга тукталды:

— Тугызынчы класска җитсәгез дә, әдәп кагыйдәләрен белмисез әле, класста утырырга өйрәнмәгәнсез,— дип, башта ул укучыларны шелтәләп алды. Аннары гына: — Олег Кошевойлар, Зоя Космодемьян-скаялар мәсьәләсе ул бөтенләй башка. Ул вакытта сугыш булган. Ә сугышның аның үз законнары. Ә аннан соң, инде алар күрәшче булып җитлеккәннәр,— дип куйды.

— Тагын сораулар бармы? Менә хәзер бирә аласыз инде сорау-ларыгызны,— дип, ул, калын мамык шәленә төренә төшеп, урынына барып утырды.

Сораулар булмады. Барысының да сөйләргә дип теле кычытып тора иде. Иң әлек әлеге Шамил сикереп торды.

— Сез гафу итегез, Ләлә Зариповна, бу мәсьәләдә минем үз фикерем бар,— диде ул.— Чын мәхәббәт эшкә дә, укуга да бервакытта да комачауламаган. Олег Кошевойлар да көрәшче булгач кына яраткан нар дип уйламыйм мин, бәлки алар шул яратулары хакына көрәшкә күтәрелгәннәрдер әле.

— Чыннан да, әллә Рөстәм фашистларга каршы сугышмас идеме? — дип куйды арадан берсе. Аның артыннан ук берничәсе «прх» итеп көлеп җибәрде.

Шамил сүз кыстыручыга да, көлүчеләргә дә кашын җыерып карап алды да:

— Ник көләсез? Сез аның юашлыгына карамагыз. Рөстәм ул бик әйбәт иптәш. Әллә нинди авыр чакта да ышанып идем мин аңа. Партизан отрядының җитәкчесе булсам, мин аны, берсүзсез, отрядка алыр идем.

Классташлары тагын көлеп җибәрде. Бу юлы инде Шамил үзе дә елмаеп куйды: кара син аны, кызып китеп, партизан отрядына җитәкче булырга да маташа икән әле. Укытучы сөйләгәндә туган киеренкелектән соң барына да рәхәт, җиңел булып китте бу көлүдән. Тик Светлана гына һаман бер көе башын иеп, иптәшләренә күтәрелеп тә карамыйча, күңелсез генә утыра бирде. Ул бу җыелышка калырга да теләмәгән иде. Тик Нажия җибәрмәде.

— Син комсомолкамы, түгелме? Комсомолка булсаң, сәбәпсез җыелыш калдырмыйсың. Беләм бит мин сине, үзең турында сүз булыр дип куркудан качасың,— диде ул.

Җыелышның башыннан бирле ул, эчке бер пошыну белән, иптәшләренең үзе турында сөйләүләрен көтте. Бу көнгә хәтле гел мактала кына телгә алынган кызга андый сүзләрне ишетү бик кыен булачак иде, билгеле. Ләкин әле аны Ләлә Зариповна гына телгә алды. Анысы да уңай яктан. Тик шунысы гаҗәп, укытучының сүзләре бу юлы аны сөендермәде. Ни өчен икән? Иптәшләренең сөйләячәк сүзләрен көтеп пошынуданмы? Алай дисәң, укытучы үзе бит аның ягында. Ләлә Зариповна яклап торганда, классташлары ник шунда әллә ни әйтмиләр. Ләкин бит ул бер үзе генә. Ә укучылар. Кичә Хәсән абыйсы аны чакырып алып сөйләште. «Кешеләрнең үзеңә карата булган яхшы хисләрен хөрмәт итә белергә кирәк. Кемнең дә булса берәүнең дуслыгына, я мәхәббәтенә шуның белән үк җавап бирү анысы синең эш, әмма ул саф хисләрдән көлү — түбәнлек»,— диде ул. Рөстәмнең хатын кычкырып укыганнан бирле инде ул нинди генә сүзләр ишетмәде, әмма аларның берсе дә Хәсән абыйсы әйткән сүзләр кебек йөрәген яндырып тормады: «Кешеләрнең үзеңә карата булган саф хисләрен хөрмәт итмәү — түбәнлек...» Түбәнлек. Ә бит Светлана, киресенчә, үзен Рөстәмнән өстенрәк куйганга шулай эшләгән иде. Кеше күзенә ташланмый торган Рөстәм һәм классның беренче укучысы Светлана, дип караган иде ул. Бәлки Светлананың үз-үзенә соклануы бөтенләй урынсыз булгандыр. Шамил әйтә бит, Рөстәм ул яхшы иптәш, аңа ышанырга була, ди. Моны Светлана үзе дә белә. Казанка буенда, аны яклап, зур, көчле егеткә ташланган шул Рөстәм түгел идеме әллә?

Светлана шулай уйланып утыра иде, Нажиянең тавышына сискәнеп китте.

— Ә Светлана үзе нәрсә уйлый? Нигә ул берсүз дә сөйләми әле?
— Әйе, әйе, ул нәрсә әйтер икән?

Кыз авыр гына торып басты. Булышыгыз инде дигәндәй, ялварып укытучыга карады. Нәрсә дип әйтсен соң Ләлә Зариповна. Ул үзе дә аптырап калган иде әле.

Ул, укучыларын әле беренче тапкыр күргәндәй, карап тора. Бер күз карашым белән дә җиңәм мин аларны, дип йөри иде бит әле ул. Шул

укучылар тормышның нинди дә булса бер мәсьәләсендә үзенең фикере белән килешмәсләр дип башына да китерми иде.
Ә иптәшләре Светланадан җавап көтәләр.

## У



Улы Рөстәмнең дөньяда барлыгы турында шәһәр клиникаларының берсендә эшләүче хирург Фәйзи Әхмәтович Шабаевның исенә төшерүче класс җитәкчесе Ләлә Зариповна түгел, ә егет үзе булды.

Әз генә кар сибәләп торган җылы җепшек көн иде. Урам чатындагы бакча эченә салынган борынгы йорт янына юаш кыяфәтле бер яшүсмер килеп туктады. Парадныйның звоногына басарга кыймыйча озак таптанып торды ул. Бармагы белән күзлеген күтәреп, тирләп чыккан борын очын сөртеп алды. Аннары, бүреген басып куйды да, төймәгә җәһәт кенә басты. Озак көтәргә туры килде аңа. Өйдә юк микәнни, дип китәргә дә уйлаган иде, эчтән аяк тавышы ишетелде. Малайның арка тамыры чымырдап китте. Тез буыннары йомшагандай булды. Кем ачар ишекне? Әгәр әтиемнең хатыны ачса, нәрсә дип әйтермен? Ул, мине танып, ишек төбеннән үк куып җибәрсә? Әтием үзе генә ачса ярар иде дип уйлады ул.

Ишек ачылды. Кар шикелле ак күлмәк өстеннән җылы йөнтәс нәрсә кигән зур буйлы, матур йөзле бер кеше — Рөстәмнең әтисе — кем кирәк, дигәндәй сүзсез генә карап тора башлады. Рөстәм аны шунда ук танып алды.

Моннан җиде-сигез ел элек әтисен соңгы тапкыр нинди кыяфәттә күргән булса, ул әле дә шундый. Тик чәчләре агара башлаган һәм гәүдәсе бераз тазара төшкән. Бик ерактан килгән ниндидер бер моңны тыңлагандай, башын аз гына кыңгыр салып карап торуларына кадәр онытмаган икән әле Рөстәм. Баштарак исе китмәгәндәй иде, ә менә соңгы елларда ни өчендер әтисен бик күрәсе килә башлады аның. Үсә-үсә эти кеше бик кирәк була икән шул. Башка малайлар әтиләре белән балыкка баралар, яр буенда көймә буйыйлар. Дәрестә икеле алсалар, әтиләреннән куркып, өйләренә кайтмый йөриләр. Сугышсалар, әтигә әйтәм дип, бер-берсен куркыталар. Кичләрен, әтиләре янына утырып, телевизордан футбол карыйлар. Иптәшләренә барганы бар Рөстәмнең. Аларның өйләрендә ничектер шау-шулы, ыгы-зыгылы булса да, рәхәт. Андый өйләргә кеше дә күп йөри. Анда сөйләшүләр дә бөтенләй икенче.

Ә Рөстәмнәрдә тып-тыныч. Гел әбисе белән икәү генә алар. Әнисе командировкаларда булганда, атналар буе аларның ишеген кагучы юк. Өйдәге тынлыктан күңелгә салкынлык бәреп тора. Ничектер чыгып йөгерәсе, кешеләр янына барасы килә. Әтисе китмәсә, алай булмас иде.

Менә аның каршында эти кеше басып тора. Рөстәм узган елларда ук инде бу йортны эзләп тапкан иде. Әтиемне күрмәммме дигән яшерен өмет белән бу бакча, бу ишек тирәләрен аның шактый әйләнгәләгәне бар. Әтисен очрата алмады Рөстәм, ә икенче килүендә нәкъ аңа охшаган бер малайның, чаңгылар күтәреп, шул ишектән килеп чыгуын күрде. Аның малае, дип уйлады ул. Нәни йөрәкне берьюлы йөзләгән инә чәнчеп алгандай булды. Рөстәм үзенә-үзе хисап биреп өлгерә алмады, кинәт туган көнчелек хисенә бирелеп, чаңгыларын киеп азапланган малайны төртеп екты. Екты да үзе йөгереп китте. Аның колагына малайның, әтигә әйтәм,— дигән сүзләре ишетелеп калды. Бу сүз әле соңыннан да аны үртәгәндәй бик күп көннәр буе колагында чыңлап торды. Әтигә әйтәм, имеш! Әйе, алар әти дип әйтә алалар. Ә Рөстәмнең андый кешесе юк. Кыерсытсалар, яклаучысы да юк. Менә бүген ул әтисен эзләп килде. Гомерендә беренче тапкыр иң авыр хәлгә төшкәч килде.

Таяныч эзләп, киңәш сорарга килде. Әле ярый, әни өйдә юк, ул өйдә булса, көчләп-көчләп мәктәпкә куган булыр иде. Ә мин барыбер бармас идем. Әти алай итмәс. Ул миңа эш табарга булышыр. Әнә бит ул нинди. Үзе зур, үзе матур. Аны белмәгән кеше дә юктыр әле шәһәрдә, кемгә барып сөйләшсә дә, сүзен тыңларлар, бөтен дөньяны үзенә буйсындырырлык куәте бар сыман аның. Архимед бабай кебек, таяныр ноктасы булганда, бөтен җир шарын әйләндерерлек акыл бардыр анда, дип уйлады Рөстәм. Ләкин бер үк шәһәрдә яшәп, буй үстереп килгән баласын танымый микәнни соң ул? Әнә шулай бер-беренә караган көе сындай катып күпме торырга мөмкин соң инде? Рөстәм, ялгыш килгән кешедәй, кире китәргә дип борылды. Шунда гына әти кеше телгә килде:

— Кер. Рөс-тәм!

Ул, читкә тайпылып, малайны алга уздырды. Ә үзе парадныйның ишеген бикли алмыйча шактый азапланды. Ниһаять, ул бүлмә ишеге төбенә килеп туктаган Рөстәм артыннан китте. Бу көтелмәгән очрашудан Фәйзи Шабаев гаять дулкынланып, каушап калды. Рөстәмне ул күрү белән үк таныды. Дөрес, ул аның кыска ыштанлы малай вакытын гына белә. Шуннан бирле күрешкәннәре булмады аларның. Фәһимә шулай теләде. Киселгән икмәк кире ябышмый, безне борчып йөрмә, диде. Аннан соң икенче хатыннан балалары туды. Кыска чәчле кечкенә малай образы әкрен-әкрен тоныклана барды. Ә менә хәзер, борын астына мыек төртеп чыккан үсмер егет килеп кергәч, ул югалып калды. Бер карауда ук Фәһимәнең чалымнарын шәйләп алды ул. Фәһимәнеке төсле үк коңгырт күзләр, сызылып киткән кара каш. Никадәр генә онытырга тырышып та, әле соңгы көнгә кадәр күңелне бимазалаган кадерле йөз сызыклары. Болар барысы да инде күптән булып үткән хәлләрне яңадан исенә төшерделәр.

Бик матур яшәргә тиеш иде бит алар. Бер-берсен сөешеп туймас еллары иде. Фәйзи китеп барды, ә Фәһимә тотып калмады. Тотарга теләмәде. Әйткән сүзе бар иде шул: Фәйзи мин сине бик, бик яратам. Ләкин белеп тор, башкаларга карасаң, бер вакытта да, бер кайчан да кичермәм. Безнең ара мәңгегә өзелгән булыр!

Мәхәббәтең никадәр зуррак, кайнаррак булса, аның таплануын авыррак кичерәсеңдер шул.

Шундый хәлләр буласын каян белгән диярсең. Фәйзи үзе алай буласын башына да китермәгән иде. Уйламаганда килеп чыкты ул хәл. Башта ул аның өчен бик борчылды, Фәһимәсенә сиздермичә генә атналар буе газапланып йөрде. Тора-бара басылды тагын, кеше сизмәсен дигән бер борчу гына калды аның күңелендә. Вакытлар үтүгә анысы да онытылды. Фәйзи инде тәмам тынычланды. Өчәүләп диңгез буенда ял итәргә җыенып йөргән көннәре иде. Ул үзенә һәм хатынына ничек тә путевкалар табу артыннан йөри, Фәһимәсе юл кирәк-яракларын караштыра. Барысының да күңеле күтәренке, шат иде. Һәм бер кичне... боларның барысы да чәлпәрәмә килде. Аны яшь кенә, чибәр генә бер явыз хатын эшләде. Семья булачак сәяхәт турында хыяллана-хыяллана, түгәрәкләнеп чәй эчеп утырган чагында килеп керде ул. Оялып, тартынып та тормады. Туп-туры өстәл янына килде һәм ничектер кинәт кенә сулып, куырылып киткән Фәйзигә карап: я, ни эшлибез, судлашабызмы, бергә яшибезме? Безнең балабыз булачак,— диде.

Фәһимәне яшен суккандай булды. Бөтен гәүдәсен кинәт хәлсезлек басты. Күз алдында вак кара таплар бии башлады.

Күзен ачып җибәргәндә ул кроватьта ята, ә Фәйзи, башын иеп, хатынының аяк очында утыра иде. Фәһимә күзләре белән әлеге хатынны эзләде, тапты, аның салкын күз карашлары белән очрашты һәм хәлсез тавыш белән:

— Кит! Аның белән кит! Калдыр безне,— дип пышылдады.

Фәйзи китте. Ишелеп килгән бу бәхетсезлекне күтәрерлек егетлек тапмады, судлашып, иптәшләре алдында хур булудан курыкты. Шуның белән үткәннәргә киртә куелды, алар инде онытылыр, бетәр дип уйлады ул, әмма ялгышты. Фәһимәнең юлыннан китте Фәйзи, тик аны йөрәгеннән чыгарып ташлый алмады. Еллар үткән саен, аның югалган бу бәхете ныграк сагындырып, мәңгегә килгән чир сыман борчып тора башлады. Газеталары, телевизор һәм радиолары бик еш кына аның исемен телгә ала торган булдылар. Юк юк та ул аны урамда очраткалый, медиклар җәмгыяте оештырган кичәләрдә күргәли һәм яшь вакытның гүзәл хатирәләре тагын яңарып, аның йөрәген телгәли иде. Бу очрашулардан соң ул ни эшләргә белми бик озак сагышланып йөри. Яшь хатын моны сизә, көнләшә. Урынсыз шикләнүләр, озакка сузылган үпкәләүләр, атналар-айлар буе дәшми йөрүләр тормышның бөтен ямен ала. Әгәр Фәйзи табигатьтән гайри бер көч бар дип ышана торган булса, бу газапларын яшьлегендә эшләгән бердәнбер гөнаһысы өчен килгән җәза дип уйлар иде.

Алар бик матур итеп җыештырылган зур, якты бүлмәгә керделәр. Фәйзи улын ишек төбеннән түргә чакырды. Тик малай ямьшәйгән, карлы ботинкалары белән яшел хәтфә паласлар өстеннән узарга кыймады.

— Рәхмәт. Мин моннан гына. Хәзер китәм,— диде ул. Үзе йөнтәс бүреген салып, тирләгән борынын сөртеп алды. Кыен иде аларга. Икесенә дә кыен иде. Бер-берсенә бик якын да, бик чит тә алар. Берберсен күрүгә куанышканнар да, ниндидер ярамаган эш эшләп тотылгандай, каушаганнар да. Рөстәм, сагаеп, түрдәге бүлмәләргә керә торган ишекләргә карап ала. Әнә шул ак буяулы биек ишектән берәрсе килеп чыкмагае дигән уй тынгылык бирми аңа. Теге чаңгылы малай чыгып, әти, ул мине тертеп екты дисә, аның әтисе, юк, Рөстәмнең үз әтисе, аны тирги башласа... Рөстәмнең шикләнүен Фәйзи дә сизде.

— Без биредә икәү генә. Балалар әниләре белән циркка китте. Яңа бина ачылгач барганнары юк иде әле. Ә мин бармадым. Бераз эшләремне карыйм дип калган идем,— диде ул. Ә үзе, кара инде, нигә болай күп сөйлим әле мин, күрәсең, улымның килүе каушатып җибәрде, дип уйлап алды. Дөресен генә әйткәндә, бу очрашуның шаһитсез булуы аның өчен бик кирәк иде. Әле болай да бу стеналар, бу тәрәзәләр аша хатынының күз карашы аның аркасын бораулап тора сыман. Әйе, бу очрашуның кыскарак булуы хәерле. Ичмасам, бүгенгә. Бу юлы. Торабара алар тагын күрешерләр әле. Башка вакытта. Тынычрак урында.

Шулай да нигә килде икән аның улы? Юктан гына шулай килеп кермәгәндер бит ул.

— Өегездә берәр хәл булдымы әллә, Рөстәм? Әниең авырмыйдыр бит?

— Юк, авырмый,— диде малай һәм тотлыгып калды. Аның әтием дип әйтәсе килде, әмма теле әйләнмәде.— Мин эшкә керергә уйладым. Берәр җиргә урнаштырмассызмы, дигән идем.

— Син укуыңны бетердеңмени инде? Институтка керергә уйламыйсыңмыни?

— Тугызынчыда гына бит әле мин.

— Оныта язганмын. Уналты гына яшь бит әле сиңа.

— Унҗиденче китте инде.

— Әйе, әйе, февраль аенда уналты тулды.

Фәйзи тынып калды. Февраль аенын ябалак кар төшеп торган җылы бер көне, бала табу йортыннан Фәһимәсе белән Рөстәмен алып чыккан вакыты күз алдына килде аның.

— Февраль ае...

Ләкин малайның хисләргә бирелеп торыр чагы түгел иде, аның түземсез тавышы тагын кабатланды.

— Миңа бирәр эш кирәк иде.

Рөстәмнең тел очына тагын эти дигән сүз килде, тик бу юлы да ул аны әйтергә кыймады.

— Нигә соң әле син унынчыны бетерергә уйламыйсың? — диде Фәйзи, башын кыңгыр салып улына бераз карап торгач.— Тормышыгыз бик авырмы әллә? Мин сезгә ярдәм итәргә теләдем. Әниең бит, алмады. Кыен булса, әйтегез, мин хәзер дә сезгә акча биреп барырмын. Минә хәзер үк...

Ул, кабаланып, кесәләрен капшый башлады. Юк, юк, акча аламы соң Рөстәм аннан. Монда килгәнен ул әнисеннән дә яшерергә уйлаган иде бит. Әнисе белсә, үпкәләр, улының акчалар алып йөрүенә риза булмас. Иң авыр вакытларында да ул Фәйзи Шабаевка барып егылмады. Хәзер инде, тормышлары көйләнгәч, әйбәт кенә яши башлагач, ул нәрсәне эшлиме соң? Аннан Рөстәмнең эшкә керергә теләве бөтенләй акча өчен түгел бит әле. Аның зурлар белән бер тигез хокукта яшисе, тизрәк кеше арасына керәсе, беркайчан да, беркемнән дә үзен кимсеттерәсе килмәүдән генә бит. Эшкә кермәсәң, кичке мәктәпкә укырга алмыйлар икән дип тә ишетте ул. Ә укуны бетерергә кирәк аңа. Анысын Рөстәм үзе дә белә. Тик әлегә кадәр укыган мәктәбендә түгел. Җене сөймәс Светаның күз алдыннан китәргә кирәк. Башка җирдә укырга, бүтән укучылар белән укырга. Нигә соң әле бу эти дигән кеше акча турында сүз кузгатты? Нәрсәгә кирәге бар аның Рөстәмгә. Киногә барыйм дисә, әбисе дә, әнисе дә каршы килми. Кирәк әйберләрен дә гел алып биреп торалар. Юк, акчаның бернәрсәгә дә кирәге юк Рөстәм өчен. Тизрәк кесәсенә җыеп тыксын да, нигә, ни өчен, ни эшләп алай дип төпченүдән генә туктасын инде. Барысы турында да ничек сөйләп бирәсең ди аңар. Әти кеше булса да, читтә яши торган, бөтенләй ят кеше бит инде ул аның өчен. Ә Рөстәм ялганлый алмый. Класста булган хәл турында этисенә әйтү түгел, егет аны үзенең исенә төшерергә дә хурлана. Бетсен, онытылсын, яңадан искә төшмәсен дип йөрүе бит инде аның.

Ничектер сүзнең җае табылмады. Ата белән бала арасында берберенә ышану тумады. Икесе ике нәрсә турында уйлый, ике нәрсә турында сөйли башладылар. Егет озак тормады. Ишеккә борылды. Әтисе калырга кыстамады. Эш кирәк булса, эзләп карармын, берәр җае чыкмый калмас, диде. Әмма кайчан, кайда очрашырга кирәген кистереп әйтмәде.

Бакча кырыендагы борынгы өйнең ишегеннән ябып урамга чыккач, җиңел сулап куйды Рөстәм. Читлектән очкан кош кебек сизде ул үзен. Әтисен күрү теләге басылган, инде кайчан да булса яңадан күрешергә эз генә дә омтылыш калмаган, алай гына да түгел, малайның йөрәгендә юкка килдем дигән бер үкенү уянган иде. «Теге малае өчен йөгереп йөрер иде әле. Миңа гына шулай ул»,— дип, этисенең малаеннан көнләшеп тә куйды.

## VI

Мөслимгә килгәннән бирле күңеле тыныч булмады Фәһимәнең. Әллә ни генә йөрәгән тырнап, эчен пошырып торды шунда. Киткәндә, Рөстәмне йокысыннан уятып булса да, әйтәсе сүзләрен әйтеп китәсе калган икән. Бигрәк тәмле йоклый иде шул, кызганды, уятмады. Алай дисәң, шулай ашык-пошык җыенып киткән чаклары аз булдымыни аның? «Бу кадәр күңелем ярсып, үземә урын таба алмый йөргәнем юк иде. Әллә эни авырый микән? Исән-сау гына яши күрсен. Бөтен терәгем шул.

Аннан башка тормышны күз алдыма да китерә алмыйм», дип үйлады Фәһимә. Мөслим кибетенә барып, көчтәнәчкә вагын-төяген алды. Эч пошу шатлыкка була дип әйтәләр, дип үзен юатырга тырышты. Ялгызлык шулай итә торгандыр инде. Һәрвакыт нәрсәдән булса да шикләнеп яшисең, нәрсәдәндер сагаясың, бер-бер яман хәл булмасын дип борчыласың.

Аларның Фәйзи белән аерылышуларына да ничә ел бит инде. Фәйзинең хәзер үз оясы бар. Балалар үстерә. Тик Фәһимә генә, әнисе әйткәндәй, һаман да шул юньсезне оныта алмый. Элекке мәхәббәт беткән инде. Аның урынына газаплы, әрнүле хатирәләр калган, ир кешегә булган ышаныч кимегән, мәхәббәтнең бөеклегенә табыну югалган. Әнә шулар башка кешене яратырга, аңа ышанырга ирек бирми бугай. Ничә еллар инде Фәһимә әнисе һәм бердәнбер баласы өчен борчылып, ялгыз башы гомер итә. Ул бәхетен эштән табарга уйлый. Нәрсә кушсалар, шуны башкара, кая җибәрсәләр, шунда бара. Ял дими, эш сәгатьләрем тулды дими. Аның тырышлыгын күрделәр, күтәрделәр, төрле комиссияләргә сайладылар. Менә ничә ел инде ул шәһәр Советы депутаты булып тора. Аны беләләр, ул үзе дә эш белән онытыла, баштанаяк бирелеп эшләгәндә, йөрәктәге тынгысыз уйларга урын калмый. Ул шулай дип уйлый, шулай дип юанырга тырыша. Ләкин вакыт-вакыт ялгызлык үзен сиздерә. Бигрәк тә бәйрәм араларында, ял көннәрендә. Ике көнлек ялга да күчкәч, кешеләр парлап-парлап тегендә-монда баралар. Урамнарда ул ирен култыклап барган хатыннарны күрә. Үзенең дә шулай йөрисе килгән тоя. Аның да әле сөеләсе, ир кадере күрәсе, ир таянычын тоеп яшисе килә.

Хәсән аны ярата бугай. Бу турыда аның авыз ачып Фәһимәгә бер генә сүз дә әйткәне юк. Ләкин хатын-кыз йөрәге бит барометр кебек, үзенә булган кечкенә генә игътибарны да бик тиз сизә. Ә Хәсән аларны икенче йортка күченеп киткәч тә онытып бетерми. Юк юк та ул Фәһимәне эзләп таба. Рәхмәт инде, авыр вакытларда күп булышты ул аларга. Рөстәм белән дә бик дуслашканнар иде. Фәһимә үзе дә нәләнеп бетә язды. Ялгызлыктан эчләре бик пошкан чакларында алар бер-берсен я театрга, я кинога чакыралар, я булмаса бергәләп урамнан йөреп керәләр иде. Шулай йөргән чакларында Фәһимә үзендә дә сәер бер хис уянуын тоя. Юк, Хәсәнгә булган рәхмәт хисе генә түгел ул, инде күптән онытылган, яңадан кабатланмас дип уйлаган тойгыларның үзен сиздерергә теләве булса кирәк.

Кешеләр Хәсән белән Фәһимә өйләнешә икән дип сөйләделәр. Фәһимәнең әнисе дә бу хәбәргә сөенгән иде. Еш кына кереп йөргән, хәлләрен белешеп, йомшак кына сөйләшеп утырган бу укытучыны ул яратып калган иде. Укытучы, тәүфыйклы кеше, Рөстәмгә дә әти булыр, дип юраган иде. Тик Фәһимә генә ашыкмады. Хәсәнне ул абыйсы шикелле итеп ярата, хөрмәт итә. Тыныч холыклы, сабыр табигатьле бу кешегә мәхәббәте көчәйсә, шатланыр да иде. Үзенең Хәсән белән бәхетле булырын да аңлый. Ләкин, ни эшлисең, бер алданган йөрәк тиз генә ачылып китәргә ашыкмый.

Ә менә күңел тыныч түгел. Нинди бәхетсезлек көтә аны? Фәһимә, самолеттан төшүгә такси алып, өенә ашыкты. Ике баскычны бер сикереп, югары менде, ишек төпләренә килеп җиткәч, тын алырга да тукталмыйча, звонок басты. Әнисенең аяк тавышы килгәнче, йөрәге тынычланмады. Нинди генә хәбәр ишетер икән ул. Менә ишек ачылды һәм анда чуар халат кигән әнисе басып тора иде. Фәһимәне күргәч, карчыкның талган йөзе яктырып китте.

— Әнием, икегез дә исән-саумы? — диде Фәһимә, баскан урыныннан да купмыйча.

— Ай алла, исән булмый кая китик,— диде энисе һәм кызының сумкасына үрелде.— Үзең исән-имин генә кайттыңмы?

Фәһимә эчкә атлады. Шул вакыт ул үзенең бик арыганлыгын, хәлдән тайганлыгын сизде. Чишкән пальтосын салып эләргә көче җитмәде, аркасы белән ишек яңагына сөялде.

— Әллә нишләп эчем бик пошты. Гомер алай булмый иде,— диде ул, кухня ягына кереп барган энисенә,— берәр күңелсезлек юктыр бит?

— Күңелсезлек дип, әллә нәрсә юк,— диде Хәдичә әби, нәрсәгәдер икеләнгәндәй бераз гына туктап торды, аннары кызына борылды.— Кайтып керү белән бирмәм дип әйткән идем, мә инде,— диде ул, халат кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарып,— ышкулдан җибәргәннәр. Рөстәм турысында.

Кәгазь Рөстәмнең класс җитәкчесе Лэлә Зариповнадан иде. Чакырып җибәргән. Мондый кәгазьләр өйгә балаң бик юньле булганга кайтмый инде.

— Нәрсә эшләде икән бу малай актыгы?

— Белмим, белмим, үзең баргачтын әйтерләр әле,— диде Хәдичә әби.

Рөстәм белән булган хәлнең барысын берьюлы әйтеп ташларга кодрәте җитми иде аның. Бераз тынычлангач, иплэп кенә сөйләрмен дип әзерләнгән иде дә бит, кызы энә артыннан ук кереп тә җитте.

— Яшермичә генә әйт әле, әни, Рөстәмгә ни булды?

— Ни дип инде. Сабагын калдыргалый. Син киткәч бармады.

— Бер дәме?

— Бер дә дип инде, бармады шул. Хәсән дә әллә ничә кат килеп китте, иптәшләре дә.

— Үзе кая соң әле?

Фәһимәнең тавышы кырысланып, күзләре караңгыланып китте. Моны күреп, Хәдичә әби тагын Рөстәм ягына ауды:

— Әле генә өйдә ие, иптәшләренә чыгып китте микән, ай алла, менә әле генә шушында китабын укып утыра ие бит,— дип, Рөстәмнең инде иртәдән бирле өйдә булмавын яшереп калды.— Син, кызым, башта әйбәтләп сөйләш үзе белән. Балага тиктомалга каты бәрелмә. Бәлкем гел дә гаеп анда түгелдер әле. Менә чәй эчеп ал да ышкулга барып сорашырсың.

Чәйне күтәп тормады Фәһимә. Әле салып та өлгермәгән пальтосын яңадан төймәләде дә, кабаланып, мәктәпкә китте.

Укытучылар бүлмәсендә аны Зоя Ивановна каршы алды. Үзенең гадәтләнгән урынына, кызыл сукно ябылган өстәл башына утырган да ул һаман дәфтәр тикшерә. Дәрес арасындагы биш сәгатьләрне, кыска гына тәнәфес вакытларын бер дә әрәм үткәрми, я укучыларның дәфтәрләрен тикшереп куя, я аларның көндәлекләрен карый, я башка берәр эш белән утыра ул. Иптәшләре бер шагыйрьнең сүзләре белән шаяртalar аны:

— Зоя Ивановна, «өйгә кайткач, өйгә кайткач...»

— И җан кисәкләрем,— ди андый вакытта Зоя Ивановна,— өйгә кайткач та житә әле ул эш.

Лэлә Зариповна белән сәер генә мөгамәләдә яши Зоя Ивановна. Моның сәбәбен бары тик алар үзләре генә беләләр.

Лэлә Зариповнаның Хәсән Кәбирович белән әйбәт кенә сөйләшеп йөргән вакыты иде әле. Шулай беркөнне Зоя Ивановна дәрескә барыннан да элегрәк килде дә, үзенең яраткан урынына, зур булып үскән каен гөле артына кереп утырып, бер журналдагы мәкаләдән өзекләр күчерә башлады. Озак та үтмәде, бере арты бере Хәсән Кәбирович белән Лэлә Зариповна килеп керделәр. Алар юлда да бергә килгәннәр, килгәндә, араларында бик җитди сөйләшү булган, күрәсең, Лэлә Зариповна еларга җиткән тавыш белән:

— Синең нигә шулай салкын булуынны беләм мин, Фәһимә Шабаева башынны әйләндерә,— дип әйтте.

— Әйе, Фәһимә мина ошый, бик ошый, тик безнең арада берни дә юк.

Алар Зоя Ивановнаны күрмәделәр, ә ул ирексездән шундый сергә тап булуына уңайсызланды, үзенең барлыгын белдерү өчен идәнгә китабын төшереп җибәрергә мәҗбүр булды.

Лэлэ Зариповна сискәнеп, уңайсызланып китте. Өчесе дә шактый сүзсез тордылар. Менә шул вакыйгадан соң аларның болай да бик якын булмаган аралары тагын да ерагайды. Һәрвакыт туңып йөргәнгә, язын-көзен шул мамык шәлен ташламас, шаяруны аңламас, үтә җитди кеше иде Лэлэ Зариповна. Бервакыт уен-көлке сөйләшмәс ул, әйтсә, сүзен җайсыз итеп, кешенең хәтере калырлык итеп әйтер. Инде утызның теге ягына чыгып та, үзенең оясын кора алмаган коллегасын кызганып та куя Зоя Ивановна. Нигә дип бу табигать Лэлэ Зариповнадан җан җылысын кызганган икән дип карый ул. Аның зәһәр теленнән шикләнеп ничек тә читтәрәк йөрергә тырыша.

Шуның өчен дә Фәһимә кереп класс җитәкчесен сорагач, бик иркенләп сөйләшергә яраткан укытучы, аның дәрестә икәнен генә әйтте дә эшен дәвам иттерде. Фәһимә көтәргә булды, стенадагы түгәрәк сәгатькә күз төшереп алды да ишек төбендәге диванга килеп утырды. Гаҗәп ялыктыргыч озын минутлар иде бу. Фәһимә, булачак сөйләшүне уйлап, янадан борчылып утырмас өчен, игътибарын нәрсә туры килсә шуңар юнәлтергә тырышты. Стенадагы расписание, төрле белдерүләр язылган, нинди‑дер графиклар сызылган кәгазьләргә күз төшерде. Класс журналларыннан буш‑ап калган шүрлекнең бүлемнәрен санап чыкты. Аннары Зоя Ивановнага текәлеп, аның ак чыраен, сары кашларын, чигәсендәге миңен, тарак белән бастырып куйган йомшак чәчләрен озак‑озак карап утырды. Зоя Ивановна сүзсез тора торганнардан түгел иде. Тикшереп утырган дәфтәреннән күзен алмый гына:

— Сезнең балагыз биредә укыймы әллә? — дип сорады.

— Әйе, Рөстәм Шабаевның әнисе булам. Тугызынчы «А»да укый.

Зоя Ивановна, башын борып, күзлеген маңгаена күтәрде дә күзләрен Фәһимәгә төбәде.

— И, җанкисәгем, сезмени инде ул Шабаева? — диде ул, бераз карап торгач. Аннары дәфтәрен читкә үк алып куйды һәм бөтен игътибарын Фәһимәгә юнәлтте.— Сезне бик көтәләр иде монда. Өйдә юк идегезмени соң?

— Командировкада булдым шул.

— Шул шул менә. Үзебез тегендә чабабыз, монда йөгерәбез, ә балабыз...

Зоя Ивановна өметсез кыяфәт белән кулын селтәп куйды. Бу хәл Фәһимәнең күңелендәге тәшвишне тагын да арттыра төште.

— Әйтегез, зинһар, ни булган соң Рөстәмгә? Нәрсә эшләде ул?

— Артык куркыныч бер нәрсә дә юк,— диде Зоя Ивановна, Фәһимәне юатырга теләп, ләкин шуның белән аны тагын да ныграк борчуга салды.

Ул арада звонок шалтырады. Бүлмәгә бер‑бер артлы укытучылар керә башлады. Өчпочмаклы линейкаларын, акбурларын күтәреп завуч Фатыйма керде. Ул таныш түгел хатынга күз төшереп алды да, исәнләшеп, кулындагы класс журналын шүрлеккә куярга узды. Зоя Ивановна бу юлы да дәшми кала алмады:

— Фатыйма Хәлиловна, Лэлэ Зариповна янына Шабаева килгән.

— Рөстәмнең әнисеменни? Әнә Лэлэ Зариповна үзе дә керде.

Фәһимә, ишеккә борылып карауга, мамык шәле астына китаплар кыстырган укытучыны күрде.

Класс житәкчесе Фәһимәне тынычрак урынга, завуч өстәле янына алып килде. Ана өстәл кырыннан урын бирде, үзе өстәл артына ук кереп утырды.

— Мәктәпкә килмисез, иптәш Шабаева. Улыгыз бик шәп укучылардан түгел бит, шуны беләсезме?

Нәрсә әйтсен Фәһимә. Рөстәмнең уртача гына укып барганын ул үзе дә белә. Ләкин улының тукып-тукып та башына берни керми торган өметсез бала булмыйча, күп нәрсәдән хәбәрдар, күп нәрсә белән кызыксынучан икәнен; теләгән нәрсәсен, бик тиз төшенеп, шуны аңлатып бирә белүен, тырышса башка балалар шикелле дүрткә-бишкә генә дә бара алуын күреп тора. Үзенең юлын табар әле, кирәген белә башлагач, алдына бер максат куйгач, тырышып укый башлар, дип үз-үзен юата иде ул. Күрәсең, ялгышкан Фәһимә. Артыграк ышанып ташлаган. Һәр анага үз баласы бик акыллы булып күренә. Ул да Рөстәмгә артыграк ышанган, артык ирек куйган, аның көннән-көн ялкаулана баруын күрмәгән. Әйе, ешрак килергә кирәк булган шул мәктәпкә. Өйләре дә каршыда гына бит әле, житмәсә.

— Балага вакыт житми шул, Ләлә Зариповна. Нихәл итәсең. Гаеп үземдә инде. Әле генә командировкадан кайтып кердем,— диде ул, шактый уңайсызланып һәм кызарып.— Икеләләре шулкадәр күпмени соң Рөстәмнең? Ул хәтта дәрескә дә йөрми башлаган. Иптәшләрен куып житүдән өметен өзгән микән әллә?

— Хәзергә икеләләре юк югын, аның дәрес калдыруына башка нәрсә сәбәп. Сезгә өегездә әйтмәделәрмени?

— Мин берни дә белмим әле.

Ләлә Зариповна класста булган хәлне кыска гына итеп сөйләп бирде: менә ничә көн инде тугызынчы «А» күч аерган корт оясына охшый. Әле комсомол жыелышы, әле класс жыелышы. Ә Рөстәм һаман мәктәпкә килми. Әтисе кайда яшидер, улының барлыгын да белми, ә Фәһимә малаеның бөтен тәрбиясен әбисенә ышанган. Менә нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты — укуының да рәте юк, ә башында әллә нинди юк нәрсәләр...

— Укучы мәктәптә укырга тиеш, белем алырга тиеш, шуннан башкасы тәртип бозуга гына китерә, шушы яшьтән, мәхәббәт дигән булып, хатлар язып йөрү берниндн рамкага сыймый торган эш. Без укучыларны ничек тә шул адымнан сакларга тиеш. Шулай түгелме?

— Гафу итегез, Ләлә Зариповна, мин педагог кеше түгел, шулай да...

— Тем более.

— Ләкин бу мәсьәләгә мин башкачарак карыйм.

— Мәсәлән...

— Мәсәләнме? Телибезме без, зурлар, теләмибезме, уңалты, унҗиде яшьлек укучыларда яратуның беренче тойгылары уяна башлый инде. Нишлисең бит, табигать. Ә без аннан куркабыз. Чөнки ул безнең тынычлыгыбызны боза, мәшәкатьләр тудыра, шикләнүләр уята. Ни өчен шулайдыр, без барыбыз да яшь кешедә туган бу яңа хиснең бары тик начар ягын гына уйлыйбыз. Ул-бу булмагае дип шикләнәбез, ышанмыйбыз, аларның күңелендә гел яктылык, сафлык, нәфислек кенә туган минутларын артык төпченүебез, шымчылануыбыз белән каралтабыз. Минемчә, андый ата-аналар үзләренең яшьлегендә булган хаталарын балалары кабатламасын дип хафаланалар. Бу хәлдән мәктәптә дә куркалар...

— Сез арттырып җибәрәсез,— диде Ләлә Зариповна, нервланып. Рольләрнең кинәт кенә алмашынуына, гаепле башын иеп тыңлап утырасы урынга, бәхәсләшеп китеп, класс житәкчесенең үзенә акыл өйрәтергә тотынган бу хатынга чынлап торып ачулана башлады.— Это уже слишком. Күренеп тора, сез балагызга теләсә нишләргә ирек куйгансыз.

— Мин аңа ышанам.

Бу бәхәснен очы-кыры күренми иде. Нинди генә педагоглар, меңләгән-миллионлаган ата-аналар гомерләре буе баш ваткан мәсьәләләрне кечкенә бүлмәдәге өч-дүрт укытучы гына хәл итәргә дә җыенмый иде, билгеле. Аннан соң Фәһимә әле генә юлдан кайткан, борчылган, арыган, шуның өстенә аның әле улын да күргәне юк. Бу хәлләрнен барысын да Рөстәмнең үз авызыннан ишетергә тели иде ул. Тик менә ничек итеп сүз башларга әле аның белән. Ана белән бала күп нәрсәләр турында сөйләшә, ләкин әлегә кадәр тормыш, мәхәббәт шикелле мәсьәләләргә кагылмыйлар иде. Бәлки алар ул вакытта Рөстәмне кызыксындырмагандыр. Әнисе дә улын кечкенәгә санаган, күрәсең. Һаман бала дип караган, шулай үсәр-үсәр дә көннәрдән бер көнне тормышның котылгысыз сорауларын көн тәртибенә куяр дип кем уйлаган аны. Әкрен-әкрен аңлата килгәндә дә яраган икән шул. Ә хәзер, әллә ничек, кинәт кенә шул турыда сүз башлавы кыен. Ә сөйләшергә бик кирәк. Вакыт җиткән генә түгел, бәлки соңга да калгандыр әле Фәһимә. Бик каты тиргәп ташларга, дәрес калдырып йөргәне өчен үпкәләргә дә мөмкин. Шулай итеп, аны иртәгесен үк мәктәпкә дә кайтарырга булыр иде. Тик ул вакытта баланың күңелен үзеннән биздерәсеңне көт тә тор. Кеше, бигрәк тә яшь чакта, көчләп кушканны бер дә күтәрә алмый шул. Ул мең төрле йозаклар белән бикләнер һәм беркайчан да аның күңеленә ачкыч таба алмассың. Баланың ни уйлаганын, ни белән яшәгәнен я бөтенләй белмәссең, я булмаса ул ерактан, бик соңга калып, икенче-өченче кешеләр аркылы гына ишетелер. Шунда инде бик авыр, бик үкенечле булыр. Ярый ла син шунда үз гаебеңне аңласаң! Акыл белән уйлап, балаңа якынаю чараларын эзләсәң. Таба алсаң. Ә бит кешеләр, кызып китеп ярсыганда, каршыдагы киртәләрне көч белән алырга тырышучан булалар. Бик иплән кенә, сакланып кына орынырга кирәк булган күңел кылларын тарталар, йолкалар, өзгәләп бетерәләр.

— Юк, җыелышлар җыеп, класс шаулатып кына хәл итәрлек мәсьәлә түгел шул бу, Ләлә Зариповна. Мәхәббәт мәсьәләсен бернинди программага да кертеп, бернинди регламентка да сыйдырып булмый. Көтмәгәндә, уйламаганда күңелне биләп ала да ул, тоташ утка сала. Шулай да матур итеп ярата белү, мәхәббәткә тугры булу, аның сафлыгына, бөеклегенә баш ию, аның көчсез бер колы булып калмау, ә аңа лаеклы булу шикелле тормыш хикмәтләрен укучыларга мәктәп стеналарында да төшендерергә кирәктер бәлки. Юкса, өйдә сөйләшмибез, мәктәптә аңлатмыйбыз, мәхәббәт турында язылган китапларны укудан тыябыз һәм, көннәрдән бер көнне, үзебез әле һаман балага санап йөргән улыбыз я кызыбыз беренче тапкыр шул хисләр иркендә калгач, ни эшләргә дә белмибез. Әнә Рөстәм белән дә нәкъ шундый хәл.

Фәһимә Ләлә Зариповна белән бер сәгатькә якын сөйләшеп утырды. Әмма алар бу мәсьәләдә капма-каршы уйлый торган ике кеше булып чыктылар.

Рөстәм әле дә кайтмаган. Ул булганда өй эче тулып, җанга рәхәт бер тынычлык биреп тора иде. Ә хәзер әнә ике бүлмәнең икесе дә тыптын. Хәтта Хәдичә әбинең кыштырдап йөрүе дә боза алмый бу тынлыкны. Почмакларга инде эңгер-меңгер кергән. Тәрәзә тирәләрендә генә кышкы кичнең саран яктылыгы сирпелеп тора. Ул болай да моңсу бүлмәне тагын да күңелсезләндереп, ятимләндереп җибәргән.

Фәһимә керә-керешкә утны кабызып куйды. Өстен салып, әнисе янына кухняга чыкты.

— Мин киткәч Рөстәм гел шулай озак йөрдеме соң, әнием?

Хәдичә әби ничә сәгатьтән бирле ут өстендә торган ашын сосып, кызы алдына куйды. Тозын-борычын якынрак китерде.

— Әйтсәм әйтим инде, кызым, безнең Рөстәм эшкә керәм дип йөри бит әле ул. Ни әйттем үзенә, әниең кайтканчы түз, дидем. Юк бит, тыңлыймыни синең сүзеңне хәзерге яшьләр. Эш эзлим дип чыга да китә, чыга да китә. Син аша, аша. Кайтып житәр әле менә, күрерсең.

Мөслимнән чыкканнан бирле авызына ризык капканы юк иде Фәһимәнең. Әмма тамагына аш үтмәде. Залга чыгып, тәрәзәдән карап торды. Әле караңгы да төшеп житмәгән, күк йөзендә инде йолдызлар кабынган. Кешеләр өйләренә ашыгалар. Ә бала-чага һаман урамда. Әйтерсең лә, аларга көн житми. Ишек алдына ясалган өстәл өсте хәтле генә шугалакта этешә-төртешә тимераяк шуалар. Әле кайчан гына аның Рөстәме дә итәкләре бозга катып кайтып керә иде бит. Итек эчләренә оеш-оеш кар тулган булыр иде. Соңыннан радиаторга әле аркасын, әле аякларын терәп бик озак жылыныр иде. Суык тимәсә дә тими икән бу бала-чагага. Ауный-тәгәри шулай үсеп кенә торалар. Рөстәмнең дә кечкенә вакыты әле кичә генә кебек иде. Ә никадәр гомер үткән.

Фәһимә, калын пәрдәләрне тартып, тәрәзәне томалап куйды да, эш бүлмәсенә кереп, өстәл артына барып утырды. Терсәкләрен өстәлгә куеп, башын тотты. Күзләрен йомды. Бер мәлгә онытылып китте, күңеленә һичнинди уй килмәде. Аннан, кинәт кенә кузгалып, китап шкафыннан бер төргәк алды. Газетага чорнап, тасма белән урталай бәйләп куйган бу төргәктә аның яшь вакыттан ук язып килгән көндәлекләре иде. Биредә аның тормышы, язмышы, беркемгә дә әйтергә кыймаган серләре. Әле институтта чакта ук язып барган көндәлеген ул Фәйзи белән кавышкач та дәвам итте. Бигрәк тә Рөстәм тугач, бар ваклыкларына кадәр язып барды. Кайчан консультациягә алып барган, анда ни әйткәннәр, улы ничә килога арткан, кайчан көлә башлаган, ничә айдан теше чыккан, утыра башлаган, ничек үрмәләп киткән. Барысы да, барысы да теркәлеп барган. Соңыннан, сәламәтлек саклау министрлыгына эшкә күчеп, командировкаларга йөри башлагач, көндәлекне язу түгел, ачып та карый алмый башлады Фәһимә. Кызганыч, нигә дип менә шушы көнгә кадәр дәвам иттермәде икән ул аны. Никадәр шатлыклар, борчулар баштан үткән. Күбесе инде онытылып та беткән. 1951 елның февраль аенда язылган битләр бу көндәлекнең иң куанычлы урыннары булган икән. Рөстәм туган ай ул. Аларның көтеп алган куанычлары дөньяга килгән көн. Бу юлларның күбесен алар икесе бергә утырып яза торганнар иде. Фәйзи әйтеп тора, Фәһимә яза. Көлә-көлә, Рөстәмнең берәр кызык ягын язып куялар. Бу көндәлекне алар бергәләп укырга да яраталар иде. Әйе, әйбәт иде ул, 1951 ел... Ә монысы менә 1959 елның нәкъ июнь башы. Кара, никадәр вакыт үткән. Исәлекләр дә көн белән төн шикелле капма-каршы. Берсеннән сафлык, яктылык бөркелә, ә икенчесе... икенчесен укыгач, күңелне кургаш сыман авыр уйлар баса, күрәсең, шуңадыр, Фәһимәнең йөзе тагы караңгылана. Бу битләрне тизрәк ябып куярга ашыга ул, икенчеләрен ача. Тик әлеге күңелсез уйлардан тиз генә арыну мөмкин түгел, алар аның күңелен бимазалап, онытылмыйча, шактый вакыт азаплый...

Ул елны Рөстәм беренче классны гына тәмамлаган, футбол тубыдай тыгыз тәнле, йоп-йомры бер малай иде әле. Әтисе алардан чыгып киткәндә, уенда калды. Өйдә булган хәлне урамнан, бөтен нәрсәләрдән хәбәрдар булып торучы иптәш малайларыннан ишетеп керде. Әнисенең, бүлмә ишегенә сөялгән көе, тирән уйларга чумып торуын күргәч, янына барырга кыймады, кухняга, әбисе янына керде.

— Әбием, әти бездән китте, әйеме? — дип сорады ул, ни өчендер пышылдап. — Ул безгә бөтенләй кайтмыймы инде?

Малайның күзендә яшь тә юк, борчылу да сизелми, бары тик аптырау, балаларча беркатлы гаҗәпләнү генә күренә иде. Күрәсең, семья фажигасен ул әле аңламый. Тормышның шундый катлаулы мәсьәләләрен чишәргә бик кечкенә иде шул әле бу малай. Әбисенең генә эчкә

баткан керфексез күзләреннән яшь килә. Ул аларны яулык чите белән сөртеп ала да жылы учы белән онығының башыннан сыйпый.

— Ул юньсезнең киткәне хәерле, балам,— ди әбисе, йомшак кына итеп.— Бер дә курыкма, кем-хур булмабыз әле, анаң гына сау булсын.

— Юк, мин курыкмыйм,— ди Рөстәм. Ул үзенең әбисен юатырга теләгән була,— әсин елама, мин зур үскәч, сиңа күчтәнәч алып кайтырмын. Әтием кебек ташлап китмәм мин сине, яме, әбием, яме.

— Ярар, ярар, балакаем. Бар уйнарга чык. Иптәшләрең янына.

Рөстәм әкрен генә ишеккә таба килә, әле һаман бер урында басып торган әнисенә карап ала, аннары яңадан әбисе янына керә.

— Әбием, әтием бездән нигә китте? Безне яратмый ул, әйеме?

— Кечкенә әле син, балам, үскәч аңларсың,— диде әбисе. Оныгына бер алма тоттырды да ишектән чыгарып жибәрде.

Боларның берсен дә Фәһимә күрмәде дә, ишетмәде дә. Бу минутта берәр нәрсә турында уйлаудан гажиз иде ул. Ник шунда аяк астында жир убылып төшми, баскан урыныннан кузгалмас, аңа хәзер бар да бер...

Ә тормыш көйләнә икән ул. Дөньядан югалып кына калмаска, үзүзеңне кулга алырга гына кирәк икән. Әнә бит нинди юллар язылган. Дөрес, анда әле йөрәк сызлавы сизелеп тора, шулай да яктыга өмет, үзен нык тотарга тырышу күренә.

Фәйзи чыгып киткәннән соң Фәһимә байтак вакытлар көндәлегенә кагылмаган икән. Тоташ бер ел. Бу ел эчендә ниләр генә булмагандыр? Ялгыз калган хатын башыннан нинди генә уйлар кичмәгәндер? Язылып куелса, хәзер укып каравы кызык булыр иде. Хәер, борчылуга, күңел төшенкелегенә ирек бирмәс өчен, ул вакытта Фәһимә тәүлекнең бер генә сәгатен дә буш калдырмаска тырышты. Эшкә чумып үтте аның көннәре. Арып-талып йокыга яткач, саташулы төшләр белән ватылып торуга, тагын эшкә чыгып йөгерде. Шулай үз-үзенә тын алырга да ирек бирмичә яшәде ул елларда.

Ә бер елдан көндәлек дәфтәренә яңа юллар язылды.

«**1960 ел. 5 апрель.** Быел кыш жылы һәм юеш булды. Анысы ярады әле. Юкса, кышкы пальтомны яңартырга вакыт бик житкән иде. Кыш буена бер тапкыр да кияргә туры килмәде. Язгы-көзге пальтодан чыктым. Бер шәһәрдә яшәгән көндәш алдында сынатырга ярыймы соң. Хәер, мин аны бер генә тапкыр күрдем. Әрсезләнеп өемә килеп кергән һәм ярты сәгать эчендә минс бәхетсез иткән, Рөстәмне ятим калдырган кичендә. Әле ярый, шуннан соң беркайчан да кара-каршы очрашмадык. Бик яшь икән, чибәр икән диган сүзләр генә ишеттерделәр. Булса булыр. Ә мин... мин дә аннан ким түгел икәнемне исбатлап яшәргә тиеш бу дөньяда. Киләсе кышка бик яхшы пальто житкерермен инде. Жәйге отпускамны алгач, әни белән Рөстәмне авылга жибәрермен. Рөстәм таза булып, тере малай булып үсеп килә. Әтисенә охшар, караган саен бәхетсезлегемне исемә төшереп торыр микән дип уйлый идем. Үскән саен үзгәрә бара. Әнием әйтә, бабасына охшаган, ди. Шунысы яхшы — сәламәт булып үсә. Тик кечкенәдән күзлек кия башлавы гына эчне пошыра. Ятып укырга яраткан шул, вакытында искәртеп калып булмады. Әле миңа көннәр матурланып китте. Кыш буена кояш йөзен бер күрергә тилмергән идек, апрель башыннан тотынды кыздырырга — урам тулы су ага. Малайны һич өйдә тотасың юк. Карап кына тормасаң, чыгып йөгерә дә, сәгать үтүгә, баштанаяк суга манчылып кайта. Дәрес әзерләтүләре дә кыенлашты. Бөтенесен унбиш-егерме минутта әвәләп ташлый. Я әбисе, я мин янына утырып, итәгеннән тартып торырга туры килә. Менә бүген дә Рөстәмгә дәрес карарга куштым, ә үзем, янына утырып, китап укырга тотындым. Алай да күңеле әллә кайда йөри малайның. Я ишек алдына төшкән күгәрченнәргә карап тора, ул да булмаса, минем китапка күз төшереп ала. Бу кадәр атак булырсың

икән, дим эчемнән генә. Ул да шулай, бирелеп бер нәрсәне эшли алмас иде.

— Әнием,— ди Рөстәм, дәфтәрдән башын күтәрми генә,— яныма утырсаң, я әбием утырса, минем хисабым тиз чыга. Нигә шулай икән ул?

— Як-ягына каранмаганга.

— Класста да шулай булсын иде ул.

— Ә син класста да янында без утырабыз дип уйла.

— Уйлыйм да мин...

— Я, Рөстәм, тагын юк-барга күңел бирә башладың. Эшеңне кара.

— Әнием, сез гел минем янда утырыгыз, яме.

— Ярый, ярый.

Дөресен генә әйткәндә, мин үзем дә шулай утырырга бик риза. Бу минем иң бәхетле минутларым. Өйдә тыныч. Борчып торучы кеше юк. Рәхәт. Янымда иң якын кешем — балам утыра. Мин аның тән җылысын тоеп торам, тын алуларын ишетәм. Ул минеке, бары тик үземнеке генә. Дөньяда берни белән дә алыштырып булмый торган зур бәхетем ул минем. Вакыт-вакыт әллә ни була үземә. Шулай утырганда Рөстәмне кысып-кысып сөясем, алма күк битләреннән тыным беткәнче суырып үбәсем килә. Үзем дә беләм, әни кешенең түндырмыйча да, көйдермичә дә һаман бертөрле җылытып торган, күңелгә тынычлык биргән сабыр, акыллы ратуы түгел бу. Шуңар күрә дә мин Рөстәмне борчымыйм, эшеннән бүлдермим, күңелемнең ярсып-дулап чапкан аттай ашкынуын берәр эш белән мавыгып, сүрелдерергә тырышам.

**1 Май.** Бәйрәм көн. Кояш кыздыра. Аз гына җил дә бар. Рөстәм белән җитәкләшеп демонстрациядә үттек. Улым арыр, туяр, кайтырга кыстый башлар дип курыккан идем. Кая ул! Суга чумган балык шикелле. Кольцодан узганда, кулымнан тартып, колоннаның читенә алып чыкты.

— Әнә, Хәсән абый. Безнең мәктәптә укыта ул,— диде ул кулын артка куеп, юл читеннән колоннага карап торган бер кешегә күрсәтеп.

Чандыр гына буйлы, ябыграк аксыл йөзле бу кешенең үзебезнең ишек алдында торган укытучы икәнен белә идем. Тик ничектер туктап сөйләшергә, танышырга туры килмәгәнгә, очрашканда бер-беребез белән исәнләшми идек. Һәм бу хәлдән мин шактый уңайсызлана идем. Көн саен дип әйтерлек очрашкан кешенең күзенә карап, дәшми киту әллә ничегрәк. Исемен дә белмәгән кеше белән исәнләшеп үтүе дә сәер. Күрешергә, танышырга сәбәп тә юк иде. Әле ярый, балалар бар дөньяда. Кермәгән ишекләре, күрмәгән кешеләре, белмәгән нәрсәләре юк үзләренең. Рөстәм дә күршебез белән танышып алган.

Без күрештек. Мин аның кайнар, коры кулын кыстым. Әле кояш нуры тимәгән текә маңгаена, җилдә сибелеп торган кара чәчләренә карадым. Әллә ни сөйләшер сүз дә юк иде. Бер-ике авыз сүз алышкач, икебез дә уңайсызланып, тынып калдык. Әле дә ярый, Рөстәм яныбызда. Бу хәлдән ул коткарды.

— Хәсән абый, әйдәгез безнең белән,— диде ул.

Күршебез карышмады. Күрәсең, аның өчен көнне кайда булса да, кем белән булса да үткәрү барыбер иде. Без, инде шактый алга узган колоннабызны куып, адымнарны кызулаттык.

Гоголь урамы чатына житкәч, шактый озак туктап тордык. Кайсыдыр бер заводның йөк машинасына төялгән тынлы оркестр «Манчжурия сопкаларында» дигән маршны уйнап җибәрде. Хәсән мине танцыга чакырды. Ничә еллардан соң беренче тапкыр онытылып, кыз чагымдагыдай кинәнеп биедем мин бүген. Дөньяның бүгенгедәй шатлыклары минем өчен инде үткән, онытылган, яңадан кайтмастыр дип йөри идем. Кара син аны, мин дә әле очып-очып әйләнә алам икән, рәхәт бер моңга буйсынып тирбәлгән чагым әле минем дә онытылмаган икән.

Бер рәхәтнең бер михнәте була, диләр. Без шулай биегән арада, Рөстәм каядыр китеп югалган. Хәсән белән икебез ике якка аерылып эзләргә тотындык. Ләкин кая ул, бу кадәр кеше арасында орчык буе малайны табып буламы соң! Әле генә кичергән шатлыкларым бер минут эчендә юкка чыкты. Рөстәмем аяк астында калып тапталыр, еракка китеп адашыр дигән коточкыч уйлар килде башыма. Бу хәтле ашкыну юньлегә буламы соң дип, баламны, дөньямны онытып, яшь кызлардай тилереп йөрүемә үземне тиргәп ташладым.

Шулай газапланып, анда кагылып, монда сугылып йөргәндә, Рөстәм үзе килеп кулымнан тотты. Үземне-үзем тыя алмыйча, аны пыр туздырып тирги башладым.

**26 июнь.** Бүген Рөстәмне пионер лагерена озаттым. Улымны беренче мәртәбә янымнан аерып җибәрүем. Бик кыен булды. Хәзер төнге сәгать унбер. Алар йоклыйдыр инде. Аккош күле буенда һава дымсу, кичләрен салкын була. Рөстәмнең йокысы тыныч түгел. Өстен ачып, туңып ятмаса ярар иде. Вожатыйга әйтеп җибәрәсем калган икән, кереп-кереп өстен ябып чыксын иде. Тизрәк якшәмбе генә җитсен, янына барып кайтырмын.

**5 сентябрь.** Бүген медиклар йортында кичә булачак. Профессор Галимовның алтмыш яше. Миңа да ике кешелек билет бирделәр. Барыргамы, юкмы? Барсаң, анда Фәйзи булыр инде. Хатыны белән килсә. Аның белән очрашсаң, күңел генә бозылып калыр. Инде төзәлә башлаган яралар яңадан кузгалыр, әрни башлар. Алар парлап йөргәндә, ялгыз каздай моңаеп барып керүең үзе бер уңайсыз. Юк, бармаска булдым мин бу кичәгә. Әзерләп куйган күлмәгемне шкафка кире элдем, туфлиларымны карават астына тондырдым. Үзем мендәргә барып капландым. Күңелем ярсый, йөрәгем сикерә, ә күземдә яшь юк. Күз кабакларымны ниндидер коры, эссе ялкын көйдерә сыман. Кипкән хәзер яшь. Күңел каткан. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, Рөстәм дә ачуны китереп утыра. Башта, урамнан эзләп алып кереп, көч-хәл белән дәреськә утырттык. Инде әйләнеп тә карарга өлгермәдем, эшләп бетердем дип, яныма килеп җиткән. Дәфтәренә карасам, исем китте. Шул хәтле пычрак, тәртипсез язылган юлларны күргәнем юк иде әле. Ә язуында юл саен ике-өч хата. Язын өйрәнгәннәрен дә онытып бетергән бит бу бала. Җәй буе китап тотып карамау бәласе инде. Тәмам ачуым чыкты:

— Бар, күземә күренмә, дәфтәреңне баштанаяк күчереп чык, шуннан соң килерсең яныма,— дип куып чыгардым.

— Бигрәк каты орынасың инде, Фәһимә, баланың күңеле болай да китек,— дип, әни яклашып йөри тагын.

Юк, бу кичтә, бу өйдә тынычлык булмас, ахры, миңа. Юкка бармадым мин ул кичәгә. Әз булса да ял итеп кайтыр идем. Юкса һаман эш тә эш... Тукта, нигә дип өйдә утырырга тиеш соң әле мин. Кичәдә Фәйзи булгангамы? Булса соң. Киенермен, ясанырмын да ял итеп барып керермен. Кемне югалтканын күреп, йөрәге әрнерлек булсын.

Каян башыма килгәндер, Хәсән белән барырга булдым мин ул кичәгә. Язын демонстрациядә танышканнан соң, без аның белән сөйләшеп йөри башладык. Ә Рөстәм белән алар бөтенләй дуслашып беттеләр.

Өенә кереп йөргәнем юк иде. Ә бүген ишегеннән барып кактым мин аның. Биленә күн алъяпкыч бәйләгән, җиңнәрен сызганган Хәсән ишек ачты. Бәйрәм күлмәкләремне киеп, муенсалар тагып басып торуымны күргәч, аптырап калды.

— Ничек керәсе иттегез, узыгыз, узыгыз,— дип, юл бирде ул миңа, шул арада үзе бүлмәнең утын кабызып җибәрде.— Гафу итегез, мин сезне көтмәгән идем, менә карточкалар эшләп азапланам.

— Мин шулай көтмәгәндә генә килеп керергә яратам инде,— дим, ә үзем уңайсызланам. Инде нәрсә әйтергә дә белмичә бүлмә эченә күз

йөртеп алам. Бердәнбер тәрәзә калын одеал белән капланган. Идән уртасындагы өстәлгә газета җәелеп, анда савыт-савыт су, проявителе, закрепителе дигәндәй тора. Кая карама, китаплар. Хәер, китаптан башка нәрсә юк иде дә бугай ул бүлмәдә.

— Мин бит сезне алырга кердем, бүген бездә бәйрәм, профессор Галимовның юбилее. Әйдәгез, медиклар йортына барып кайтабыз.

Ул ничектер кызарып китте. Аннан соң күземә карап алды да:

— Хәзер алайса,— диде.— Сез менә шуларны карый торыгыз, мин хәзер.

Мин кибәргә куйган рәсемнәрне караштырган арада, ул җете ак күлмәктән, кара костюмнан яныма килеп басты.

— Мин әзер,— диде Хәсән, текә маңгаена ишелеп төшкән чәчләрен тарый-тарый.

Без киттек. Юлда мин аңар Рөстәмнән зарланып алдым. Җәен тәмам чыгырдан чыкты малай, урамнан биздереп булмый, дәресләргә күңел бирми, дидем. Ул ешрак күзәтергә, режим билгеләргә, әзерләгән дәресләрен кабатлап сорарга киңәш бирде.

Мин бик беләм дә бит боларны, шулай эшләргә дә тырышып карыйм. Укулар башланыр алдыннан, икәү утырып, режимын да төзегән идек. Дөресен генә әйткәндә, улым белән чын-чынлап утырырга вакытым җитми. Шәһәр Советы Казанка буенда яңа йортлар салуны планлаштыра. Шуның урынын-җирен, һавасын-суын дигәндәй, санитария ягыннан өйрәнеп, тикшереп карарга һәм нәтиҗәсен тиз көндә өлгертеп бирергә кушалар. Әле шул эш артыннан йөргән көннәрем. Теләсәм, теләмәсәм дә, Рөстәмнең бөтен тәрбиясен әни өстенә салырга туры килә. Әни тынычландыра ул, кайгырма, сезне үстердем бит әле. Бер дә начар булмадыгыз. Абыең Мәскәүдә эшли, үзең врач, ди. Әни хаклыдыр, бәлки. Ә шулай да... Әй, сиздерә дә соң бу әти кешенең юклыгы! Берең өлгермәгәндә икенчең бала белән булыр идең. Син күреп житкермәгән, син әйтеп бетермәгәне аның җилкәсенә төшәр иде. Менә нәрсәдә икән ул ялгыз көе бала үстерүнең авырлыгы.

**5 нче ноябрь.** Рөстәмнәр мәктәбендә тантана. Мине дә чакырдылар. Өченче класс укучыларын бүген пионерга алалар. Улым да, мин дә бу көнне түземсезләнеп көткән идек. Менә инде ул, иптәшләре белән бер сафка тезелеп, басып тора. Барысы бер авыздан алар тантаналы вәгъдәнең сүзләрен кабатлыйлар. Андый минутларны ни өчендер тыныч кына үткәреп булмый. Күземә яшь килә. Уңайсызланып, халык арасыннан чыгам һәм укытучылар бүлмәсенә керәм. Анда кызу бәхәс бара. Ата-аналар комитетында эшләүчеләр нәрсә беләндер килешә алмыйлар. Яшь кенә бер ханым, бик борчылып һәм ачуланып, каршында утырган ир кешегә:

— Әйттем бит, ничә тапкыр әйттем. Тыңламадыгыз. Я, һәр балага шунда берәр плитка шоколад тоттырсак, начар булыр идемени? Менә дигән бәйрәм булыр иде ул аларга, гомерләрендә исләрендә калыр иде,— ди.

— Бик начар булыр иде, ханым,— ди ир кеше, тыныч кына итеп. Хатынның кызып-кызып сөйләвенә әллә ни исе китмичә, үзенекен исбатларга тырыша.— Дөрес, балалар тәмле-томлыны яраталар, ләкин бит аны кунак өстәле артында бирү яхшы. Ә бүгенге көн аларның хәтерендә башка як белән сакланырга тиеш. Андый әйберләр биреп, пионерга керү көненең политик әһәмиятен киметмик әле. Мин моңа башта ук каршы булдым, хәзер дә каршы.

Икенче бер ханым, аны бүлдереп:

— Мин сезнең белән риза түгел. Әйтегез әле шуны, өйгә кайткач, балагызга сез бер җылы сүз дә әйтмәссезмени? Аның пионерга кергән көнен бәйрәм итеп, берәр әйбер алып бирмәссезмени? — ди.

— Өйдә мин ни генә эшләсәм дә, ул өйдә, семьяда эшләнә. Бәлки

мин бу көнне башкачарак та билгеләп үтәрмен. Ә мәктәп стенасында бу вакыйганың революцион романтикасын күтәрергә кирәк.

Хәрби кешеләр сыман пөхтә киемле, төз гәүдәле, тыныч йөзле бу кешенең сүзләре мине үзенә тартты. Бөтен жаным-тәнем белән аның яклы булып, аның сүзен җөпләп, үзем дә берәр сүз әйтим дип авыз ачкан идем, ул тагын сөйләп китте:

— Үземнең комсомолга кергән көнемне хәтерлим әле мин. Әле минә кичә генә булган шикелле. Шоколадның исемен дә ишеткәнем юк иде ул вакытта. Бөтен Идел буен кырып салган ачлыктан яңа гына тернәкләнеп килә идек. 1922 елның 7 ноябрь көне иде бу. Без ул көнне, факеллар яндырып, урамнарда йөрдек. Туганнар кабере янында Ватаныбызга турылыклы булырга ант иттек.

Мин аны тыңлыйм һәм спорт залында иптәшләре арасында басып торган улымны күз алдыма китерәм. Гарнизоннан килгән чал чәчле офицер аларга кызыл галстуклар бәйләде. Ул үзе дә дулкынлана иде булса кирәк. Дивизияләрне атакага күтәргәндә калтырамаган тавышы, калтыранып, карлыгып чыга иде. Ә балалар аның бөтен күкрәген тутырып торган орденнарыннан күзләрен ала алмыйлар. Әйе, мин моны әле генә үзем күреп кердем. Соныннан, өйгә кайткач та, бу турыда никадәр сүз булды безнең. Офицердан ишеткән сугыш эпизодларын улым әле миңа, әле әбисенә килеп сөйли. Ә ятар алдыннан галстугын ничек кадерләп төреп куйды ул! Ялгышасыз, ханымнар! Шоколадны түгел, батырлык үрнәкләрен хәтерләрендә ныграк саклар безнең улларыбыз.

Фәһимә дәфтәренең берничә битен берьюлы ачты. Ашыгып-ашыгып язылган берничә юлны укып алды. «Бүген класс җыелышында булдык. Медведев фамилияле малай гел дәрестән качып китә икән. Бөтен укучылар шуннан зарлана. Аны тиргибез, ә ул, тиргәгән саен, киреләнә, ди класс житәкчесе. Бүген мин аңа иртән үк кисәтеп куйдым: «Саша, әгәр сиңа китәргә бик кирәк икән, миннән сора. Мин сине җибәрермен»,— дип әйттем ди». Малай укытучысын сынарга теләгән, ахры, бер тәнәфестә килеп сораган. Укытучы да сүзендә торган, китәргә рөхсәт биргән. Ә малай китмәгән.

Баланы өйрәтергә, житешмәгән якларын күрсәтеп торырга кирәк һәм, шуның белән бергә, аңа ышанырга да кирәк. Юкса, ул киреләнә башлый. Медведев та алай тиз генә төзәлеп китә алмас, ләкин класс житәкчесе аның кирәкле кылын табып алган иде. Бәлки яхшы нәтиҗәсе булыр».

Фәһимә тагын берничә битне ачты. Таныш фамилияне очратып туктады. «Медведев турында Рөстәмнән сораган идем, ул инде дәрес калдырмый. Без аны редколлегиягә сайладык, ди».

Минә тагын Рөстәм турында. Тоташтан берничә бит язылган. Монысы инде алтмыш бишенче ел. Рөстәм жиденче класста укыган чак.

**15 февраль.** Рөстәм еш кына әтисен искә ала. Ә минем ул турыда ишетәсем дә килми. Малай кеше атага зар була, күрәсең. Ускән саен аңа ата сүзе, ата кулы кирәктер шул. Ә мин хәтта аның Казанда яшәвен дә улымнан яшерәм. Улымның бары тик минеке генә булуын, хисләрен, уйларын бары тик минем белән генә бүлешүен, мине генә яратуын телим. Белеп торам, минә дигән эгоистлык чире, ләкин ни эшлим. Фәйзигә булган үпкәмне еллар гына сүндерә алмады, күрәсең. Хәер, әтисенең улын бик күрәсе килеп тормыйдыр әле. Киткәннән бирле бер килеп чыкканы да юк. Баштарак акча сала иде. Анысын үзем алмадым. Тормышның очын-очка ялгап барам, артык мохтаҗлыгым юк иде. Сер сынатасым да килмәде. Рөстәмгә аның акчасы түгел, үзе кирәк. Ә безнең юллар киселгән инде. Аның кире кайтасы юк. Һәм мин дә аны гафу итмәячәкмен.

**8 июнь.** Кичәле-бүгенле безнең өйдә кара кайгы. Бу турыда мин тыныч кына яза да алмам әле. Ләкин миңа шулай кәгазь битендә үз-үзем белән сөйләшергә гадәтләнеп киттем. Кайчан, ничек булса да эчеңне бушатырга кирәк бит. Менә әле дә мин язып утырам, ә янымда, одеалын баштанаяк бөркәнеп, Рөстәм йоклап ята. Әнием әллә ничә кереп әйтте инде, утны сүндер, балага йокларга ирек бирмисең, дип. Ә мин белеп торам, колак төбендә бомба шартлатсаң да, уянасы юк аның. Төне буе йокламаган, ашамаган бала тәмам хәлдән тайган, талчыккан.

Беркөн икеле алып кайтканы өчен кичен шактый кыздырган идем малайны. Иртән үзем эшкә киткәч тә, мин сезнең белән тормыйм, әтине эзләп табам дип, чыгып киткән. Әнием башта аңа ышанмаган. Мин дә чынга алмадым. Көне буе көттек малайны, кич җитте, кайтмады. Төне буе көттек. Аптырагач, кереп Хәсәнне уяттым. Ярый әле ул бар күршедә. Бөтен киңәшем, табышым шунда. Шәһәрнең бөтен милиция бүлекләренә шалтыратып чыкты ул. Үзем берни эшли алмыйм, каушап калдым. Әлегә кадәр күргән хәсрәтләрем хәсрәт булмаган икән.

Бу төнне без йокламадык. Шулай керфек тә какмаган көе Рөстәмнең мәктәбенә йөгердем. Укытучылар бүлмәсенең ишеген ачуга, каршыма Хәсән чыкты.

— Рөстәм класста утыра. Сез хәзер аңа күренмәгез. Өйдә дә берни булмаган кебек тотыгыз үзегезне. Мин үзем аның белән сөйләшермен,— диде.

Мин эшкә киттем. Әмма башым тубал кебек, бөтен гәүдәм калтырый. Кичкә хәтле ничек түзәргә дә, ничек итеп Рөстәм белән тыныч кына сөйләшергә? Булдыра алмам, ахры, мин моны. Я тагын тиргәп ташлармын дип, өйгә юри озак кайтмый йөрдем. Тик юкка булган. Рөстәм төш вакытында өйгә кайткан да, кискән агач кебек, урынына ауган. Шуннан бирле кыймылдап та карамый, ди әнием.

— Әтине очратмаммы дип, көне буе трамвайда йөрдем. Арыгач, вокзалга төшеп, эскәмиядә йокладым. Иртә белән өйгә кайтасым килгән иде, әнидән куркытым, аннары мәктәпкә киттем,— дип сөйләгән Рөстәм әбисенә.— И, әбием, өйсез булудан да читене юк икән, моннан соң инде беркая да китмәм,— дип әйтә ди.

И, бала, бала, тагын нинди хәсрәтләргә салырсың икән башларымны?»

Фәһимә, авыр сулап, көндәлекне ябып куя. Үткән көннәрнең истәлегенә бирелеп утыру кызык та, моңсу да, йөрәк өзгеч авыр да булды аңа. Яшьлегенең кабатланмас көннәре үзенең ялгышлары, әрнүләре, шатлыклары — бөтенесе белән аның күз алдыннан үтте. Көндәлек дәфтәренең соңгы битен япкач кына ул чынбарлыкка кайткандай булды. Күтәрелеп сәгатькә карады. Кичке сигез тулып килә икән инде. Фәһимәнең йөрәгенә жу итеп китте. Рөстәмне болай өйдә көтеп утырырга ярамас, ни дә булса эшләргә кирәк.

Ул әле ни эшләргә кирәген дә уйлап җиткермичә, кабаланып, өстенә киенә башлады. Үзенең мәңгелек почмагы — кухнядан Хәдичә әби килеп чыкты. Ул инде баядан бирле Рөстәмнең кайтмавын кызының исенә төшерергә уйласа да, аның, бик бирелеп, нидер укуын күргәч, сүз дәшергә кыймый тора иде.

— Кызым, бер-бер җирдән эзлик мәллә? Бер дә болай озак йөрми ие кана,— дип куйды ул юаш тавыш белән. Оныгының әнисе өйдә юк чагында шулай югалып торуына ул үзен гаепле саный иде булса кирәк.

Урамга чыгып, бераз салкын һавада торгач, Фәһимә уй-фикер йөртерлек хәлгә килгән иде инде. Ләкин, хәзер чыгып, кая барсын соң ул? Менә шушы караңгы төндә, зур шәһәрнең миллионга якын халкы арасыннан Рөстәмне ничек эзләп тапсын? Әй, шул телефонның булмавы! Ул таныш-белешләренә, Рөстәмнең иптәшләренә шалтыратып карар

иде. Һич югында, милиция бүлекләреннән сорашыр иде. Ә менә хәзер ул, жиде юл чатында баскан көе, улының берәр яктан килеп чыкканын көтеп тора. Күпме торыр соң ул басып? Гомумән, Рөстәмнең гәүдәсен алга сузыбрак бу юллардан кайтып килүен күрә алырмы ул? Бер-бер хәл булды микән үзенә? Исән-сау микән баланың башлары? Фәһимә андый ямьсез уйларны күңеленә китермәскә тырыша. Ләкин бу курку, карак мәче шикелле, посып кына килә дә, күңелне тырный башлый. Никадәр тырышса да, котыла алмый ул алардан.

Фәһимәнең инде аяклары туңа башлады. Аркасына чымырдап салкын йөгерде. Әз булса да жылыну өчен, бераз йөреп килде. Әмма ерак барырга курыкты. Борылган арада Рөстәм килеп чыгар да өйгә кереп китәр, күрми калырмын дип уйлады. Урамда инде халык та сирәгәя башлады. Вакыт бик соң, күрәсең. Акылы аны өйгә чакыра, урамда басып торудан файда юк, кер, чишен, йөрәгеңә бик түзә алмасаң, тәрәзәннән карап утыр, ди. Ә күңеле биредә калырга өнди. Һәм ул аңа буйсына. Кышкы салкын инде җелекләренә төшсә дә, урамда кала.

Ниһаять, ул таныш шәүләне күреп ала. Аның йөрәге ешрак тибәргә тотына. Әнә ул инде якынлашып та килә. Янында бер ир дә бар. Анысы ике кулын да кесәсенә тыккан, пальто якаларын күтәреп куйган. Кулын болгый-болгый нидер сөйләп, яныннан килгән малайга йөзен борган. Менә алар тәрәзәдән төшкән ут яктысына килеп керделәр. Тукта, Хәсән ич бу. Кайда очраштылар икән? Әнә малай Фәһимәне күреп алды, ахры, сөйләвеннән кинәт туктап калды, адымнарын акрынайтты. Аннары, кинәт йөгереп, әнисе каршына килеп басты. Ул арада Хәсән дә килеп житте. Фәһимә көткән вакытта җен ачулары чыгып, менә шунда улы кайтып күзенә күренсә, бер тукмап алырдай булып тора иде. Рөстәм кайнар сулышы белән әнисенең күкрәгенә килеп капланугы, Фәһимәнең ачуы шунда ук таралды. Җыерылган кашлары язылып, йөзенә рәхәт бер елмаю таралды.

— Синең белән аерым сүз булыр, бар өйгә кер, әбиең көтә,— дип, Рөстәмне өйгә кертеп жибәрде ул.

— Син аңар бик ачуланма инде, Фәһимә. Миңа килгән иде ул. Сөйләшеп утыра торгач, вакыт үткәнен сизми калганбыз. Бик борчулы чагы аның. Берәр нәрсә уйлашырга кирәк булыр безгә.

Шуннан Фәһимә үзе командировкада йөргән арада булып үткән хәлләрне, икенче тапкыр, Хәсәннән ишетте.

## VII

Хәсән мәктәптә фототүгәрәк алып бара иде. Фото-лабораторияне ул үзе карап, осталарга үзе күрсәтеп, эшләтте. Биредә һәрнәрсә үз урынында, һәркайчан чисталык булыр. Чисталыкны һәр укучыдан таләп итә Хәсән. Аның бу жыйнаклыгы армиядә хезмәт иткәндә гадәт булып кергәнме, әллә, ялгыз торып, шулай өйрәнгәнме ул, һәрхәлдә, укучыларның да эленке-салынкы йөрүен яратмый, үзе дә һәрвакыт пөхтә киенгән, чиста итеп кырынган булыр.

Лабораториясендә аның һәркайчан укучылар булыр. Камчатканың вулканлы сопкалары, Көнчыгыш Себернең таш баганалары, Карелия урманнары, Кавказның биек тау болыннары турында тыңларга теләгән берсе килә аның янына. Укучыларның Хәсән абыйлары артыннан йөрүләре Ләлә Зариповнада канәгатьсезлек уята бугай. Бер вакыт шулай сүз арасыннан гына тәртгереп әйтеп куйганы бар:

— Укучылар һәртөрле фәнгә игътибар бирергә тиеш. Ә Хәсән Кәбирович шул географиясе һәм фотосы белән аларның вакытларын ала.

Ә балалар йөриләр шул түгәрәккә. Нихәл итәсең. Ерак җирләр романтикасы шулай кызыксындыра булса кирәк аларны. Әле бүген дә алар озаклап, фоторәсемнәрне кәгазьгә төшереп утырдылар.

Хәсән өенә кайтып килгәндә, ишек алдына керешли, Рөстәм белән очрашты.

— Кара, бик шәп булды әле, әйдә безгә кереп утырыйк,— диде укытучы, егеткә карышып торырга да урын калдырмыйча. Хәер, Рөстәм үзе дә карышып тормады. Ул туңган һәм арган иде. Бирегә ул шул Хәсән абыйсын очратмаммы дип килде дә бит. Әтисе яныннан киткәч, ул, кая барырга белмичә, урамда бик озак йөрде. Өйгә кайтасы килми иде аның. Мәктәпкә керү турында уйлап та карамады. Троллейбуска утырып, Ленин районына төшеп китте. Анда берничә заводның кадрлар бүлегенә кереп карады, әмма аңа уналтысы тулмаган кешене эшкә райисполкомнар аша гына алабыз дип әйттеләр. Шунда барып, махсус комиссиягә мөрәҗәгать итәргә киңәш бирделәр. Анда да кагылды малай. Комиссия дигәннәре атнага бер генә көн эшли икән. Ә бу атнаны инде аларның утырышы уздырылган. Кая гына барырга да белми йөргәндә, ул элек үзләре торган урамга килеп чыкты. Ишек алды түрендә, кар баскан агачлар арасында утырган йорт янына туктады. Кечкенәдән уйнап үскән, әле соңгы елларга кадәр яшәгән йорты иде ул аның. Чәчәкле пәрдә корылган әнә ул тәрәзәләр алар бүлмәсенеке иде. Хәзер анда малайга ят кешеләр яши. Бу ишек алдында торучылар алышынып беткән инде хәзер. Элекке танышларыннан сугышта хәбәрсез югалган улын әле һаман көтеп, адресын үзгәртергә куркып яшәүче ялгыз карчык та янәшә йорттагы Хәсән абыйсы гына калган. Хәсән абыйсының тәрәзәсендә ут юк. Кайда икән ул? Тиз кайтырмы икән? Ут алынмаган тәрәзәгә карап байтак торды малай. Көндез бераз җепшетеп алган аяк асты ярмаланып каткан иде. Кечкенә якалы юка пальто аша малайның аркасына суык йөгерде. Һәм эчкә төшеп калтырата башлаган суык, аны куып җибәргәндәй, урамга йөгертте. Шул вакытны ул кайтып килүче Хәсән абыйсын очратты.

Менә инде җылы өйдә. Укытучысы тиз генә чәй куеп җибәрде. Кухняга чыгып, йомырка куырып керде һәм малайны өстәл янына чакырды.

— Очравың әйбәт булды әле, менә бергәләп чәй эчеп алырбыз,— диде ул, Рөстәм алдына йомыркалы табаны этә төшебрәк.— Кайчакта бер үзең өчен аш-су әзерләп торасы килми дә берәр кафега чыгып китәсең. Ә бүген әллә нишләп анда барырга да теләк булмады.

— Арыгансыздыр,— диде Рөстәм, Хәсән абыйсының сүзен ялгап җибәрү өчен генә. Ул аның сөйләүдән туктавын теләми иде, туктаса сораштыра башлар, бер атнадан бирле инде үзәккә үткән хәлләрне тагын искә төшерер дип курка иде. Ни өчендер хәзер, шушы кечкенә, җылы һәм якты бүлмәгә килеп кергәч, күңеле тынычланып киткәндәй булган һәм аның шул тынычлыкны һич кенә дә бозасы килми иде. Малайның күңеләнгән сизепме, Хәсән үзе дә әлеге вакыйгаларга кагылырга ашыкмый.

— Арылгандыр шул. Бүген фототүгәрәк җыелды. Узган атнадагы походта төшергән рәсемнәрне эшләдек. Син дә барган идең бит әле анда?

Егет әйе дип башын какты.

— Аруын да ардыра. Шулай да укучылардан башка күңелсез миңа, Рөстәм. Беркемем дә юк бит. Ә кешесез тора алмыйм.

Рөстәм Хәсән абыйсына күтәрелеп карады. Малайга аның йөзе боегып киткәндәй тоелды. Сания апаның үлгәненә бик күптән бит инде, нигә өйләнми икән ул? Ә безнең әти менә, әни исән булуга да карамастан, икенче кешегә китә алган. Ләкин ул боларны әйтмәде. Эченнән генә уйлап куйды. Ә теленә аның үзе дә, Хәсән дә көтмәгән икенче сүзләр килде:

— Мин бүген әти янында булдым.

Хәсән зур кара күзләрен тутырып малайга карап алды.

— Эшкә урнаштырсын дип барган идем. Ә ул әллә нинди шунда — Рөстәм ни дип әйтергә белмичә, бераз дәшми торды да,— кызганыч кеше,— дип куйды.— Беләсезме, Хәсән абый, ул әле мин килгәнгә дә курыкты бугай. Сөйләшүе дә әллә ничек кенә. Менә мин сезнең белән рәхәтләнеп сөйләшеп утырам, ә аның янынннан китәсем генә килеп торды.

Хәсән Фәйзине аз белә иде. Сания белән бу йортка күчеп килгәч, бер ел үтүгә, Фәйзи инде семьясыннан китеп барды. Чибәр кеше, яхшы ата дип уйлый иде Хәсән аның турында. Бер-ике тапкыр юлда очрашып, сөйләшеп кайтканнары булды. Фәйзи семьясын ташлап киткән дип Саниясе кайтып әйткәч, Хәсән ышанмады, ә ул, баксаң, чын булып чыкты. Юк, бөтенләй белми иде ул Фәйзине. Шуңа күрә Рөстәмнең сүзенә кайтарып берни дә әйтә алмады. Бәлки әле малайның атасына карата җылы хисләре сүнеп тә җитмәгәндер, күңел түрендә йомылып ятадыр. Ялгыш кагылырсың да баланың күңелен рәнҗетерсең. Аннары ата белән бала мөнәсәбәтләренә кагылдырмый торган икенче бер сәбәбе дә бар Хәсәннең. Ул — аның Фәһимәгә булган хисләре. Фәһимә аны белә бугай инде. Белә, әмма җавап кына бирми. Хәсәнне ул якын итә. Шатлыгын, кайгысын бүлешә. Бары шул гына. Юк, этисе турында Рөстәмгә тегеләй дип тә, болай дип тә әйтмәде Хәсән. Ул сүзне Рөстәмнең үзенә кайтарып калдырды:

— Сиңа бит унҗиде яшь. Ә унҗиде яшьтә без инде сугышта идек. Күпме көч, күпме ихтыяр кирәк булды ул вакыттагы егетләргә. Аларның күбесе туган өйләренә әйләнеп кайта алмады. Фашистларга каршы көрәштә һәлак булды. Белсәң әгәр, шундый укыйсылары килә иде аларның. Һәркайсы җиңү көнен түземсезләнеп көтә, бик күбесе ВУЗларга керү турында хыяллана иде. Әнә шул кайтмый калганнар өчен дә, аларның хыялын тормышка ашыру өчен дә укырга кирәк иде сезнең кебекләргә. Эх, Рөстәм, Рөстәм, синең бит яшь вакытың, иң энергияле, дәртле чагың. Шуны бушка уздырсаң, никадәр күп нәрсә югалтасың бит, беләсеңме? Син уйлыйсыңдыр әле, укыганда ничек булса да ярый, эшләгәндә үземне күрсәтермен, дип. Ләкин бу ялкаулыктан килә. Сәләте булып та уртача гына укыган кешенең яхшы эшләвенә ышанмыйм мин. Андыйны күргәнем юк әле. «Ялкаулык — бәхетсезлекнең башы» дип дөрес әйткәннәр. Хәзер үзеңне ялкаулыкка өйрәтсәң, бер вакытта да бәхетле булмассың. Син әниеңнең бердәнбер баласы, бердәнбер шатлыгы дип әйтергә дә була. Синең бәхетсезлегеңне күрү аны гомерлек хәсрәткә салачак. Менә шуларның барысы турында да бер уйлап кара әле син, Рөстәм. Эшләп тә укырга мөмкин, билгеле. Тик хикмәт андамыни? Син менә үзеңнең мәктәбеңдә, үз иптәшләрең янында тәмамларга тиеш укуыңны.

Эш эзләп бераз ашыкмыйсың микән, Рөстәм. Гетеның бер акыллы фикере хәтердә калган: кеше уйлаган уен эш белән, эшләгән эшен уй белән сынап караса, ялгышмас, ялгышса да, дөрес юлга тиз басар, дигән ул. Менә син дә яхшылабрак уйлап кара әле, Рөстәм. Минемчә, сиңа урта мәктәпне тыныч кына тәмамларга кирәк. Аннан соң, телисең икән эшли бир. Иптәшләрең дә мәктәпкә кайтуыңны телиләр бит.

Хәсән, сүзеннән туктап, бераз уйланып утырды.

— Ә син аша, аша! — диде ул һәм яңадан бер сүз дәшмичә, озак кына уйланып утырды.

— Ә мәхәббәт дигәннәре шундый четерекле нәрсә инде ул. Ашыксаң — ялгышасың, сабыр итсәң — соңга каласың,— дип яңадан сүзен ялгап җибәрде ул, Рөстәмгә карап.— Беләсеңме, Рөстәм, синнән өчдүрт кенә яшькә олырак бер егет, моннан нәкъ чирек гасыр элек шулай гашыйк булган иде. Бөтен дөньяның нурга чумган җәй ае. Поп-йомры каз бәбкәләренең яшел үләнгә абынып йөргән вакытлары. Бакча буенда сәрби агачлары, тәрәзә төбендә яран гөлләре шау чәчәктә

утырган чак. Бөтен җирдән бәхетле бер сафлык бөркелеп тора. Ә көнбатышта инде бер атна канлы сугышлар бара. Кечкенә бер авыл аша әле яңа гына училищены тәмамлаган курсантларның фронтка китеп барулары. Иртәдән бирле маршта килгән яшь лейтенантларны командир әнә шул авылда ялга туктатты. Әлеге егет отделениесе урамга яңы белән салынган алты почмаклы йортның ишек алдына керде. Кара чәчен кыска итеп кискән, нәзек, озын буйлы яшүсмер кыз, өйдән чиләк белән су чыгарып, яшел үлән өстенә куйды. Чигүле озын сөлгене иңбашына салып, егетләрнең тузанланып беткән зур учларына чүмеч белән көмештәй саф су сала башлады. Ул шул кадәр оялчан иде, күтәрелеп карарга кыймыйча, башын түбән иеп кенә торды.

Күз керфекләренең дерелдәп китүеннән һәм бит алмаларына чыккан куе кызыллыктан бу табигать баласының тәмам каушап төшүе күренеп тора иде. Башка вакытта кызлар янының узып киткәндә дә бер шаян сүз әйтмичә түзә алмаган егетләр, аны күргәч, тыйнакланып калдылар, һәркайсы үзен олы сымак тотарга тырышты. Шулай да теле кычытып торган берәү түзмәде:

— Сенелем, ничәнче класста укыйсың? — дип сорап куйды.

— Быел унынчыны бетердем.

— Егетләрегез армиягә киткәндер инде?

Кыз сорау бирүчегә күтәрелеп карады һәм тиз генә керфекләрен түбән төшерде.

— Киттеләр,— диде ул бик акрын тавыш белән.

— Зыян юк, менә фашистларны тукмарлар да кайтып та житәрләр әле.

Әйе, сугышның башланган гына көннәрендә кешеләр бу афәт озакка бармас, дошманны җиңел генә куып чыгарырбыз, безнең куәткә ул озак каршы тора алмас,— дип уйлый иде шул.

Походтагы солдат өчен ял озак булмый. Ике сәгатьтән инде кузгалырга команда булды. Әле кичә генә петлицаларына кече лейтенант кубиклы таккан бу егетләр станциягә таба юл тоттылар. Ә берсе, көне буе кояшта килеп, эссе сукканы, лапас кулəгәсенә җәйгән йомшак урында ятып калды. Өч көн торды ул бу йортта. Әлеге оялчан кыз өч көн буена янынnан китми карады аны. Ә дүртенче көнне егет иптәшләрен куа китте. Күкрәк кесәсендә аның бу кечкенә авылның адресы язылган дәфтәр бите дә, кызның нәфис бармаклары чиккән батист яулык китте. Чибәр кыз бу яулыкны, салкын суга чылатып, егетнең маңгаена куеп торган иде. Ә киткәндә егет аны кесәсенә салып куйды.

Кыз кулыннан юынып, кунакчыл өйдә ял итеп алган егетләрнең күбесе юктыр инде хәзер. Үкенечкә каршы, беренче көннәрдә туган өмет акланмады. Сугыш озак барды, күп корбаннар алды. Ә теге егет исәнсау әйләнеп кайтты. Гомере озын булгандырмы, сугышның иң каты җирләрендә йөрсә дә, зыян булмады үзенә. Әмма күңеленең бер чите китек иде егетнең. Ерак авылда калган кыска чәчле кара кызны, үзенә булмаган беренче мәхәббәтен юксына иде ул. Күкрәк кесәсендә киткән адрес буенча ике арада бик күп хатлар йөрде. Ниләр генә юк иде ул хатларда: авылда беренче булып «похоронный» алган семьяның ачы кайгысы да, комсомолларның кызыл обоз белән икмәк илтүләре дә, разведкага киткән окопташ дусның әйләнеп кайтмавы да, украина юлларының яңгырда изрәгән кара туфрагы да, Берлин хәрабәләре дә... Тик мәхәббәтнең тылсымлы сүзләре генә юк иде анда. Язарга күңел тартмаганнан түгел, бу олы хисне кәгазьгә сыйдыра алмаганнан, җиңел чыккач, шул кыюсыз кызның күзләренә карап, егетнең үз теле белән әйтергә теләгәненнән шулай булды ул. Ә менә кемдер берәү алай уйламаган, әйтәсе сүзен вакытында әйткән һәм үзенә каратып та куйган кызны. Тормышка чыктым, дигән хатны алгач, егет нишләсен, әрнегән һәм... бәхет теләп, сөйгәненә хат язган...

Укытучы туктап калды. Ә Рөстәмнең түземсез күзләре аның сүзне дәвам итүен сорый иде:

— Шуннан, Хәсән абый?

— Беренче мәхәббәт булды микән ул?

Малайга карап әйтсә дә, бу сорауны ана бирүе түгел иде Хәсәннең. Инде күптән онытылып та, ни өчендер менә хәзер искә төшкән бу вакыйганы ул, инде олы кеше буларак, хәзерге хәленнән чыгып бәяләргә тели иде.

— Сания белән очрашканга кадәр бик сагышландым мин, гомергә онытылыр төсле түгел иде ул. Ә менә Саниягә туган хисләр онытгырды аны. Иң беренче уянган тойгыны чын мәхәббәт дип булмый икән әле. Еракгагы яшеннең сирәк-сирәк ялтырап алган сыек шәүләсе кебек була икән ул беренче хис. Күкне ярып төшеп, күз алларын караңгылатып киткән чын яктысы аның алда икән.

Соңыннан, өенә кайтышлый, Рөстәм Хәсән абыйсының бу хикәясен юл буенча исеннән чыгармады. Ул Светлананы яратам дип уйлый иде. Бу тәкәббер кыз аңа барысына караганда да матур, барыннан да акыллы булып күренгән иде. Хәзер ул аның турында иштергә дә теләми. Ә менә Хәсән абыйсы чын мәхәббәт була икән ул, ди. Рөстәмгә дә шундый мәхәббәт бер килер микәнни?

Шулай уйлый Рөстәм. Һава суларга дип чыккан укытучы абыйсы дәшми генә аның янынан килә. Өйдә сөйләнгән истәлекләр аның да күңел күген кузгаткан. Фронттан кайткач, педагогия институтына укырга керүләре, анда Сания исемле чәчрәп торган үтә тере, профкомында да, комсомол оешмасында да әллә ничә төрле җәмәгать эшләре алып барырга да өлгергән, кайберәүләр тартып-сузып өчлегә укыганда, курста бер үзе югары стипендия алып килгән житез кыз белән танышуы, соңыннан бергә яшәгәндәге бик күңелле дә, бик бәхетле дә көннәре берәм-берәм күз алдына килде аның.

Истәлекләр, әллә ничек, үзеннән-үзе тагын Рөстәмгә барып тоташты: егет йомшак күңелле, кыюсыз. Андый кешеләргә тормыш иту читен була. Берәр мәсьәләне хәл кыла башласалар, икеләнәләр, шөбһәләнәләр, кискенлек булмый үзләрендә. Тормышында шундый борылыш ясарга Рөстәмнең кыюлыгы житкән икән, егетнең юлына каршы төшмәскә микән әллә? Тик аны зур заводка урнаштырсаң әйбәт булыр иде. Эшчеләр арасында чыныгыр, характеры чарланыр. Анда үсмерләр өчен аерым цехлар бар. Үзләре белән тәҗрибәле мастерлар эшли. Дөрес, тугызынчы классны житкәч, укучыны чыгарып җибәрү мактаулы эш түгел, дип уйлады Хәсән.

Аннары ул Ләлә Зариповнаны күз алдына китереп, елмаеп куйды. Әй, дулар иде бу уемны белсә, дип куйды эченнән. Башта Фәһимә белән сөйләшергә кирәк әле, ныклап уйламыйча хәл кылырга ярамый бу мәсьәләне. Малайның характеры формалаша, акыллы киңәшчеләр, булышчылар кирәк үзенә, дип бер нәтиҗәгә килде.

Берсе әле яшь генә башлаган, икенчесе гомер тавының инде түбәсенә менеп житкән ике кеше шулай уйлана-уйлана Фәһимә янына килеп туктаганнарын сизми дә калдылар...

Рөстәм өйгә керде. Борчылудан әле һаман урынына ятмыйча, бүлмә белән кухня арасында йөргән әбисенә бер генә күтәрелеп карады да турга узды. Ашарга сорамады, өстәлгә куелган ризыкка кагылмады. Борчу катыш бер каушау белән әнисенең кергәнен көтә башлады. Хәсән абыйсын очратып сөйләшкәч, бераз тынычлангандай булган иде ул. Ә менә хәзер, караңгы урам уртасында әнисенең басып торуын күргәч, аптырап калды. Командировкадан әле кайтырга тиеш түгел иде. Әллә Ләлә Зариповна чакырып кайтарды микән? «Укырга йөрмәвем өчен барысы

да тиргиләр. Һәркем үзенчә таләп итә. Ә мина никадәр авыр икәнен белмиләр микәнни сон алар»,— дип уйлый Рөстәм, ачынып. Ул бик арган. Хәсән абыйсы белән сөйләшә-сөйләшә әкрен генә килеп, нык ук туңган да иде, күнелсез уйларга бирелеп, әнисен көтеп утыра торгач, өстәлгә башын салып, йоклап киткәнен сизми дә калды.

Бераздан Фәһимә әйләнеп керде. Улы янына килеп бераз карап торды. Рөстәмнең беләгенә салган башыннан сыйпады. Кыйгаеп, маңгаена менгән күзлеген алып куйды. Аннан сон, Рөстәмне уятып, өстен чишенергә кушты. Йокы исереклеге белән улы берни белми чишенде. Фәһимә аның өстен рәтләп япты. Караватка кырыена утырып, улының ябыгып киткән йөзенә карап торды. Әкрен генә аның яңагыннан сөеп куйды. Рөстәм, саташып, нидер мыгырданды.

Рөстәм өчен көне буе кичергән курку хисе дә, ана булган ачуы да, аналарча йөрәк әрнүе белән әрнеп, аны кызгануы да Фәһимәнең тәмам хәлен алган. Урыныннан кузгала алмас булып, ихтыярсызланып, утырды да утырды ул. Әнисенең бүлмәгә керүен дә сизмәде.

— Ят инде, кызым, иртәгә эшкә барасың бар бит. Ял итә алмый каласың,— диде ана әнисе.

Әй, ана, ана! Кырыкка житкән кызы да бала шул әле аның өчен. Юлга чыкса да, эшкә китсә дә, эше унмаса да, йокысы туймаса да, ана борчыла аның өчен.

Рөстәмне үстереп аякка бастырсам, исән-сау укытып чыгарсам, зур хәсрәтем бетәр иде, үз күнен үзе күрер иде аннары, дип уйлый иде Фәһимә. Картларның: «Баланың борчуы үзең үлмичә бетми ул»,— дигән сүзе дөрестер, күрәсең. Бер карасаң, Фәһимәнең тормышы жайлы гына бара, югыйсә. Сәламәтлеге бар, эшендә яраталар, хөрмәт итәләр, кая барсаң танышлары, дуслары, Фәһимә дип, үлеп тора. Рөстәме дә әле бу көнгә хәтле, кайбер балалар шикелле, сүздән чыгып, азып-тузып, жан көйдереп йөрмәде. Ничә карасаң өйдә булыр иде, ничә карасаң кулында китап иде. Ә шулай да Фәһимәнең тормышы бер яктан китек. Кайтып керсә, чыгып китсә, сыңар аккош шикелле, һаман ялгыз, һаман ялгыз. Фәһимә үзе ул турыда әллә ни пошынмый да сыман. Ә менә Хәдичә әбинең эче поша. Ятса, торса, шуны уйлый. Күнеленнән генә инде ул Хәсәнне дә юрап куя. Ул да ялгыз. Эчми, тартмый дигәндәй, йомшак телле. Рөстәм белән дә дус үзләре. Ә малайга үскән саен ата булыр кеше кирәк. Әни белән сөйләшә алмый торган сүзләре дә була бит аларның.

## VIII

Фәһимәне йокы алмады. Артык борчылган иде ул. Хәсән белән сөйләшү дә тынычлык китермәде. Ничек болай булды сон әле бу? Ни эшләргә инде ул бала белән? Улының кичке мәктәпкә күчүен һич теләми иде ул. Тиздән аттестат алыр дип торганда гына тагын ике елдан артык уку күтелмәгән борчу гына тудырачак иде. Эшләп укырга көче дә житәрлек түгел бит әле аның. Юка гәүдәле балага авыр булачак. Укуын үз вакытында бетермичә, эленке-салынкы йөргән, кичке мәктәпкә кереп караган, укыйсы килмичә аннан да чыккан, бер урында рәтләп эшләмичә, эштән-эшкә күчеп йөри башлагач, сугышып, суд эскәмиясенә барып утырган күрше малаен күз алдына китереп, ананың борчылуы тагын да артты. Менә шуңа да улының, укып бетереп, төпле генә урнашып калуын тели иде ул. Керә алса, институтка кереп, укуын дәвам итсен. Булмый икән, яше житкәч армиягә китәр. Чыныгып, дөнья күреп, ныгып кайтыр. Чыннан да, балалык гадәтләрен ташлап, тәмам олыгаеп кайта бит аннан егетләр. Ә хәзер алар жинел генә уйлыйлар шул: теләсәм укыйм, теләмәсәм юк. Теләсәм, шул мәктәпне бетерәм, теләсәм, берәр кичке мәктәпкә кереп укыйм. Ә ул мәктәп коллективы

сыйдыра алырмы аны, холкын, тырышлыгын, булдыра алу сәләтен чамалый белерләрме анда? Һәр коллективның еллар буена тәрбияләнгән үз традицияләре була. Хөрмәт итә алырмы ул аларны, санлармы? Һаман да шул үз холкын куып, казанга сыймаган кабыргадай тырпаеп тормасмы?

Менә шуларның берсе турында да уйламый микәнни бу бала? Иске урындагы чатакларын яңа җирдә белмәсләр, ул шулай йомылып калыр, алар өчен җавап бирергә дә туры килмәс, яңа коллективта бары шома гына, җиңел генә башланып китәр дип уйлый, күрәсең. Ләкин үз-үзеңнән качып булмавын, һаман да шул холкы, үзеңдә булган шул яхшы һәм яман сыйфатлары белән барып керүен ул башына да китерми. Яңа мәктәпкә күчтеме, барлык борчулары берьюлы бетәр дип уйлый ул. Әлеге вакыйгадан соң иптәшләре арасында калу авыр иде аңа. Инде онытылып бетте дисәң дә, аларның бу хәлне искә алып, бер булмаса, бер әйтеп куюлары бар. Шуның өстенә бит әле укуы да малайның уртача гына. Яхшы укыса, кайбер якларын гафу да итәрләр иде, әмма Рөстәм кебекләр өчен инде бу хәл чүп өстенә чүмәлә була, юк-бар нәрсәгә күңел салганга, шулай йомшак укый дип, хәзер нәтиҗә чыгарып куячаклар, дип тә уйлый Фәһимә. Бер туктаусыз шелтә сүзләре ишетеп тору, һаман-һаман ышанычсыз күз карашларын тоюю, якты чырай булмау баланың канатларын сындырачак, әлбәттә, күңелен төшерәчәк. Шуларны уйлаганда малайның бу карарга килүен акларга да мөмкин. Ләкин бит әле мәктәптә аның күңелен аңлый белә торган Хәсән кебек, бераз гына ваемсыз булса да, киң күңелле Зоя Ивановна кебек, завуч Фатыйма кебек укытучылар да күп.

Рөстәмнең бу эше әнисенең күңелендәге борчуны тагын шул ягы белән арттырды: малай да, әтисе кебек, авырлыкларга каршы көрәшсез-нисез бирешүчән булмыйммы? Фәйзи авырлык алдында бик тиз югалып калды. Ямманаты таралудан, судья каршына басудан куркып, яраткан кешеләрен ташлап китте. Ә бит семьяны саклап калырга мөмкин булыр иде. Бала хакына дип, бәлки Фәһимә дә аны гафу итәр иде. Акрынлап, яра да төзәлер иде. Хәзер менә ике җирдә ике бәхетсез семья. Шулай ук Рөстәм дә беренче тапкыр күңелсезлеккә очрау белән чигенер, иптәшләрен ташлап китәр микәнни? Нәрсәне күреп житкермәдем, нәрсәдә ялгыштым соң мин, нишләргә соң хәзер? дип өзгәләнде Фәһимәнең йөрәге, улының баш очында уйланып утырганда. Бөтен тормышы, Рөстәменә игътибарсыз калган һәр минуты тагын бер тапкыр башыннан узды аның. Хәсән дә хаклы сыман. Бәлки аның заводка керүе чыннан да хәерлерәк булыр. Күңелен сындырган, ышанычын югалткан иптәшләре арасына, инде бер киттем дигәч, яңадан әйләнеп кайтуы да кыен шул.

Инде ни эшләргә икән? Нинди киңәш бирергә Рөстәмгә? Күп уйлады ул, күзенә йокы кермәде. Шуннан түзмәде, онытылган көндәлеген, бердәнбер күңел сердәшен, яңадан кулына алды. Ничәмә еллар бүленеп торганнан соң, анда яңа бит ачылды. Яңа юллар язылды.

**13 февраль.** Космик тизлек белән яшибез. Әле иртә белән генә, эчем пошуга чыдый алмыйча, Мөслимдә уянып киткән идем. Шуннан бирле борчулы озын көн үтте. Инде менә төн уртасы житеп килә. Кемнәрне генә күрмәдем дә, ниләр турында гына сөйләшмәдем мин бүген. Әйе, Рөстәмем минем, әле кечкенә генә малайга исәпләп йөргән Рөстәмем, инде гашыйк булырга да өлгергән. Ләкин беренче хисләре аның җавапсыз калган. Алай гына да түгел, көлгәннәр аның ул хисеннән. Гомере буе шулай төзәлмәслек яра алмаса ярый инде бу яшь күңел. Чын яратуның барлыгына, аның бөеклегенә ышанмый башлавы да мөмкин бит әле аның. Ләкин Рөстәмнең күңеле яхшылыкка тиз тартыла. Яшь йөрәгенең чын мәхәббәт хисләре белән янар көннәре алда әле. Аңа менә бүгенгесе авыр.

Соңгы елларда мин, эшкә мавыгып, ничектер улымнан читтәрәк яшәдем, күрәсең. Аның тәрбиясен күбрәк әбисенә тапшырганмын. Мин хәтта улымның нидән кызык табып яшәвен, нәрсә белән мавыгуын да белмим икән ләбаса. Ләкин балага, үсеп буйга җитә башлагач, әбисенең дөньясы гына тар булган. Ул үзенә сердәш, иптәш эзләгән. Минем балам турында Хәсән миннән күбрәк белә. Ә бит мин үземне яхшы аналардан санап йөрим. Җае чыкканда, кешеләргә дә балам тәртипле үсә, намуслы дип әйтергә яратам. Уртача гына укып баруын да үземчә аклаган булдым. Мин Рөстәмнең, вузга кереп, студент булуын гына күз алдыма китерә ала идем. Ә чынлыкта, урта мәктәпне бетерә алмау куркынычы да бар икән. Хәсән һәрвакыт әйтә килде: баланы бик кечкенәдән эшкә өйрәтергә кирәк, аның утырып дәрес каравы да шул ук эш инде ул, соңыннан авырга килер, дия торган иде. Аһ, Хәсән, Хәсән, никадәр хаклы булганыңны белсәң иде син... Хисләреңне дә аңлыйм, яратуыңны да сизәм синең. Тик үзем генә алай тиз кабынып китә алмыйм. Ләкин күңелем көннән-көн сиңа тартыла. Тоям мин аны, куанам да шикелле ул хискә, куркам да сыман.

## IX

Галимә ханым кызы торуга аш-чәй әзерләп йөри иде. Үзе белән кызган май исе ияртеп кухня яктан килеп керде дә ишек төбендәге включательгә басты. Бүлмәгә яктылык сибелде, күңелгә дә әз генә җиңел булып китте.

— Тордыңмы, кызым, әйдә, коймак өлгерттем, юынып ал,— диде әнисе. Ул, өстәл өстеннән кичә кызы калдырган китапларны җыеп алып, чәй әзерли башлады. Аннары, ашыгып, тагын кухняга чыгып йөгерде. Табада калган коймаклары көя иде бугай.

Шул вакытны кухняга Фәһимә дә килеп керде. Мөслимгә киткәндә йортлар идарәсенең техникларына шалтыратып, шушы йортны килеп карауларын, мөмкин булса ике семья өчен ике ишек ясатып бирүләрен үтенгән иде. Ә ул халык, үшән ат шикелле, чыбыркылап торсаң гына эшли. Күз алдында була, була, эшлибез аны, дип калалар, ике-өч тапкыр килеп исләренә төшермәсәң, урынныннан кузгатырмын димә. Фәһимә артыннан да барырбыз, карарбыз дип калганнар иде, килделәрме, юкмы икән? Килсәләр, ни дип әйттеләр икән? Эшкә барышлый, урау булса да, Болак буеннан әйләнеп, Галимә ханымнардан шуны белешеп чыгарга уйлады Фәһимә. Калган эшкә кар ява, диләр картлар. Вакыт дигән нәрсә бик чамалы, көн тудымы, яңа мәшәкать чыгып кына тора. Үзе командировкада йөргән арада эше дә күбәйгәндер инде, әллә ни хәтле хатлар килгәндер. Бары да җавап көтә, бер җылы сүз көтәләр бит.

Рөстәм дә бик эчне пошыра. Үзе эшкә киткәндә ул аны урыныннан кузгатып калдырды.

— Тор, җыен, мәктәпкә барырсың. Ул нинди дәрес калдырып йөрү ул,— диде Фәһимә.

Рөстәм урыныннан торды, киенергә ашыкмады. Мәктәпкә барып керәсен уйлап, эче пошып китте. Килеп керүемә барысының да күзе миндә булыр инде. Кызлар чыш-пыш сөйләшә башлар, малайлар авыз ерып көләрләр, дип уйлап алды. Ялварып әнисенә карап куйды:

— Әнием, син мине берәр мәктәпкә генә урнаштыр инде.

— Ә син үз мәктәбеңнән китәргә теләвең турында минем белән киңәштеңме соң?

— Син өйдә юк идең ич.

— Мин кайтканны көтәргә булмадымы? Син инде зур кеше. Нәрсә эшләргә кирәген үзең беләсең. Шулаймы?

Малайның йөрәге сулкылдап куйды. Үпкә белән әбисенә карап алды: житкергән икән. Өченче көн, әбисе мәктәпкә бармыйсын дип тиргә башлагач, кызып китеп, шулай дип әйткән иде Рөстәм.

— Менә шулай, улым, инде үсеп житүең мине бик шатландыра иде, тик башыма мондый мәшәкатьләр салырсың дип кенә уйламаган идем.

Рөстәм, озын керфекле зур күзләрен тутырып, әнисенә бер карап алды. Син булышмасаң, мин нәрсә эшли алам соң? — ди иде аның карашы. Бу араларда шәһәр бетереп эш эзләп йөрсә дә, малайның күңелендә эшне дә, укуны да әни җайлар әле дигән өмет яшәгән булса кирәк. Кинәт кенә нинди зур мәшәкать, нинди зур борчу төшүен әле шунда гына аңлады бугай ул. Бик мескен бер кыяфәт белән утыра иде, аны күргәч Фәһимәгә баласы бик кызганыч булып китте. Рөстәмне кечкенә вакытындагы шикелле кочып аласы килде. Шушы хәтле сөйкемле улының матур хисләреннән көлгән таш бәгырьле билгесез кызга күңелендә ачу туды. Баласының шулай, ни эшләргә белмичә, ихтыярсыз утыруы бары тик ул кыз аркасында гына кебек тоелды.

Анын күңеле дөрес сизенгән икән. Техниклар әле булса килмәгәннәр. Тик Галимә ханымны ул хәл артык борчымый булса кирәк:

— Я, ярар инде, булган эш булган да беткән. Минем эчемдә усаллык юк. Әйтәм дә кайтам. Күршеләребез белән бә-эк әйбәт торабыз. Күңелең киң булгач, бер ишеккә дә сыясың икән ул, иптәш депутат,— ди.

Җиннәрен сызганып торып, иртәнге чәйгә коймак пешереп азапланган бу ханымга Фәһимә, сәерсенеп, баштанаяк карап торды. Ни пычагыма дип әле син шулай тавыш кубарып, кеше борчып йөрдең соң? Никадәр вакытымны алдың. Әле ярый, техниклар килеп житмәгән, аларны юкка йөртүең булыр иде. Менә тагын йортлар идарәсенә барып әйтергә кирәк. Кеше җибәреп тормасыннар. Үзеңнең дә эшләгән чагың булгандыр лабаса. Булмаса, кызың эшли, Ләлә Зариповнаны бит бик пунктуаль, артык таләпчән кеше дип әйтәләр. Ничек соң сиңа шул эшне эшләргә ирек куйды ул? Вакытның кадерен белергә бер дә өйрәнмәдеңмени син? дип уйлады Фәһимә. Һәм күңелендәгеген әйтеп тә биргән булыр иде, шул вакыт, инбашына сөлге салып, теш порошогы һәм сабын тотып, җылы халатына төренә биреп, кухняга Ләлә Зариповна килеп чыкты.

— Исәнмесез,— диде ул Фәһимәгә, салкын гына итеп.

— Исәнмесез, Ләлә Зариповна. Бу арада гел очрашып торырга туры килә әле үзегез белән.

— Шулай инде ул. Балаларына берәр хәл булса гына ата-аналар борчыла башлый. Барысы да дип әйтмим, әлбәттә, кайберләре...

— Гафу итегез, бу минем адреска туры килми бугай. Аннан соң әле мин биргә әниегезнең үтенечен юллап килгән идем. Депутат буларак.

— Җәмәгать интереслары белән яшәү мактаулы эш, әлбәттә. Тик үз интересларыңны да онытмаска кирәк. Бигрәк тә балаң барлыгын.

— Анысы шулай. Әгәр Галимә ханым кебек, юкка-барга да бузә куптарып, эч пошкан саен депутатка йөгермәсәләр, аларның да файдалы эш өчен вакытлары күбрәк булыр иде.

Фәһимәнең бу шелтәсенә Ләлә Зариповна берәр җавап табар идеме, юкмы, табада кызган маеннан да болай чәчрәп, Галимә ханым бәхәскә керергә тора иде. Фәһимә шуны сизде дә, тизрәк чыгып китү ягын карады.

Рөстәм турында тагын бер тапкыр сөйләшергә, Хәсән киңәшен класс житәкчесе белән дә уртаклашырга уйлап алган иде. Болай булгач Фәһимә ул турыда сүз кузгатып тормады.

Һавага чыккач, ул иркен сулап куйды. Төне буе бурап-бурап яуган кар инде туктаган, күк йөзе бераз ачылып, көн яктырып киткән, бөтен җирне каплаган мамыктай йомшак ак кар күзне камаштыра. Әле булса урамнарны чистартып өлгермәгәннәр, машиналар аз йөри торган җирләрдә юллар аеруча карлы. Буран артыннан көн дә җылытып җибәргән. Спасс башнясындагы сәгать сигез туларга чирекне күрсәтә иде, Фәһимә, соңга калам, ахры, дип, тагын да кызулый төште.

Әтисенә ышаныч юк. Аптыраганнан гына барган иде Рөстәм. Ә менә әнисе мәктәпкә кире кайтырга өнди. Тик Рөстәм әле соңгы тапкыр булса да үз фикерен тормышка ашыру өчен талпынып карарга булды. Нигә дип аңламыйлар икән бу олы кешеләр балаларының күңелен. Үзеңне шулай мәсхәрә иткән кыз укыган класска яңадан кайтып керүе никадәр кыен икәнен белмиләрмени соң алар? Хәсән абый комсомол җыелышында Светланага шелтә биргәннәр дип әйтә бит әле. Әллә гел юатыр өчен генә сөйлидер ул аны. Шундый шикләр, борчулар тынгы бирми Рөстәмгә. Шуның өчен ул, бер кеше сүзенә карамыйча, эш эзләргә, кичк мәктәпкә керергә дигән фикердән чигенмәскә булды.

Кичә ул райисполкомга керсә дә, каушавы белән, рәтләп сөйләшә дә алмаган иде. Комиссия утырышына килгәндә берәр язу-мазар кирәктер инде ул. Нинди рәк язулар алырга, кайсы бүлмәгә, сәгать ничәгә килергә — шуларның барысының да рәтен белеп кайтырга дип, ул яңадан шунда китте. Ике урам чатына салынган ике катлы гына тәбәнәк таш йортның бүлмә ишеге саен халык тора. Кайсы утырып, кайсы басып, кайсы сөйләшеп, кайсы тик кенә чиратка баскан халык алдыннан узып, ишеккә борын тыгармын дип уйлама: артыңнан хәзер кычкыра башлыйлар. Синең яшь булуыңны да, сабырсыз булуыңны да, зурларны санга сукмавыңны да искә төшерәләр, хәтта балак очлары киңәеп киткән чалбарыңны һәм муеныңа төшеп торган озын чәчләреңне дә телгә алалар. Бер ишеккә тыгылып караган иде Рөстәм, барысын да ишетте шуларның. Эченнән бик оялды, колак яфраклары кызара башлады, шулай да сөйләсәгез, сөйләгез, исем китми әле дигәндәй, елмайган булып, коридорның икенче башына юнәлде. Нишләргә икән? — Бер-ике авыз сүз сорар өчен генә чиратка баса алмый бит инде ул. Аннан соң әле кайсы бүлмәгә керергә икәнен дә белми. Бер җирдә чират торырсың, ә сиңа бөтенләй анда керергә кирәк булмас.

Шулай буталанып йөргән арада бүлмәләрнең берсеннән, кулына бер кочак кәгазь тотып, шунда эшләүче апа килеп чыкты. Рөстәм, аны туктатып, йомышын әйтте. Тегесе малайның башыннан аягынача бер карап алды. Хәлгә керерлек җылы, өмет бирә торган караш түгел иде бу.

— Мин әйтә алмыйм, бишенче бүлмәдән сора,— диде хатын. Узып киткәч, тагын бер тапкыр артына әйләнеп карады. Бу нинди җан көеге йөри тагын дигәндер инде.

Бишенче бүлмә дигәннәре беренче катта булып чыкты. Монысының ишеге төбендә халык юк иде. Рөстәм бүлмәгә башын тыгып карады, озын өстәл артында сөйләшеп утырган өч-дүрт кешене күреп, рөхсәт сорады.

— Сабыр ит, диделәр аңар.

Ул көтә башлады. Бераз читтәрәк торган эскәмиягә барып утырып та торды, озын һәм ярым караңгы коридор буенча йөреп тә килде. Әлеге дә баягы чират торучылар янынннан да әйләнеп үтте. Стенадагы түгәрәк сәгать телләре бик акрын кыймылдаган кебек булсалар да, һаман алга үрмәлиләр үзләре. Ул килеп басканда ун иде, менә инде унбер дә тулып үтте. Әлеге ишектән керүче дә, чыгучы да күренмәде. Рөстәмнең түземе бетә башлады. Ул ишекне яңадан ачып карады. Әле кешеләр һаман шул бер урында утырган көе җай гына сөйләшәләр.

Тик бүлмәдә тәмәке төтене зәңгәрләнеп күерган да, көл савыты тәмәке төпчекләре белән тулган иде. Башта алар малайның кыюсыз, акрын тавышын ишетмәделәр, үз сүзләрендә булдылар. Рөстәм, бу юлы инде кычкырып, янадан рөхсәт сорагач, күтәрелеп карадылар. Тик шул минутта Рөстәм бүлмәгә узарга да, сүз әйтергә дә белмичә аптырап, басып калды. Бүлмәдәге дүрт кешенең берсе, ишеккә арты белән утырганы, Хәсән абыйсы булып чыкты.

— Ә, Рөстәм, әйдә кер. Синең турыда сүз бара иде әле,— диде укытучы аны чакырып.

Бүлмәдәгеләр, шушы баламыни инде ул егет, дигәндәй Рөстәмне баштанаяк карап алдылар. Егеткә тагын да кыен булып китте. Ык-мык итеп торды да ул:

— Мин эшкә керергә телим, дип куйды.

Бүлмәдәгеләрнең Хәсән белән янәшә утырганы, урыныннан кузгалып, кечкенә һәм юка гәүдәле яшүсмергә карап тора башлады.

— Сиңа ничә яшь соң, энекәш? — дип сорады ул бераздан.

— Унҗиде инде,— диде Рөстәм.

Сүзгә икенчесе, өстәл артында утырганы кушылды:

— Ничек соң, укыйсы килмимени?

Егет, шикләнеп, укытучысына карап алды. Ә Хәсән, кыюрак бул, дигәндәй баш кагып алды.

— Минем эшлисем килә. Укуны кичке мәктәптә укырмын,— диде Рөстәм.

— Ә кайда эшләр идең соң син? Нинди һөнәр алырга теләр идең?

Рөстәм җавап бирергә өлгерми калды, әлегә кадәр дәшми утырган күзлекле кызның тавышы ишетелде:

— Эшче дигәч тә бит ул... Эшчеләр дә күп төрле була. Токарь, фрезеровщик, лекальщик, аппаратчы, слесарь, гравер, штамповщик...

Ул тагын әллә нинди профессияләрне санап китә алган булыр иде, бүлмә буенча йөреп торган кеше аны бүлдерде:

— Допустим, әле ул гравер булып эшли алмас, лекальщик булуы да бик икеле. Но шулай да кем булып эшләр идең соң син, егет?

Рөстәм завод дигәч тә цехларда тезелеп киткән төрле-төрле станокларны һәм шунда йөргән майлы комбинезонлы, чәчен берет астына җыеп тыккан эшчеләрне күз алдына китерә. Кинода шулай күргәне бар. Аннары укыган чагында үзләре практикага йөргән завод цехында да шундыйрак күренеш иде. Ул эшчеләрнең төрле-төрле һөнәр ияләренә аерылуларын да белә, әмма үзе слесарьлыкка өйрәнгәнлектән, башкаларның эшен өстән-өстән генә чамалый иде. Шунлыктан әлеге кыз санап киткән профессияләрнең берсенә дә тиз генә туктала алмыйча, аптырабрак, бүлмәдәгеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап куйды.

Өстәл янындагы урын бирдәләр аңар. Хәсән абыйсы хәзер Рөстәмнең нәкъ каршында иде. Ләкин ул бер сүзгә дә катнашмады. Ни йомыш белән килде икән. Аның монда утырганын белсә, Рөстәм бүген ике аягының берсен атламас иде.

— Ә бәлки үз классыңда укуыңны дәвам иттерерсең? — дип сорадылар аннан.

— Мин кичке мәктәпкә күчәм.

— Ә аңлашылды,— диде әлеге кыз бик зур хакыйкать ачкандай.— Син мәктәптә өлгерми башладың, шулаймы? Кичке мәктәптә уку җиңелрәк дип уйлап, шунда керергә телисең, дөресме?

Рөстәм дәшмәде. Ирләр сүзенә кысылмыйча, тик кенә утырсаң ни була, дигәндәй, бер күз сирпеп кенә кызга карады. Аның караш, өстәл артында утырган кеше кызның сүзен җөпләп алды:

— Ә бит кичке мәктәпләрдә аннан-моннан гына укып булмаячак. Анда да, көндезге мәктәпләрдәге шикелле үк, таләп каты булачак.

Бу кадәр төпченерләр, әллә ниләр сорарлар дип уйламаган иде ул. Боларны әле шулай кылана, ә комиссиясендә ни сорап бетермәсләр.

Рөстәмнең бер дә алай чәчелеп китеп, барысын да сөйләп бетерәсе килми иде.

Һәрнәрсәнең чиге була бит, әлеге кешеләр дә сорашудан туктадылар. Комиссиягә килү тәртипләрен аңлатып бирделәр. Аларның әле кабул итеп алган документларны тикшерүләре икән. Шуннан соң атнага бер тапкыр, эшкә керергә теләүче яшүсмерләрне чакырып, үзләре белән сөйләшәләр. Килгәндә я әтиең, я әниең белән килергә кирәк. Сөйләүләреннән аңлап алды Рөстәм, комиссия членнарының кайсылары педагог, кайсылары комсомол оешмаларында эшләүче икән. Аннары бирегә укуларын ташлаган ялкау балалар, зурларга баш бирмәс хулиганнар, әле кечкенә булсалар да, ата-анасының бәгыренә төшкән, җеләкләрен саргайткан кире беткәннәр күбрәк килә икән. Ә Рөстәмгә калса, тегендиләр арасында да, мондыйлар арасында да күрергә теләми иде ул үзен. Шуның өчен дә ул, сүзен бетереп ишекне ачкач, иркен сулап куйды. Тизрәк бу йорттан йөгереп чыгып качасы килде аның. Хәсән абыйсы, мине көтми китмә, дип артыннан әйтеп калмаса, ул шулай иткән дә булыр иде.

— Я, Рөстәм, комиссиягә хәтле ныклап уйла. Эшләргә дип әйтсәң, сине Компрессорлар заводына җибәрергә мөмкинлек бар. Кичке мәктәпкә керергә үзем булышырмын,— диде Хәсән, бүлмәдән чыгып, Рөстәм янына килгәч.— Бәлки үзебезнең мәктәптә генә калырсың, ә?

— Юк, Хәсән абый, китәргә булгач китәргә инде. Укуын ташлар дип уйламагыз. Мин барыбер урта мәктәпне бетерәм әле,— диде егет.

Хәсән аны хуплап аркасыннан кагып куйды:

— Ярый, хәерле булсын. Эшләргә булгач эшләргә! — диде.

Рөстәм урамга чыкканда, көн инде ачылган, аяк асты тәмам шомарып, тайгакка әйләнгән, дворниклар, тротуардагы карны бер якка өеп, кеше биеклегедәй таулар ясап куйганнар. Бил тиңентен юешләнеп беткән малайлар шунда кала алышлы уйныйлар. Бер өемнең башына чыбыклардан ясалган биш почмаклы йолдыз кадаганнар. Рөстәм узып барышлый гына бер зур йомарлам кар ыргыткан иде, өем таралып ук китте. Кала саклаучылардандыр инде, бәләкәй генә бер малай ачу белән аның артыннан кычкырып калды.

— Дулак!

Рөстәмнең кинәт шаярасы килеп китте. Тагын бер йомарлам кар алып атты. Ул арада өемнәр артыннан аның үзенә йодрык-йодрык карлар оча башлады. Малайның башына, күкрәгенә, эченә килеп тиделәр алар. Ул кулы белән битен каплап, «ут астыннан» йөгереп чыкты. Аның артыннан балалар шырык-шырык көлеп калдылар.

Урамда сумка күтәреп атлаган укучылар күренә башлады. Башта алар берән-сәрән генә очрадылар, аннары төркемләп-төркемләп килә башладылар. Укулар беткән вакыт иде булса кирәк. Мәктәп чатына җитеп үзләренең өйләренә борылыйм дигәндә генә Рөстәм Светлана белән йөзгә-йөз очрашты. Светлана мамык башлыгының колакчыннарын иңбашына салып, каракулгә охшатып ясалган аксыл туныпың сәдәфләрен төймәләмичә, бер үзе акрын гына атлап килә иде. Көтелмәгән бу хәлдән алар икесе дә аптырап калдылар. Светлана кып-кызыл булып кызарды, башын аска иде һәм кинәт кенә урыныннан кубып, йөгереп китеп барды. Рөстәм бик озак аның артыннан карап торды. Ни өчендер бу кызга артык үпкәләми иде инде ул. Әллә мәктәптән китәсе булганга шулаймы? Булса да булыр, тугыз ел бергә укыган иптәшләреннән аерылу җинел түгел, андый чакта Светлана шикелле үзәгенә үткәннәре дә юк юк та бер сагындырып куяр әле аның.

Кич белән Фәһимә кайтты. Кибетләрдән ала-ала кайткан кефирын, йомшак күмәчен, колбаса кисәген, тагын шундый вак-төякләрне куярга дип кухняга кергән иде, Хәдичә әби кухня ишеген ябып куйды да пышылдап кына:

— Ни булды соң инде бу балага, төш турында кайтып керде дә өйнең астын-өскә китереп бетерде. Иске чалбарын эзли, атасыннан калган пинжәкне таптыра, үләм инде,— дип зарлана башлады.

Фәһимә шунда ук түрдәге бүлмәгә чыкты. Рөстәм шифоньер тартмаларын ачып куйган, әллә кайчан таслап салынган, күп еллардан бирле тотылмаган кием-салымнарны таратып ташлаган, Фәйзидән калган бер чалбарның балакларын сүтеп азаплана иде. Әнисен күргәч башын күтәрде, уңайсызланып кына:

— Әни, бу чалбар барыбер тик ята. Мин аның балакларын тарайткач эшкә киеп йөрим әле,— диде.

Фәһимә улы янына килеп утырды да кулыннан эшен алды. Чалбарны алдына җәеп карады һәм елмаеп куйды. Рөстәм соры җеп белән эре-эре атлатып тегеп чыккан булган. Җөе тартылып җыерылып тора.

Улы, ни әйтер инде, дигәндәй әнисенең йончыган борчулы йөзенә текәлгән иде. Фәһимәнең, бер сүз әйтмичә, иске йон материяне сыйпап утыруын күргәч, түзмәде:

— Мин бүген райисполкомга барганием,— дип куйды.

Әнисенең, уйга бирелеп, үзе сөйли башлаган сүзләрне ишетмәвен күргәч, туктап калды. Фәһимә башын күтәреп улына карады, аның нәрсәдер әйтергә теләвен аңлады. Ләкин Рөстәм һич көтмәгәндә:

— Син авырыйсыңмы әллә, әнием? — дип сорады.

— Юк, нигә алай дип әйтәсең?

— Күңелсез син бүген.

— Шатланырлык берни дә юк бит.

— Беләм инде ни әйтәсеңне.

— Ә мәнә мин синең ни әйтәсеңме һаман белеп бетермим әле.

— Мин эшкә керергә булдым инде, әни. Райисполкомда Хәсән абыйны очраттым. Ул да шулай дип әйтте.

— Әй, Хәсән, Хәсән! Рәхмәт инде сиңа,— дип уйлады Фәһимә улының соңгы сүзләрен ишеткәч.— һаман без дип тырышуың бит. Рөстәм өчен үз атасы кайгырмаганда, син борчылып йөрисең.

Шул вакыт Хәсән аңар бик якын, бик үз булып тоелды, мәнә хәзер үк аны күрәсе, аның янында буласы килде. Тик уйлаганын минуты, сәгате белән эшләрлек ашкынулы яшьлеге узган инде, күрешәчәк көнне сабыр гына көтеп торырга кушкан айнык акылы хуҗа хәзер ана. Әнә Хәдичә әби дә балаларын табын янына чакырып тора. Фәһимә урыныннан торды да улын иңбашыннан кочып алды:

— Әйдә булмаса ашап алыйк, эшче кешегә көч күп кирәк,— диде ул, уенын-чынын бер итеп.

Хәдичә әби өстәлгә ипиен, телем-телем кыярын, тозын, борычын тезеп куйган. Рөстәм шадраланып торган сусыл, тозлы кыярның бер телемен алып, шытыр-шытыр чәйни башлады, иңенчесенә үрелде. Әбисе аның кулына сукты.

— Әдәпсезләнмә, өстәл янына утыргач та житешерсең.

Фәһимә дә, өстен алышып, килеп утырды. Табын түгәрәкләнде. Рөстәм дә өйдә торса, Фәһимә дә берәр җыргә китәргә ашыкмаса, Хәдичә әбинең күңеле була. Өйдә ничектер бәйрәм шикелле, җан да тыныч.

Әйе, бу кечкенә гаилә шулай торып, торып бер болганып ала да янадан бер җайланып китә. Ни эшлисең, тормыш бит. Алда әле борчуы да, шатлыгы да күп булыр. Тик янынан дусларың, теләктәшләрең генә китмәсен.

❖ ❖ ❖

## Гәрәй Рәхим

### Октябрь

Син хакыйкать булып тудың дөньяга.
Ач йортларга икмәк булып кердең син,
Наданнарга хәреф булып таныйдың,
Ил өстендә ирек булып йөрдең син.
Кырыс көннәр сине солдат иттеләр —
Һәм син безгә җиңү фәнен өйрәттең.
Тыныч көннәр сине сәнгать иттеләр —
Һәм син безгә зур бер сәнгать өйрәттең.
Баш өстендә үлем торган көннәрдә
Яшәү булып яңгырадың тормыштан.
Дөнья җырга сусаган һәр мизгелдә
Син җыр булып чыктың безнең сулыштан.
Икмәк булдың, ирек булдың, җыр булдың,
Көрәшләрдә тиңләштең зур дәрьяга.
Тик боларның барыннан да алдарак
Син хакыйкать булып тудың дөньяга.

●

Мин бит җирдә яңа кеше әле,
Мин нарасый әле, мин — бала.
Мин агач ат итеп атланырга
Әзер әле фани дөньяга.
Һәм чабарга тормыш урамыннан
Кыңгыраулар гына чыңлатып.
Гомер буе шулай ялан аяк
Элдерергә бу җир буйлатып.
Әнкәй кушкан бөтен йомышларны
Онытып, мин шушы атымда
Ташланырга әзер бу дөньяның
Зур шау-шулар купкан чатына.
Мин әзермен әле кайгыларга
Тик сызгырып кына утәргә,
Тезгенемә берәр кул сузылса
Камчы сызып узып китәргә...
Мин бит җирдә яңа кеше әле,
Мин агач ат белән гел бергә.
Мин ашкынам безнең урамнарга
Кыңгыраулар чыңы илтергә.

# Ник

Кеше хәттә утларга да
Керә, дисең.
Алдында тик су гына бит,
Ник кермисең?!
Ир-егетләр үлемнән дә
Көлә, дисең.
Каршыңда тик кайгы гына —
Ник көлмисең?!
Атка — атча, эткә — этчә
Җавап, дисең.
Каршыңда мең эт тора бит,
Ник өрмисең?!
Теләге бар томан аша
Күрә, дисең.
Дөреслек бит нәкъ каршыңда —
Ник күрмисең.
Эшең бетсә җирдән китү
Яхшы, дисең.
Юньле эшең күптән бетте —
Ник китмисең?!

●

*Рекатка*

Бер көн сиңа үлем килсә,
Үлә күрмә ялгыш.
Синнән яшәү таләп итә
Сагынмаган сагыш.
Каршыңда бар бөек ләззәт —
Сөелмәгән сөю.
Үлә күрмә, җирдә кала
Көелмәгән көю.

Тормышыңда бар бит әле
Тоелмаган тою.
Синнән көрәш көтеп ята
Тыелмаган тыю.
«Үлем килсә нишлим?» — димсең?
Мөмкин аны куу.
Алдыңда бар иң бөек кәч —
Бар тумаган туу.

●

Урам буйлап килә идем
Югалган бер моңны эзләп.
Син очрадың. Тавышыңнан
Таныдым мин — моң икәнсең.

Шау-шу тулы дөнья буйлап
Килә идем тынлык эзләп.
Син очрадың. Чәчләреңнән
Таныдым мин — төн икәнсең.

Язлар эзләп килә идем
Вакыт диган урам буйлап —
Күзләреңнән таныдым мин,
Син яшел яз идең, иркәм.

Тормыш буйлап килә идем
Үземә тиң сөю эзләп.
Очрамадың. Авыр миңа.
Мин сиңа тиң түгел икән.

●

Мәхәббәттә синең белән
Сарайлар коралмадым.
Мин Таһир булган чакларда
Син Зөһрә булалмадың.

Ләкин син дә минем белән
Чатырлар куялмадың.

Син Зөһрә булган чакларда
Мин Таһир булалмадым.

Нишлисең, безнең сөюләр
Яшиләр ике якта.
Икесе бер ук ялгышу,
Икесе ике хата.

Без бары тик Җирне яраттык,
Балачактан Җиргә инандык,
Уенчыклар алып тормадык —
Җир туфрагы белән уйнадык.
Балалыкны өйдә калдырып,
Җиргә сәяхәткә чыктык без.
Юлда очрап байтак дошманның
Якасыннан урап тоттык без.
Ләкин усаллыкны күрсәттек
Бары Җир хакына гына дип;
Һәм тормыштан бәхет дауладык
Бары Җир халкына гына дип.
Күпләр бездән көлеп йөриләр
Җирне артык якын иткәнгә.
Янәсе, без үлем килгәч тә
Тиешбез ич Җирдән китәргә.
Ләкин үлем килеп, бер көнне
Таләп итсә безне үзенә —
Үлемне дә кызык итәрбез,
Аңа түгел, Җиргә китәрбез.

## *Укучыларыма*

Сез гел сынап карамагыз
Минем һәрбер фигылемә,
Минем һәрбер шөгылемә,
Минем һәрбер шигыремә.

Сез матур яшәсен өчен
Кайчакта мин мәҗбүр булам,
Кайчакта мин Мәҗнүн булам,
Кайчакта мин мәльгун булам.

Шуңа мине тормыш үзе
Я артык саф кеше итә,
Я артык сак кеше итә,
Я артык ят кеше итә.

Сез гел сынап карамагыз,
Алданырсыз, мин бит кеше.
Яшим бары дөнья өчен,
Кылган эшем — дөнья эше.

*Я. Ф га*

Кайчагында артык тупас булсам,
Ачуланма, дускай, син аңа —
Мин бит бу тормышны тазартырга
Чакырылган кеше дөньяга.

Шуна һаман житдиләнә барам,
Күпләр белән керәм бәхәскә.
Хакыйкатькә карап шигырь язам,
Олыгаям тагын бер яшькә.
Шигырь ритмым һаман кырыслана,
Усаллана бара рифмалар.
Рәхәтләнәм, әгәр минем сүзләр
Тупасларга кырыс булсалар.
Бардыр миндә жиңү комсызлыгы
Үлем белән килгәч күзгә-күз.
Бардыр миндә дошман шыксызлыгы
Дошман белән килсәм йөзгә-йөз.
Кайчагында артык ямьсездер мин —
Тик син аңла шулай кирәген.
Бүреләрне жиңәм бит мин, бары
Бүре законнарын өйрәнеп.
Шуңа кайчак артык тупас булам,
Ләкин ачуланма син ана.
Мин бит бу тормышны тазартырга
Чакырылган кеше дөньяга.

●

Ул мәжлес шундый матур иде —
Шәрапларда көлгән алсу төс
Битләрендә һаман уйнап торды,
Ә урамда йөрде соры көз.
Өй артында йөрде үкенүләр,
Без аларны өйгә кертмәдек.
Узганнарны искә алмый гына
Һәр тост саен бәхет күтәрдек.
Бәхетебез чиксез иде безнең —
Тик көз һаман безне күзәтте.
Янгыр булып бәрде тәрәзәгә,
Хәтер булып өзде үзәкне.
Кукта торды көзге соры болыт
Хыянәттән килгән аваздай...
...Ул мәжлес шундый матур иде,
Матур иде, ләкин бик азга.

◇ = ◇

## Рөстәм Мингалимов

# Сүзләр эзлим

Сүзләр эзлим,
Сүзләр эзлим,
Тиздән күкрәр болыт төсле,
Тынып торам шуңа.
Ә каршымда чиксез байлык:
Таулар, урман, сулар;
Күпме иген,
Күпме җимеш тирбәтә басулар —
Җир халкын бишкә тапкырла,
Җитәрлек ич болар...
Соң ни өчен негр сабый
газаплана ачтан?
Сүзләр эзлим,
Сүзләр эзлим,
Тәмам тынгым качкан.
Теге ана ник яшь белән
бусагалар юа?
Аның авыр кайгысы
Минем тынны буа.
Ник тегендә
йортлар яна?
Ялкын уйный күктә —
Очкыннары миңа чәчрәп
тәннәремне өтә...
...Дөнья эчен
һаман ныграк
капшый минем күзләр...
Сүзләр кирәк иде миңа,
Явызлыкны
җиргә кысып
үтерерлек сүзләр.

## Раузага

Ак кар ява,
Ак кар ява.
Эре, йомшак
Ак кар ява —
Казан кары...

Урам тулы
Казанлылар —
Китүләре,
Кайтулары.
Өсләренә
Ак кар ява —
Казан кары...

Бер шат бала
Кар төяган
Чана тарта.
Берсе куйган
Кар кисәген
Түбәсенә...
Син кар чөймә
Турыбызга,
Иркәм, юрап:
Кемгә төшсә
Шуның рәхәт
Күрәсенә.
Мондый юрау —
Мине борчый,
Сине — белмим

. . . . .

Күрәсене
Аерым-аерым
Күрмик бары.

. . . . .

Нинди яхшы!
Икебезнең өскә ява,
Эре, йомшак
Ак кар ява —
Казан кары.

## Без бер дөнья

Әллә ничек кенә очраштык та
Икәү киттек, һаман барабыз.
Арабызга салкын керер иде,
Калмады шул инде арабыз.
Безне аерым-аерым танып булмас,
Бер-беребезгә шундый охшаштык.
Теләкләребез дә, киемнәр дә
Тиеннәр дә безнең тоташты.
Без бер дөнья, бер якадан тоткан
Ун бармаклы мифик кул төсле.
Без бер дөнья һәм шыр-ачык дөнья,
Янгыр астындагы кыр төсле.
Җайлашсыннар кырга, яшәсеннәр
Шау-гөр килеп анда кешеләр;
Берәү «яхшы!» дисен дөньябызны,
Берәүләре «начар!» дисеннәр —
Мондый сүзләр ул бихисап була.
Сүзгә абынып тормыш чайкала,
Портлар уалалар, кеше егыла;
Дөнья басып кала, сау кала.

## Шулай кирәк...

Син яшәгән шәһәр — ваза түгел,
мин — вазага куяр гөл түгел.
Сиңа яхшы булса монда калу,
миңа яхшы булыр китүем.
Курыккансың икән минем белән
мин теләгән якка китәргә,

ташла инде, үзганнарны сөйләп,
«сөю», диеп, вакыт үткәрмә.
Үзсүзлеген, катылыгың бар, дип,
холкымны да миңа аңлатма.
Дөрес юнәлешне юллар бирә,
каршылыклар дөресен аңлата...
Синдә булган китап миндә дә бар,
яшә әйдә анда әйткәнчә.
Китап улы түгел, ир улы мин,
мин юлдашны сайлыйм эткәмчә:
Юлдаш булса, ил таянган иргә
таянырга курыкмасын ул,
кирәк чакта тотар көчем булып,
янәшәмә басып барсын ул.
Үзсүзләнеп, хәтта усалланып
тормыш сөйгәнемне төшенсен.
Киңәш бирсен миңа йомшарырга,
катылыгым өчен кичерсен.
Мин сөенәм икән, миннән артык
сөенә торган булсын юлдашым.
Мин бәреләм икән, еламамын,
Минем өчен юлдаш еласын.
Аны юатырга, елмайтырга
көч табылыр минем йөрәктә.
Агач өйдә мине үстергән семья
миңа тимер гадәт өйрәтте.
Шуңа сөя беләм, курка белмим,
телисенме, юлдаш итәмен?
Теләмәсән, мин сөйсәм дә сине,
бик сөйсәм дә, ташлап китәмен.
Шулай кирәк... Шулай сиңа яхшы;
шулай яхшы булыр миңа да;
кешеләргә шулай яхшы булыр,
шулай яхшы булыр дөньяга.
Дөнья якты ич ул, юллары таш,
шуннан узалмабыз бит инде,
уңын сулга, сулын уңга кигән
икебез ике туфли шикелле.

## Хәтерләү

Син ак каен идең —
Ләкин яшенме мин?
Хәзер белдем,
Начарлыгым тигән сиңа,
Яшермимен,
Ләкин яшенме мин?

Болыт булып кабардым,
Күкрәдем,
Язгы яңгыр булып
Койдым,
Тойдың,
Яшәрдең...
Яшермимен.
Ләкин...
Сине суккан яшенме мин?!

## Сорама, Камышлы

Сорама, Камышлы,
Сөйли алмыйм әле.
Гаҗәбрәк әле —
Әнвәребез хәле.
Кыска гына әйтсәм:
Таза гына иде.
Яза гына иде,
Яза гына иде...
Матбугат йортына
Сыялмыйча тавышы
Җиргә җәелә иде,
Тәрәзәләрдән ташып.

Бу дөньяны уйлап,
Кем генә авырмый.
Әнвәрдәй шагыйрьгә
Авыру — авырмы?!
Җиңел генә атлап,
Зур фәлсәфә белән
Кешеләргә таба
Һаман килә, килә —
Кинәт гаҗәп булды:
(Тордым карап, күреп)
Ул яшеренде яшьләр
Йөрәгенә кереп.

## Шигырьләрем белән сөйләшү

Ни дисез!
Бездә горурлык,
бездә көч бар, дисезме?
Без сине кеше
иттек, дип,
әйтергә телисезме?
Киендердек, туендырдык
дияргәме уегыз?
Соң үзегез сез ни киеп,
ни белән туендыгыз?
Йөрәгемнән өлеш-өлеш
сезгә бирмәдемме мин?
Ярсу җаным җылысына
сезне төрмәдемме мин?
Кабатланмас язларымны,
кояшлы көннәремне,
Айлы төнем, сөйгәнемне
мин сезгә бирмәдемме?
Ни калды минем үземә,
ни калды, беләсезме?!
Алыштык, дәрәҗә бирдек
һәм гомер диярсезме?
Күрәмен галәм алдында
дәрәҗәм күпмелеген.
Беләм ачы дөреслекне:
исем гомер түгелен.
Булса миндә биргәнегез...
күпсенсәгез...
алыгыз...
Ә җиргә мин сезсез тудым,
сез минсез тумадыгыз.

## Ибраһим Салахов

# ИРТӘНГЕ ОЧРАШУЛАР

*Этюдлар дәфтәреннән*

Гадәттәгечә, ул көнне дә мин иртә уяндым. Палатадагы иптәшләрем рәхәтләнеп йоклыйлар иде әле. Акрын гына киендем дә, идән такталарын шыгырдатмаска тырышып, сак кына атлап верандага чыктым.

Дымсу, салкынча һава битемне юып алгандай булды. Җинеләеп, җегәрләнеп киттем. Йокы бөтенләй качты. Шулай да әйләнә-тирәне ачык күреп булмый әле. Эңгер-меңгер. Веранда алдындагы мәйданда, тыгызланып, калын, кара карагайлар басып тора. Алар башларын бер-берсенең җилкәсенә салып, аяк өстеннән генә калгыйлар сыман. Һавада әчкелтем карагай сагызы исе... Аңа кайдандыр килгән тәмле алма исе кушылып китә. Борын рәхәт кытыклана. Хуш ис! Эссе далада озак йөреп сусагач, кинәт чылтырап аккан салкын чишмәгә килеп чыгып, шул чишмә суын эчкән кебек йотлыгып эчәм — авызымны зур ачып, бөтен күкрәгем белән сулыйм мин. Нинди татлы һәм шифалы бу иртәнге нарат урманындагы һава!

Тирә-якта шылт иткән тавыш та юк. Гаҗәп бер самими тынлык. Әйтерсең, бөтен табигать тирән бер йокыга талган да шуннан уяныл китә алмый. Күрәсең, артык ләззәтле ул иртәнге, язгы таң алдындагы йокы! Нигә әле мин болай вакытсыз торып, гомуми тынлыкны бозып йөрим? Әллә киредән палатага кайтып, рәхәтләнеп йоклап алыйм микән югыйсә? Чү! Кинәт минем уйларымны бүлдереп, кемдер сузып сызгырды. Имәнеп киттем. Аннан соң тагын элекке кебек үк тирән тынлык урнашты. Күз кабакларым авыраеп, тагын йокы баскандай булды. Мин инде чынлап палатага кайтырга ниятләп борылган гына идем — карагайлар башында гаҗәп бер чыр-чу, талпыну, тынгысызлык башланды. Ирексездән тукталып калдым. Бер акрын-сузып сызгыру, бер нечкә тавыш белән өзеп-өзеп алу, шап-шап итеп томшык шартлату, яки, тальян телләрен югарыдан түбән басып төшкән кебек, әле нечкә, әле калын тавышлар авазы һәм искиткеч музыкаль аһәң. Никадәр сөенеч, никадәр ашкыну һәм илаһи моң бу иртәнге хорда. Сихерләде, үзенә буйсындырды һәм каядыр еракка-еракка алып китте ул мине.

Ниһаять, мин уяндым. Тынлык, әле генә чыр-чу килеп ярсып сайраган кошчыклар каядыр очып юк булганнар. Инде яктыра башлаган. Карагайларның биек-биектәге очлары кызарган. Алардан тирә-якка алсу шәүлә түгелә. Менә иртәнге талгын җил исеп китте — карагайлар чак кына чайкалып башларын иделәр. Урман эченнән тонык бер яңгырау үтте, әйтерсең, диңгез дулкыннары ишелеп ярга сугылдылар.

Мин үземнең таныш сукмагыма төшеп, көн дә иртән бара торган аланыма таба атладым. Авыру калса да, гадәт калмый, ди казакъ халкы. Бик дөрес икән. Менә мин, бу иртәнге сәяхәткә гадәтләндем дә, хәзер инде алангa барып бер йөреп кайтмасам — ашым аш түгел. Кайбер иртәләр салкын, җилле була. Кайберләрендә яңгыр ява. Ә мин барыбер менә шушы тар сукмактан аланга таба атлыйм. Гадәт...

Һәр елны ял вакытым якынлашуга мин менә шушы «Воробьевка» ял йортына путевка алу хәсрәтенә сабышам. Бары шунда гына омтылам. Башка җирләр, хәтта Бурабай да мине үзенә ул хәтле тарта алмый. Билгеле инде, Бурабайның «Зәңгәр күл» ял йортында бер генә тапкыр булган кеше дә миннән көләр.

— Юләр, тапкан ял итә торган урын. Менә ичмасам Бурабай! Анда күзнең явын алып, сокландырып торган мәһабәт Кукчәтау. Сөнге булып очланып күккә ыргылган кызыл гранит кыя «Үк җитмәс». Менә шул кыяның итәгендә җәйрәп яткан күгелҗем күл... Яр буенда рәт-рәт булып тезелеп утырган гранит сфинксләр, катлау-катлау булып күтәрелгән сандык ташлар... Күз яше кебек саф, эчеп туймаслык тәмле су һәм ял итүчеләрне үчекләп, бер таштан икенче таш астына качып-сикереп уйнаклаган кызыл канатлы көмеш балыклар... Бурабайдан да гүзәлрәк һәм шифалырак ял урынын табарга мөмкинме соң? «Воробьевка» исә туздырылып ташланган чыпчык оясы гына бит ул.

Бәхәсләшмим. Бурабай турындагы сүзләр — дөрес сүз. Әмма мине һаман да «Воробьевка» үзенә тарта. Ни өчен? Мөгаен, монда мине үзенә бәйләүче беренче сәбәп — тынлык, табигыйлек. Монда бер нәрсә дә башкалардан аерылып, күтәрелеп, үзен күрсәтеп масаймый. Мондагы өйләр дә, өй тирәсендәге каралтылар да, аларны үзенә яшереп җил-яңгырдан саклап торган карагай урманы да — барысы да бер-берсенә ятышып, бер-берсен тулыландырып торалар. Әйтерсең, алар тумыштан бер гаилә, бер авыл. Монда табигать үзе йокымсырап ял итә. Шуның өчен монда килеп төшүгә дөньяның шау-шуы, мәшәкате үзеннән-үзе онытыла. Син, самими табигать кочагына кереп, ару-талуларыңны, кайгы-хәсрәтеңне онытасың һәм онытыласың.

Тимер юл станциясе белән «Воробьевка» ял йорты арасы утыз километрлар чамасында. Бу юл гел карагайлы каен урманы арасыннан килә. Кышын да, җәен дә бу юл сокландыргыч матур. Бөдрә чәчләрен тузгытып җибәреп, башларын биек күтәргән егет карагайлар, аларга ияреп югары үрелгән нечкә билле каеннар сине бөтен юл буенча озатып баралар һәм алар нииндидер серле әкият сөйлиләр кебек. Җәен монда салкынча — күләгә. Кышын буран юк — тын. Ял йортына житәрәк юл икегә аерыла, берсе — якындагы авылга, икенчесе — ял йортына алып китә. Ял йортына бара торган юлның сул ягында — урман читләп Сарысу исемле кечкенә бер елга ага. Ул үзе тар, үзе сай. Аның агуы да сизелми кебек. Ә суы шундый саф, төбендәге ком бөртекләре мәрҗән кебек чекерәеп яталар. Яр кырыена сузылып ятып — чөмереп яки учың белән генә алып Сарысу суын татып кара әле, эчкән саен эчәсең генә килеп торыр. Һич арттырмыйм, лимонадның бер якта торсын. Кояш чыккан вакытта бу елга буена кызык өчен генә килсәгез иде. Исегез китәр! Сарысу ыгы-зыгы килә. Балыклар сабый балаларча гамьсезлек белән «башларын югалтып» уйныйлар. Бер-берсен куалар, качалар, кинәт кара-каршы килеп чыгалар да сикереп китеп елга өстенә күтәреләләр һәм көмештәй ялтырап киредән суга чумалар: чалт-чолт, чалт-чолт... Елга өстенә исәпсез күп шундый көмеш айлар ява.

Мин сукмактан акрын гына атлыйм. Ул башта ял йорты биналарын алкалап урап чыга, шуннан соң гына аланга бара торган юлга борыла. Биналар дигәннән, монда алар әллә ни күп түгел. Ял итүчеләр тора торган өч өй, ашханә һәм контора. Алар барысы да шушы урмандагы карагайлардан бурап салынган, такта түбәле бер катлы өйләр.

Тәрәзәләре дә, хәзерге заманча, зур түгел, әйтергә кирәк, уртача зурлыкта — йортның биеклегенә карата таман гына. Ә менә тәрәзә янаклары тамбурлап чиккән сөлге башы кебек өлге-өлге. Иренмәгән җаннар бар бит дөньяда... Такта, останың тырышлыгы белән, чәчәкләр тезмәсенә әверелгән... Алар ерактан ук игътибарны үзенә тарталар һәм күңелгә ниндидер бер сөенеч өстиләр. Бурәнәләр, әле бүген генә бурага менеп яткан кебек, тазалар, күзәнәкләреннән гәрәбә-гәрәбә сагыз саркып чыккан.

Ял итүчеләр тора торган йортлар уртада мәйдан калдырып «П» хәрефе рәвешендә утырганнар. Верандалар, ишекләр шул мәйданга чыгалар. Мәйданның уртасында — буйдан-буйга сузылган клумба. Ул хәзер ямь-яшел — хәтфә келәм кебек. Нәни кыяклар әле шытып кына чыкканнар. Чәчәкләр үзләренең аллы-гөлле кыңгыраучыкларын ачып җибәрергә өлгермәгән. Ә менә клумбадан ары — ак йорт буена тезелеп баскан ранеткалар шау чәчәктә — ак күбек булып күтәрелгән фонтан диярсез! Әбәү, күз тимәсен, бигрәк тә матур булганнар. Мин әле үзем дә аларны менә хәзер генә күреп туктадым. Мөгаен, әле бүген төнлә генә чәчәк атканнар алар. Әйтәм, баягынак верандага чыгуга борынга алма исе килеп бәрелгән иде. Менә кайдан килгән икән ул тәнне рәхәтләндерә, күңелне рухландыра торган хуш ис...

Тәрәзәләрдә әле ак пәрдәләр. Ишекләр ябык. Мәйдандагы һәм аллеядәге урындыклар, кызып-кызып домино, шашка уйный торган өстәлләр буш. Ял йорты йоклый. Бары урман кырыендагы ашханә ягыннан гына кычкырып сөйләшкән һәм так-ток итеп утын яргән тавышлар ишетелә.

Мин, ял йорты әйләнәсен гадәтемчә бер урап чыккач, сәфәрнең төп юлына, аланга таба борылдым. Ял йорты территориясе авылдан рәшәткә койма белән бүленгән. Керәп-чыгып йөрер өчен уртада кечкенә җил капка. Капкадан чыгуга — юл башлана. Ул каршыдагы урманга керә дә, алан аркылы үтеп, каядыр еракка китә. Мин шул олы юлга чыктым.

Урман кырыендагы караltыларның берсе артында ниндидер әтәч кычкыра башлады да, карлыгып, сузып җиткерә алмыйча, туктады. Әмма аның тырышлыгы бушка китмәде. Ул күрсәнеп туктауга, берничә әтәч бер юлы гайрәтле тавыш белән бөтен тирә-якны яңгыраттылар... Юл урман эченә керде. Нәкъ баш өстемдә генә тукран тукылдый. Шуны күрим дип башымны күтәреп карагайларга карап барганда аяк астыннан гына бер җәнлек атылып чыгып котымны алды. Чак кына абынып егылмадым. Туктадым. Нәрсә булыр соң бу елгыр җан? Тирәякка карана башладым... Тукта, әнә теге карагай ботагында тирбәлә түгелме? Якынрак барыйм әле. Әй хәерсез, менә нәрсә котымны алган икән. Әле үзе күренми, ямь-яшел карагай чуклары арасыннан зур, мамык койрык кына салынып төшкән. Карагайның икенче ягына чыктым... Һәй наян да соң бу тиен дигәнең — алгы тәпиләре белән карагай бөресен тоткан, исе дә китмичә, шуны кетер-кетер кимереп утыра. Иртәнге ашын ашый. Миннән уздырган.

Ул арада ерактан бер ялгыз күкенең зарлы тавышы ишетелде.

— Күк-күк, күк-күк.

Сарысу елгасына житәрәк, юл кырт кына сулга борылды. Бу ни бу? Каен яфрагы исе сыман. Кайдан килә соң? Бу тирәдә бер генә каен да күренми ләбаса? Барган саен, көчәеп, шул ис борынны кытыклый башлады. Мин еш-еш сулап, тирә-якка карана-карана тизрәк атлый башладым. Беләсе килә бит. Озакламый каен яфрагы исенең «сере» ачылды. Сарысуга төшә торган сукмакта озын, чандыр гәүдәле кеше күренде. Башына чалма итеп сөлге ураган. Түше-бите чөгендер кебек кызыл. Култык астында — каен себеркесе. Ул әле килеп җитәр-җитмәс үк, башын ия-ия, калын тавышы белән гөрелдәде.

— Хәерле иртә.

— Рәхмәт. Җинел пар белән,— дидем мин һәм үзем дә сизмәстән әстәп куйдым, — сез бигрәк тә иртә парлангансыз.

— О! — Себеркеле кеше элеккедән дә катырак гөрелдәп янымә туктады, чалмасын сүтеп пләш башын, чөгендер битен, йөнтәс күкрәген сөртте. Аннан тагын сөлгесен башына чалып, «булды бит» дигәндәй, сул күзен хәйләкәр кысып гөрелдәргә тотынды.— О, о! Беләсенме, бүген мин иң бәхетле кеше. Ышанмыйсың? Юкка. Гафу итәсен, бер минут, хәзер барысын да ачып салам. Ял йортына мин бүген иң беренче автобус белән килеп төштем. Беләсең инде, Алма-Ата — Свердлов поезды Боровое станциясеннән төн уртасында гына уза. Станциядә «балык тотып» утырырмын дип исәпләгән идем. Ялгыштым. Вагоннан төшүгә — автобус... Здорово! Инде ял йортына житүгә — капка төбендә сестра-хозяйка: «Хуш киләсез. Бәлкем, мунча чабынып чыгарсыз, бүген генә яшь каен себеркеләре китердек», ди. Битеннән чүп итеп үбә яздым үзен. Әмма (сул күз кысылды, авыз ерылып куйды), дөресен әйткәндә, батырлык житмәде... Яшь олырак, каһәр суккыры. О, мунча, каен себеркесе ул минем стихия. Чемоданны әлеге шул матур сестра-хозяйкага тоттырдым да, сөлге-сабын алып, йөгердем мин. О, гажәп, гажәп мунча! Суы... пары... себеркесе... нәкъ Себердәге кебек. Мин үзем тайгадан адашкан аю — геолог... О!.. Гафу ит, мин сине юлында туктаттым, ахрысы... Хәерле сәяхәт. Күтәренке кәеф һәм отличный аппетит телим.— сул кул югары күтәрелде, чалмалы баш иелде — хуш! Гафу итәсен!..

Бу «тайгадан адашкан аю»ның күтәренке кәефе мине дә рухландырып жибәрде. Мин дә, гомердә булмаган рәвештә, ике кулымны күкрәгемә кушырып, башымны иеп хушлаштым.

— Күнелле ял итегез!

...Урман өстендә кояш нурлары чайкала. Ә менә наратлар төбендәге яшел үлән өсте ала-кола: әле кояш шәүләсе, әле күләгә. Тагын шәүлә, тагын күләгә. Урман эченә юлбарыс тиресе жәелгәнмени. Мин, юлдан борылып, агач арасына кердем. Былтыргы яфраклар һәм карагай бөреләре арасыннан яшел үлән шытып чыккан. Аяк басуың да сизелми, нәкъ хәтфә келәм өстеннән барган сыман. Мин балаларча бер кызыксыну, куану белән атлыйм. Нинди йомшак. Нинди пакь. Чү, нәрсә ул яфрак астында кызарып яна? Иелдем. Нәзек кенә яшел сабакта ике бөртек кызарып пешкән каен жиләге — менә хәзер тамам, тамам дип тора. Бер сабакны өзеп алдым. Иренемә тиюгә эреп китте. Үзе әчкелтем, үзе салкын. Әнә теге киң кузгалак яфрагы астында тагын кызыл чаткылар күренә түгелме? Ашыгып шунда үреләм — жиләк! Шундый тәмле, чын-чынлап телеңне йотарсың. Кемгә ничектер, минем яратканым — каен жиләге. Җир жиләге күе үлән арасында яшеренеп үсә. Аннан соң ул каен жиләге кебек ачылып түгел, сабакта ук төренеп, оясына посып утыра... Тәме дә искитәрлек түгел. Ул әле шулай яшеренеп утырып пешмичә дә кала.... Ә каен жиләге! Ул бөтенләй башка — урманга кергән һәр кешене куандырып, ымсындырып тора. Менә хәзер дә яна гына күтәрелеп килгән яшь карагай артына чыгуга имәнеп киттем — кызыл мәржән сипкәннәрмени? Кайсын өзәргә белмим. Берсеннән-берсе кызыл. Әнә теге төп артында тагын да зурраклары, тагын да кызылраклары утыра... Аны тәмләп йотуга, башка яфраклар астында тагын да кызыл чаткылар кабына...

Белмим, жиләк белән «авыз ачуым» күпмегә сузылыр иде — мине тәгәрмәч дыңгырдавы һәм ыңгырашуга охшаш басынкы бер тавыш сискәндерде. Башымны күтәрдем. Бәй, бөтенләй оныткаммын... Алгы ягыннан сузылган юл борылышында дустым басып тора ич. Һәр иртәне без нәкъ шушы тирәдә очрашабыз. Мин аланга барам. Ә ул аланның аръягындагы урман каравылчысы өеннән ял йортына килә. Аның тәдында һәрвакыт ике тәгәрмәчле арба тәгәри. Күрәсең, ул аннан һич-

бер вакытта да аерылмый. Аерыла икән, бәлки, бары тик йоклаганда яки аш ашаган арада гына аерыладыр.

Минә хәзер дә аның алдында — ике тәгәрмәчле арба. Арба өстендә гадәттәге эш кораллары — киң агач көрәк, кызгылт кабыклы, кабарып торган тубылгы себерке.

Бу кешене очратуга мин һәрвакыт Иван Сергеевич Тургеневның «Муму» хикәясендәге дворник Герасимны хәтерлим. Ул да тумыштан телсез, чукрак булa бит. Дөрес, Герасим ике метрга якын буйлы, киң-таза гәүдәле, гаҗәп көчле, баһадир сынлы кеше. Аның яше дә утыз-кырык тирәсендә, сакалы да чем-кара була. Ә минем танышка инде җиденче дистә киткән. Бue — урта, гәүдәсе — чандыр. Сакал — арба-сындагы көрәге кебек киң, ап-ак, күкрәгенә төшеп тора. Башында елтыр козыреклы, биек, күксел бәрхет кырпулы фуражка. Ул аны, нигәдер, күзенә хәтле төшереп басып кия. Өстендә озын җиңле кара сатин күлмәк. Аның өстеннән күкрәкчәле киндер алъяпкыч бәйли. Чегәннәр-неке кебек киң, кара сатин чалбар. Аякларда һәрвакыт дегет белән «туйганчы» майланган керза итек.

Шул яшьтә булуга карамастан, ул үзе бик тере, эшчән, тырыш. Без инде дүрт ел танышбыз. Әмма бер генә тапкыр да минем аның эшсез, тик утырганын күргәнем булмады. Аңа гел эш табылып тора. Ул да Герасим кебек дворник, ял йорты территориясен җыештыра һәм, нәкъ Герасим кебек үк, үз хуҗалыгында тәртип, пөхтәлек булуны ярата.

Ял йортының территориясе зур. Парк. Урман. Футбол, волейбол һәм башка уеннар мәйданы, аллеялар, сукмаклар, чәчәкләр клумбасы. Палата тирәләре. Кыскасы, эш тулып ята. Ял итүче халыкның да төр-лесе бар. Кайсысы тәртипле, ә минә кайберәүләре янындагы утыргычка утырып тәмәке тарта да төпчеген клумба өстенә ташлый. Ә кайберәү-ләре арлы-бирле йөреп көнбагыш чиртә...

Минем дус андыйларны тиз күрә. Ул, кинәт җир астыннан калык-кандай, нәкъ теге тәртип бозучының артыннан килеп чыга да башын чайкый һәм, ташланган төпчеккә кулы белән төртеп күрсәтә-күрсәтә, тамак төбеннән гырылдаулы тавыш чыгара.

— Го-го... Го-го...

Аннан бик җәһәт кенә барып төпчекне ала, арбасындагы кәрзингә салып китеп бара. Ул бер җирдә туктап тормый, гел йөреп, бер урынны көненә әллә ничә тапкыр җыештырып, себереп үтә. Минә шун-дый тынгысыз җан ул минем дус бабай. Исеме ничек соң? Кызганычка каршы, белмим. Мөгаен, аны белүче дә юктыр, чөнки аның белән бары ишарә-ым белән генә аңлашасың бит.

Ул үзе эшкә һәр көнне бер вакытта, минә бүгенге кебек, кояш күтәрелә башлаганда килә. Ә өенә кояш баеганда гына кузгала. Бөтен көне ял йортында үтә — көри, себерә, арбасына чүп-чар тутыра. Аны каядыр алып барып түгә дә тагын кайта.

Мин аның туктап кем белән булса да сөйләшүен (билгеле инде, ишарә-ым белән) яки кемгә булса да кызыксынып карап торуын күр-мәдем. Аның бар игътибары — җирдә, янәсе, анда берәр төпчек аунап ятмыйммы...

Минә ул беренче очрашудан ук ияләшеп-үзләшеп китте. Бу хәл моннан дүрт ел элек булды. Бу ял йортына минем беренче тапкыр килүем иде әле. Әле дә хәтеремдә, ул көнне дә бүгенге кебек үк иртә уянып верандага чыктым. Бу карт безнең корпус тирәсен җыештырып йөри. Ә ул көннең иртәсе бүгенгегә һич охшамаган, болытлы, күңел-сез иде. Өстәвенә төньяктан каты, салкын җил исә. Ара-тирә «шай-тан туе» килеп чыгып, әйләнә-тирәдәге кәгазь кисәк ләрен бөтереп алып күтәрә дә, кинәт туктап, чәчеп җибәрә башлый. Әле яңа гына карт себереп үткән җиргә тагын газета битләре, папирос пачкалары һәм башка чүп-чар чәчелә. Карт тагын себерергә, чүп-чарны бер җиргә җы-

ярга тотына. Инде өемне көрәк белән алып арбадагы кәрзингә салам дигәндә генә, әллә кайдан килеп чыккан җил аны туздырып кача. Карт тагын себеркесен күтәреп кәгазьләр артыннан китә. Алары да карт килеп житкәнче тыныч кына яталар, ләкин инде себерке белән кагылырга өлгермисен, янадан күтәреләләр дә икенче жиргә куналар. Иҗегәрә-йөгерә тирләп бетте, мескенем. Мин түзмәдем, верандадан төшеп, үчекләп, очып-кунып йөргән кәгазьләрне карт белән бергә ауларга керештем. Икәүләп тотынгач, кәгазьләр әлекке кебек «шаяра» алмадылар, кәрзингә бик тиз керергә туры килде. Шуннан соң карт көрәген, себеркесен арбага сузып салды да минем янга килде. Ул әлек фуражкасын салып уң кулына тотты, аннан пеләш башын ялтыратып берничә тапкыр иелде һәм тамак кырган төсле тавыш чыгарды. Бу, мөгаен, аның рәхмәт әйтүе иде. Мин дә аңа чын хөрмәт белән баш идем.

Шуннан бирле бу карт мине кайда гына очратса да, арбасын туктата, фуражкасын сала, берничә тапкыр башын ия һәм нәкъ теге, беренче очрашудагы кебек тавыш чыгара.

Менә бүген дә ул мина үзенең иртәнге сәламен бирер өчен юл уртасында туктап калган. Гадәттәгечә, алда — арба. Арбада көрәк белән себерке. Картның кәефе бүген көндәгегә караганда шактый күтәренке сизелә. Бу юлы ул фуражкасын башыннан алуга дәррәү иелмәде, авызын ачып, елмаеп озак кына карап торды, аннан соң гына иелде. Башка вакытта ул башын ике генә тапкыр ия иде, бу юлы дүрт тапкыр һәм бик түбән итеп иелде һәм урманны яңгыратып:

«Го-го, го-о»,— диде.

Фуражкасын гадәттәгечә башына кимичә, алан ягына сузды һәм тагын: «Го-го»,— дип кабатлады.— «Аланга барасызмы?» диде бугай. Мин дә башымны иеп, елмаеп аның сүзен-ишарәсен расладым. Чыннан да, мина инде аланга чыгарга вакыт бит, онытып җибәргәнмен.

Бу чатта — юл бормасы. Аланга барыр өчен хәзер шул юл уртасында тукталган карт яныннан узарга кирәк. Ул һаман авызын ачып, елмаеп мина карап тора иде. Эх, сөйли белсә, менә хәзер рәхәтләнеп бер гәп сугып алган булыр идек тә бит... Шулай уйланып карт янына житүемне сизми дә калдым. Ул арада карт алъяпкычының күкрәкчәсеннәнниндидер бер төргәк алды да җәһәт кенә минем костюм кесәсенә тыкты. Аптырап киттем. Нишләве бу? Нәрсә салды ул кесәмә? Аны туктатыйммы, әллә кесәдәге төргәкне ачып карыйммы? Мин шулай аптырап, кабаланып бер фикергә килгәнче, арба чаттан борылып әллә кайда тәгәрәп бара иде инде. Карт күздән югалды. Мин кесәмдәге төргәкне алып, газетаны җәеп җибәрүгә хәйран калдым. Анда сабаклары белән өзелгән бер уч кып-кызыл каен җиләге иде.

Мин аланга таба кузгалдым. Агачлар арасыннан кызарып гранит ташлары күренеп кала. Кайсылары судан башын чыгарган дельфин сыман басып торалар. Кайсылары бик зур әкәм-төкәм кабыгы төсле куышланып, уралып ята. Ә менә юл чатындагы ике таш аеруча мәһабәт һәм тантаналы — гаять зур диңгез кораблары яр буена килеп житкәннәр дә кара-каршы туктаганнар төсле. Шулар өстендәге мачта кебек булып, озын, төз карагайлар басып тора. Кайбер иртәләр томанлы булалар. Менә шундый иртәләрдә мин бу ташлар янына житкәч, туктапып бик озак карап торам. Әйләнә-тирәдә аксыл томан. Ә бу ике мәһабәт гранит таш, әйтерсең, диңгез кораблары булып, дулкыннар өстендә йөзәләр...

Бүген томан юк. Болытсыз, кояшлы иртә. Юл чатындагы гранит кыялар әйләнә-тирәгә салкын күләгә ташлап тантаналы тынлык саклыйлар.

Бу кыялар үзенә күрә бер чик капкасы. Моннан чыгуга урман ике якка аерылып китә дә берничә километр ара үткәч кенә килеп кушыла. Уртада аланлык барлыкка килә. Монда болындагы кебек бай пе-

чәнлек. Яңгырлы елларда бу аланнарда үлән күкрәктән булып үсә. Бик күп төрле исле чәчәкләр атканда бу аланга килсәгез иде сез! Шундый тәмле хуш ис! Монда җан да, тән дә ял итә. Шуның өчен дә мин һәр иртәне бирегә ашыгам. Менә бүген дә.

Гранит капканы үтеп аланга чыктым. Тукта, бу ни гаҗәп? Күзләрем чагыла. Каршымдагы күренешкә хәйран калып туктадым. Әйе, гаҗәп күренеш иде бу.

Алан энҗе һәм сапфир бөртекләреннән тукылган искиткеч матур бөркәнчек ябынган. Алан читендәге калын, төптән үк ботакланып күтәрелгән карагайларның һәрбер ботагыннан, һәрбер чугыннан бриллиант муенсалар асылынып төшкән. Күтәрелеп килгән иртәнге кояш нурларында алар, салават күперенең барлык төсләрен чагылдырып, кызгылт, яшькелт, саргылт чаткылар булып балкыйлар. Чыннан да, бу нинди тылсымлы күренеш соң? Бәлкем, бу бары мираж — күз алдануы гынадыр?!

Мин аланның нәкъ уртасыннан узган юл буенча алгарак атладым. Юк, күз алдануы түгел иде бу. Кояш Күкчәтау үркәчләреннән өскәрәк күтәрелгән саен алан ялкынлаша бара һәм күзне катырак чагылдыра. Бу нинди могҗиза? Аптырап тагын туктадым. Бары бик озак карап торгач кына төшендем.

Беләсезме, бу могҗизаны кем иҗат иткән булган? Үрмәкүчләр... Алар бу төнне йокламаганнар — бөтен алан өстенә, карагай ботакларына пәрәвез сузып чыкканнар. Таң алдыннан чык төшкән. Пәрәвез өстендә миллионлаган чык тамчылары. Кояшның беренче нурлары әнә шул тамчыларда чагыла һәм искиткеч бер матурлык белән балкый.

Мин бу күренештән күзләремне ала алмыйча бик озак сокланып карап, онытылып тордым. Кинәт нәрсәдер кыштырдагандай булды. Борылдым. Минем янымда гына кызгылт бер бозау басып тора. Аяклары — нечкә, озын. Колаклары зур, салынып төшкән. Ул йөгереп арыган, ахры, еш-еш мышный, зур, соргылт күзләре белән миңа аптырап карый. Мескенем, адаштыңмы әллә? Әниең кайда соң? Син әле бик еракка йөри дә алмыйсыңдыр, бигрәк яшь күренәсең. Әллә яңа гына аякландыңмы? Яратып сыйпыйм әле үзенне... Сискәнеп киттем. Чак кына кузгалуым булды, янымда дерелдәп, мышнап торган бозау кинәт башын күтәрде дә сикереп чапты... Мин абайлабрак караганда ул әллә кайда, алан уртасында бриллиант тамчылар чәчрәтеп йөгерә иде инде.

Минем бүгенге иртәдә очраткан юлдашларымның соңгысы — даланың иң йөгерек җанварларының берсе — архар баласы булып чыкты.

Мөдәррис Әгъләмов

# ЕРАККА КИТЕП КАРА

*Туган җирем — Зәй районы Биш-Субашы авылы.*
*Туган елым — 1946.*

*Чаллы районы Түбән-Биш урта мәктәбен 1964 елда тәмамлап Казанга килдем. Университетка кергән беренче көннәремнән үк мине гаҗәп бер тойгы биләп алды. Дөньяны акка һәм карага гына аерып йөргән малайга уйланырга урын күп иде... Мин тормыштан ерак торып, сүзлекләр һәм әдәби китаплар эченә күмелеп калдым.*

*Бер җәйне халык иҗаты җыю буенча Свердловск өлкәсенә чыктык. Халык ул үзенең асыл ирләрен югалтмый... Бабичны җырлап йөри, Акмулланың тапкыр сүзләре белән җавап кайтара. Тукай турында әйткән дә юк, ул халыкның җанына әверелгән...*

*Без биредә Уралның кайда икәнен генә түгел, шагыйрьнең җирлеге яки таяну ноктасы кайда икәнен дә белеп кайттык.*

*Хәзер Чаллы халык театрында эшлим. Казан педагогия институтында читтән торып укыйм. Гомер яңа башлана. Миңа тормыш дөньяга ачыграк карарга, офыкның Казанда гына түгел, офыклар артында да офыклар барын аңларга ярдәм итте...*

*Беренче шигырьләрне әнием вафат булганнан соң яздым... Ул чакта башлангыч мәктәптә укый идем. Шагыйрьләр мине шәхес буларак тетрәтәләр, шигырьләре белән өйрәтәләр...*

*...Петефи, Лорка, Блок, Җәлил...*

*Алар миңа акны карадан аерырга ярдәм итәләр...*

*Язасы килә, халык мәхәббәтенә тиң әсәрләр тудырасы килә...*

## I. УРАЛ АКЧАРЛАКЛАРЫ



### Юлларга чыксаң да...

Юллар бар җырларда
Җырлар бар.
Җырлар бар юлларга
Юллар бар.

«Ләкин» бар тормышта, «әмма» бар,
Юлларга чыксаң да, гел шулар.
Зилзилә бураны йөрәктә,
Исемсез кабынган борчулар.
Ярый ла юата җырчылар.

Хәерле юлга дип кузгалдык,
Әлбәттә, тынмады бу йөрәк.
Егылма, нелсәң, нел дип,
Раслады юлымны тал-тирәк...
«Ләкин» бар — әйтер сүз бар, димәк.

Еллары могҗиза тудыра,
Илеңнең сулышын тояр чак,
Рәхәтен, михнәтен күтәреп,
Тамчыга кояштай сыяр чак.
«Әмма» бар — яңа җыр туачак.

## Эзләүчеләргә

— Кем җырлый анда? — Тимерче бугай.
— Кем җырлый анда? — Игенче бугай.
— Кем әйтте моны? — Ә бу мин генә.
— Син үз җырыңны җырлап кил менә.

Тауларда елгалар җырлыйлар,
Тынмыйлар, тынлыкны белмиләр:
Хәрәкәт, хәрәкәт, хәрәкәт...
Туңмыйлар кышын да, гөрлиләр.

Әйтерсең, нәрсәдер эзлиләр,
Язларын җәелеп алалар:
Агалар, агалар, агалар...
Ярларын барыбер табалар.

Җир буйлап барабыз-агабыз,
Ә еллар үз сүзен әйтер бит...
Сөйлиләр, сөйлиләр, сөйлиләр:
Елгалар ярына кайтыр дип.

Ә без соң елгадан киммени,
Елганың җаны юк. Без — кеше.
Яр табып була ул,
Үзеңне
Син үзең табарга тиешле.

## Томан арты...

Тау чишмәсе юл алырмы?
Юл алыр да югалырмы?
Күңел һаман уйланырмы,
Уйланыр да юанырмы?

Бу якларга килеп төшү белән
Бик күп булды шундый бутаулар:
Иртән чыктык, офыкларда урман,
Кая киткән, дибез, бу таулар.

Йомшак кына булып җилләр исте,
Күтәрелде пәрдә-томаннар...
Таулар бары томаннар артына
Кереп кенә качкан булганнар.

Кайчак шулай кешеләрне эзлим,
Сөйләшеп тә куя соң халык,
Калды ич ул, күптән калды, диләр,
Еллар томанында югалып.

Исән-саулар икән, томан белән
Ышандыралмады бутаулар.
Кайчагында томан каплаbelse да,
Таулар булып кала шул таулар.

# Кайтасылар...

Азмыни безнен халыкта
Кандалый, Акмуллалар...
Кара елларда халыкны
Агарткан ак «муллалар».

Оренбурдан чыккан конвойларның
Уртасында барган шагыйрьне
Еллар аша күрәм. Онытырга
Мөмкинме соң җаны сау ирне.

Киләчәккә бармас, дигәннәрдер,
Төрмәләрдә яткан көннәрдә,
Әмма кояш күтәрелгән саен
Кечерәя җирдә күләгә.

Күтәрелде кояш. Сиңа инде
Конвойларсыз кайтыр чак җиткән,
Халык сиңа үз бәясен биреп
Мәңгелеккә сине ак иткән.

Кайтасылар... Азмы кайтасылар.
Бик күп әле алар тарихта,
Мәрҗәнинең мәрҗәннәре менә
Ялтырыйсы көннәр халыкта.

Сез укыткан дала балалары,
Сез җыр язып яткан тирмәләр...
Кешелекнең бөек үсешенә
Мәрҗәниләр белән киләләр.

Сез калдырган шытым гөрләп үсә,
Үзегезгә кайтыр чак җиткән.
Караларга капма-каршы куеп
Халык сезне мәңге ак иткән.

# Җырлар калка

Туган җирдән киткән белән
Китмә ирек.
Туган җырдан киткән ирдән
Көтмә өмет!

Кайсы буын килгән бу якларга,
Кайсы нәсел,
Кайсы бабасы!
Беркем белми моны. Халык моңы
Ишетелгәч тынып каласың.

Үзәннәрдән күтәрелгән җырлар
Таулар әргәсенә кагылып,
Юнәлешен үзгәртә дә оча,
Оча Казан ягын сагынып.

Һәрбер ташка монда җыр сыенган,
Җыр сыенган һәрбер куакка...
Кичләрендә чыксаң, юлдай озын
Халык моңы керә колакка.

Ул моңнарны читкә җибәрмичә,
Саклаганмы Урал таулары!
Таулар түгел, халкым шундый минем,
Тик моңнардан тора бар җаны.

Аларның бит ерак бабаларын
Патша монда сөреп җибәргән..
Җирдән сөргән,
Җырдан сөрәлмаган,
Җырлар калка — калка тирәннән.

## Карт моряк сүзләре

Дингезчегә дингез яры кирәк,
Игенчегә туган ягы кирәк.
Тик шул кирәклекне тояр өчен
Иң беренче олы җаны кирәк.

Дулкыннарга тиеп-тиеп ала,
Бер карыйсың, гади кош кына,
Һәлакәткә якынлашса кораб,
Акчарлаклар үксеп кычкыра...

Алар якын миңа, искә төшә
Мең үлемнән калган чакларым..
Урал итәгеннән эзләп килә
Коры җирнең акчарлакларын.

Причалларын оныт, акчарлагын:
Дингез моннан ерак ич, диләр.
Коры җирдә дә шул җанга якын
Акчарлаклар төсле кешеләр.

# 2. ОФЫК

## Көнчыгышын эзли кеше...

Үткәннең ачысын,
Үткәннең кайгысын
Исенә төшереп...
Яхшыдан яхшыга,
Яктыдан яктыга
Атласын кешелек.

Ераграк киткән саен
Кызык икән бу хәят.
Көнчыгышның көнчыгышын
Күрдек менә, ниһаять.

Уралдагы таш багана
Ул бары билге өчен:
Европасын тап тарихның,
Тап аның Азиясен!

Тауларның бүленеше бар,
Суларның бүленеше...
(Бүленешләр белән үзен
Чикләми микән кеше).

Каберләрне бүлеп була,
Бүлеп була дөньяны...
Үткәннәрне ташлар белән
Бүлеп куеп буламы!..

...Офыкта кояш кызара,
Калка ул кыяр-кыймас...
Көнчыгыш сөргеннәрендә
Баткандыр азмы кояш.

Иртә саен шул кояшлар
Яңадан калка кебек —
Шуңа да көрәшеп яшәү
Теләге арта кебек

...Ул чакта Россия торган
«Теге як»тан, «бу як»тан —
Фикер аерымлыгы булып
Арада Урал яткан...

Бүген гүзәл осталарын
Азиягә күчереп,
Көнчыгышның көнчыгышын
Эзләп бара кешелек.

## Офык

Ничек кенә тып-тын яшәмәсен,
Һәркемнең бар үзенең дөньясы.
Офыклардан күчеп офыкларга
Кеше үзе аны зур ясый.

Офыгыңны киңәйтәсең килсә,
Бу яклардан атла уйланып!
Иң беренче булып урманнардан
Каторжаннар үткән юл ярып.

Бәхет өчен көрәшүчеләрме! —
Юллар туры,
Юллар бер генә...
Карагайлы урманнарга керәм,
Кергән кебек халык күңеленә.

«Син дә Казаннанмы!» дигән сыман
Чыршылары дәшә, яшь-яшьләр.
Шушы юлда богауланган килеш
Ауганнардыр никем яшьтәшләр.

Карагайлар булып шаулый алар,
Кайсы чыршы булып калыккан —

Көрәшчеләр урман булып шыткан,
Аерылмас өчен халыктан.

Курка-курка кердем урманнарга,
Адашсам, дим, көннәр болытлы,
Юкка булган икән; көрәшчеләр
Киңәйткәннәр безгә офыкны.

## Декабристлар күле...

Ничә тапкыр озатканнардыр
Яңгырларны, киек казларны...
Ни яңгыры, ни киек казы
Яхшы хәбәр китерә алмады.

Тимер казыкка бәйләнгән
Яр буенда көймәләр...
Ә дулкыннар уртагандай
Киләләр дә киләләр.
Яр буенда көймәләр.

Дулкыннарны тимер чылбыр
Ыргыта телеп-телеп,
Башыңны комга салырсың
Бәйләнгән көймә кебек,
Сагындырганда ирек.

Комга ятып үкси сыман
Яр буенда көймәләр,
Ирекнең нәрсә икәнен
Дулкыннар шул беләләр,
Киләләр дә киләләр.

## Туганнар

Без бәхетле идекме,
Ил кигәнне кидекме?
Яудан җиңеп кайтканнарны
Кулга алып сөйдекме?

...Туганнар янына килдең
бу якка,
Уйлагансың, яшиләр дип
еракта.
Уйлагансың, аерылган
дип, болар,
Арабызда ята бары
тик Урал.

Авыр чакта ил кигәнне
кидек без,
Ватан анабызны тигез
сөйдек без.
Тарих өчен болгар халкы
идек без,
фашистларга: «Я — русский»
дидек без.

Башкалабыз Казан безнең
һаман да,
Иң хуш исле гөлләребез
Казанда.
Уйлагансыз, аерылган
дип, болар...
Арабызда ята бары
тик Урал.

Үтегез дә аны очар
кош булып,
Я исәр җил булып шунда,
я болыт,
Безнең якларга кунакка
килегез —
Дуслык белән көчле туган
илебез.

Җырлар алып килегез сез
кунакка! —
— Туганнар янына килдек
бу якка.

## Сабантуй...

Сабантуйларда да алга
Карый халык.
Көрәштерә башлый ул иң
Вактан алып.

Сөлгеләр тотыла, һәр авыл
Батырын күзәтә, билгеле...
Мәйдан күк кысыла йөрәкләр:
— Бирмә биленне!
— Бирмә!

Дошманнар таптаса җиреңне,
Сорамый: «Син батыр идеңме!»
Мәйдан күк кысыла бар халык:
— Бирмә илеңне!
— Бирмә!

## Мәйдан сорап килә...

Чит җирдә су коенам,
И, туган Идел генәм!
Чит җирдә су коенсам да,
Йөрәгем синең белән...

Урманнары белән уйларыма
Уралса да сихри яклары...
Төшләремә атылып килеп керә
Туган якның аргамаклары.

Июнь киче, әллә шуңа йөрәк
Авызлыгын чәйнәп уйнады...
Җырларымнан мәйдан сорап килә
Туган якның сабантуйлары.

Бер хат-хәбәр килсә туган өйдән
«Күзен бәйләп» чыга теләкләр... [1]
Бер сугуда чепрәмә килә
Сагыш дигән сары чүлмәкләр.

[1] Чүлмәк вату уенына ишарә.



6*

# Еракка китеп кара

Халкым, халкым, бары бер мизгелгә
Сине читтә итеп хис иттем,
Еракташы кояш турындагы
Әйтемеңне җанда ишеттем.

Җир киләчәге — сабыйлар,
Аларда бүген көнем:
Пионерлар йортында мин
Рәсемнәр карап йөрим.

Башкалар мине күзәтә,
Берсе аңлатып бара:
— Абый, әйдә син монысын
Еракка китеп кара!

Чигенәм, карыйм. Соклангыч.
Якыннан — буяу гына...
Ерактан — кәшмир яулыклы
Бер карчык карап тора.

Бу яктагы көннәремнең
Соңгысы җитеп бара.
Кемдер дәшә кебек миңа:
Еракка китеп кара, син,
Еракка китеп кара!

...Үз халкыңның киләчәген,
Үткәнен, бүгенгесен,
Кайгысының, шатлыгының
Зурлыгын белер өчен,
Еракка китеп кара, син,
Еракка китеп кара!

...Абый мактармы дигәндәй
Балалар көтеп бара,
Күңелдә һаман шул сүзләр:
Еракка китеп кара, син,
Еракка китеп кара!

◇ II ◇

Альберт Хәсәнов

# ЙОЛДЫЗЛАР СҮНӘР ӨЧЕН КАБЫНМЫЙ

ОЧЕРК

## Ял итеп кайт бер, булмаса...



Ул елны җәй сорап алгандай матур булды. Вакытында кояш көлде, иң кирәк чагында гына яңгыры да ялындырмады. Бу җәйне сабан ашлыкларны урып-җыю башка елларга караганда күп алдан тәгәлләнде. Инде чират тары белән кара бодайга җитеп, аларны да ике-өч көндә иңләп чыкканнан соң, беркөн шулай кичләтеп кенә Дәһине колхоз идарәсенә чакырдылар.

— Инде, Дәһи, тәнеңне ремонтлап кайт,— диде ул.— Яңгыр явасы булса, бил сызларга тотына, дип зарлана идең.


Председатель аңа бушлай путевка тоттырды. Путевканы район комбайнчылары арасында ярышта беренчелекне алган өчен җибәргәннәр иде. Инде ничәнче ел рәттән ул беренче. Иртәгә юлга чыгасы дигән кичне председатель Ядкәр Шәфиков Дәһине тагын чакыртты.

— Андый җиргә буш кул белән барып булмый. Анда баргач, кулыңны кушырып аптырап йөрмә. Менә моңа бала-чагаңа күчтәнәч алырсың, арт кесәңә салып куй. Анда кадәр баргач, яхшылап ял итеп кайт,— дип, илле тәңкә акча да сузды.— Безнең ишегә мондый нәрсә гел эләгеп тормый, яхшылап ял ит.

Шулай итеп Дәһи, уртасыннан бил каешы белән бәйләгән чемоданын күтәреп, гомер аяк басмаган җирләргә — Кырым якларына китеп барды. Бирегә әле җәйнең нәкъ уртасы иде, кояш күләгәдә дә утыз белән кыздыра. «Бәрхет сезонының» башланган гына чагы. Көннәр матур, базар тулы җиләк-җимеш. Кемнәр генә юк бу якта, нинди телдә генә сөйләшмиләр.

Күкрәгендәге Алтын Йолдызны күреп, Дәһигә аеруча игътибар күрсәттеләр. Аның бер үзенә аерым бүлмә бирделәр. Шунда ук ваннасы, шунда ук душы. Тәрәзә төбендә хуш исле гөлләр.

Әллә юлдан арып килгәнгә, беренче көннәр сизелми дә үткән кебек булды. Ә менә аннан соңгылары берсеннән-берсе озын тоела башладылар. Эш кешесе эшсез торырга күнекмәгәнмени, курортка ял итәргә килдем дип кенә башны йокыга, күңелне ваемсызлыкка салып булмый икән. Дәһи, бирегә китәр алдыннан, үз комбайнын ярдәмчесе Хуҗа Камалетдиновка калдырган иде. Хуҗа булдыклы, кулында ут уйната торган егет. Әйбернең дә кадерен белә. Ләкин шулай да комбайнны эштән туктаткач, Хуҗа аскуймаларга куйды микән инде, көпчәкләрне акка буярга онытмады микән, каешлар-



ны салдырып куярга башына килде микән, дип баш ватты ул. Суыкта, яңгыр астында калган булсалар, череп, күгәреп, ярылгалап бетәчәкләр бит.

Инде малларны җәйге лагерьлардан фермаларга кайтарыр вакыт җиткәндәр. Сыер абзарларына быел гына су үткәргечләр сузганнар иде. Уракка төшкәнче, җәйге чорда Дәһи да шунда су үткәрешеп йөргән иде бит. Су-мазар килмәсә, автоэчергечләр эшләмәсә, ул да гаепле булачак... Шундый уйлар йөрәкне кимергәндә ял кайгысымыни башта?! Ахырда ул түзмәде, путевка срогы бетәргә уникә көн калган булса да, кайтып китәргә җыена башлады.

— Радикулитыгызны бераз дәвалярга иде, кая ул кадәр ашыгасыз,— дип, курорт врачы аны тоткарларга тырышып карады. Кая ул, буламы соң? Штурвалга менә алмыйча дүрт аяклап комбайн тирәсендә йөргән чаклары онытылган. Врач сүзенә каршы аның җавабы да әзер.

— Әлегә кәеф ничава, инде сызлап аптырата башласа, хатын җәен белә аның, кыздырган кирпеч кенә бастыра,— диган булды.

Дәһи, һич көтмәгәндә, авылга кайтып керде. Анда да әле өенә ашыкмады. Башта фермага сугылды, мастерскойга кереп чыкты. Барысын белешкәч, барысын үз күзе белән күргәч кенә тәмам тынычланып, өенә таба атлады.

## «Канбаем бу, улым, канбаем»

...Бәләкәй, арба кендеге чаклы гына иде әле Дәһи ул чакта. Дусты Гыйльми Сәхапов белән себерке сабына атланып пыр тузып, тузанга батып, кызыллар белән аклар булып уйнауларын кинәт кенә ташладылар да басу капкасына таба йөгерделәр. Басу капкасы төбенә җыйналган халыкның исәбе-хисабы юк иде. Дәһинең атасы Гарифулла абзый да монда. Басу капкасының тышкы ягында әвен хәтле машина таккан трактор туктаган. Бирегә җыйналган халык бу сәер машинага төртеп күрсәтә-күрсәтә, нидер сөйлиләр, бәхәсләшәләр, ара-тирә шаркылдашып көлешеп тә алалар. Моңа чаклы берәр чүмәлә печән төягән олаулар да бик иркен кереп-чыгып йөргән басу капкасына машина сыймый. Трактор да шуңа туктап калган икән. Бернича агай, учларына төкергәли-төкергәли, капка баганасы төбен казып маташалар. Әлеге ят машина өстендә утыручы яңа кара кәләпүшен кыңгыр салган мыеклы абзый шуннан, утырган җиреннән генә, багана казучыларга куллары белән ишарәләп нидер аңлата.

Бу килбәтсез машинадан бераз шүрли төшеп, Дәһи әтисенә сырышты.

— Канбаем бу, улым, канбаем,— диде Гарифулла абзый, машинага күрсәтеп.— Үзе ура, үзе суга, үзе җилгәрә, дип сөйлиләр, дөрес булса. Курыкма, улым, син аннан. Яхшы машина булырга тиеш бу.

Ул арада басу капкасын киңәйтеп тә өлгерттеләр. Трактор, борыннары кытыклый торган әчкелтем төтеннәр чыгарып, бер кечәнеп алды да хәрәкәткә килде. Үзе артыннан әлеге «канбаем»ны ияртеп авыл эченә керде.

Гарифулла абзый канбаем өстендә бик горур кыяфәттә утырган мыеклы абзыйга күрсәтеп:

— Күреп кал, улым. Зур үскәч, син дә шундый машиналар йөртерсең. Үземнән булмады инде, әмма сине укытам, кеше итәм, алла боерган булса,— диде.

Бу машинаны беренче күрүдә Дәһи бик үк килештереп бетермәсә дә, әтисе: «Улым, сине дә укытам, зур үскәч син дә шушындый машиналар йөртерсең»,— дигәч, канбаем белән якыннанрак танышу, аның ямьсез ыржаеп торган тешләрен үз кулы белән тотып карау нияте белән трактор артыннан иярде.

Канбаемны колхоз идарәсе каршында туктаттылар. Ләкин Дәһинең планы барып чыкмады. Түбән очның бик усал бер картын машина янына каравылга куйдылар. Баштарак аны санга сукмыйча, канбаемның кайбер җирләрен тарткалап-суккалап, боргалап карарга маташкан берничә малайның арт якларына бабай үзенең артыш таягы белән сыпыргалагач, башкаларга да сабак булды. Малайлар өйләренә таралыштылар. Дәһи тиз генә тынычлана алмады. Печәнлеккә йокларга менеп яткач та кабатлап ятты:

— Канбаем, канбаем. Әти шуны йөртергә укытам, диде...

Туфрагы җиңел булсын, әмма мәрхүм Гарифулла абзыйга малаен «үзе ура, үзе суга, үзе җилгәрә» торган машина өстендә күрү насыйп булмады. Ул колхоз амбарларын саклаган җирендә дөнья куйды.

## Канбаем түгел, комбайн икән

Тиздән Дәһи мәктәпкә йөри башлады. «Комбайн» түгел, «канбаем» дип, эти дә шулай дия торган иде, дип, укытучысы белән никадәр генә бәхәсләшмәсен, килешми булдыра алмады. Барлык китапларда да укытучы апалары әйткәнчә язалар. Ләкин моңа карап кына Дәһинең комбайнчы булу, аның күңеленә тирән сеңеп калган мыеклы абзый төсле, түбәтәйне кыңгыр салып, икмәк басуларын иңләү дәрте арта гына барды. Менә мәктәпне тәмамлар да, механизаторлар курсына китәр. Ә аннан инде авылга тик комбайнга гына утырып кайтыр төсле хыялланa иде.

Ләкин көтмәгәндә генә дөньялар чуалып китте. Зәй-Каратайның кулына корал тотардай егетләре, ирләре фронтка китеп беттеләр. Дәһи дә, кыш уртасында укуын ташлап, әнисенә булышка сарык фермасына китте. Ә язын үнеч тә тулмаган малай ат җигеп сукага чыкты. Сөйләп тә торасы юк, авыр заманнар иде ул вакытлар. Сөякләре тиреләрен ертып чыгарлык булып бүлтәеп торган арык атлар сабанны көчкә генә өстериләр. Дилбегә буе гына җир баралар да туктыйлар, баралар да туктыйлар.

Дәһи яңадан парта арасына кайта алмады. Фронтка киткән агаларын, абзыйларын алмаштырып, язын чәчте, көзен лабогрейка белән урдырды. Кышын да ферма тирәсендә эш муеннан. Ул арада үзенең дә армия сафларына китәр вакытлары җитте. Механизатор булу бәхетенә ул менә армиядән хезмәт срогын тутырып кайткач кына ирешә.

## Егет теләгенә ирешә

егетләрчә
1952 елны Дәһи, әлегә кара мыеклы абзый төсле, авылга кепкасын
кыңгыр салып, комбайн штурвалына утырып кайтып керде.
Ул елларда комбайнчының хезмәт күрсәткечен суктырган икмәгенә карап түгел,
ә урдырган гектарлар санына карап билгеләү тәртибе бар иде. Башакта бөртек калуда
комбайнчының эше юк. Аңа тик гектарлар саны гына булсын. Уракка төшүнең беренче көнендә Дәһи дә барабанны полный ход ачып сипте. Табигый. Бераүнең дә арт-
та сөйрәлеп йөрисе килми инде. Кичен тикшереп караса, башактагы орлыкның яртысы
да суктырылмаган. Шунда ничектер бик уңайсыз булып китте. Берәрсе шушы хәлне
күреп тормыйммы дип, хәтта як-ягына да каранып куйды.
Бу көннән соң инде унбиш ел узды, ләкин Дәһи инде бүтән яңадан суктырырлык
итеп урдырмады. Сыйфат комиссиясе ул урып киткән участокларның һәркайсын тик
«яхшы» бәясе белән билгели килә. Урак өсте күп булса унбиш-егерме көнгә сузыла.
Менә шушы чорда синең агрегатың сәгать механизмы төсле төзек эшләргә тиеш. Җир
өстенә чыгып бер сәгать ватылып тору — ел буе тик ятуга тигез. Шул унбиш-егерме көн

эчендә татлы йокыны да, үз вакытында тамак туйдыруны да онытып торырга туры килә. Бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы һаман комбайн өстендә. Агрегатны төнлә дә тик тотмыйлар. Төнен уруның үз уңайлыклары да бар бит анык: мотор кызмый, комбайнчы үзе эсседән, тынчудан аптырамый. Ләкин «Уңыш» колхозы комбайнчылары бу мөмкинлектән мәхрүм. Аның басуларына төнлә комбайн белән кереп булмый. Җир өстендә — атлаган саен скважиналар, электр баганалары, промысел объектлары. Һәркайда тимер-томыр, трос кисәкләре аунап ята. Караңгыда баганага шуларны эләктереп, бөтен агрегатны эштән чыгарып куюың да бар. Төнлә түгел, әле көндезен дә бик сак эш итәргә туры килә. Шундый чокырлы-чакырлы басудан, электр баганалары, скважиналар арасыннан борыла-сарыла йөрергә туры килсә дә, Зәй-Каратай комбайнчылары биш мең центнердан ким урдырмыйлар. Ә колхозның иң өлкән, Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы комбайнчысы Галиулла абзый Хәйруллин, башта Дәһидә ярдәмче булып эшләгән, ә хәзер үзләре штурвалда утыручы Хуҗа Камалетдинов, Марс Бәдретдиновлар геройның эзенә басып баралар. Һәр елны биш, алты мең центнердан артык икмәк суктыралар.

Альпинистлар, тауга йөрүчеләр арасында шундый тәртип бар: алар дүрт, биш, алты меңенчеләргә бүленәләр. Ягъни, кемнең нинди биеклеккә менәргә тазалыгы, чыдамлыгы, батырлыгы җитә. Биегрәк менгән саен, һава да сирәкләнә бара, аска, упкынга мәтәлү куркынычы да зуррак. Дөньяда иң биек кыя башларына менәргә дә батырчылык итүчеләрне «җиде меңенчеләр» дип йөртәләр. Болары инде — җиде мең метр биеклектән өстә булган «Победа», «Коммунизм», «В. И. Ленин» исемендәге пикларга менүчеләр, анда байрак кадаучылар. Шушындый тәртип соңгы вакытта комбайнчыларга да туры килә башлады. Алар арасында да дүрт, биш, алты меңенчеләр барлыкка килде. Ә Социалистик Хезмәт Герое Дәһи Шәрифуллин елның елында бер үзе җиде мең центнер икмәк җыйнап килә. Аның комбайнындагы җиде йолдыз да шуны раслый, шуны аңлата.

## Укымый булмый икән

Хезмәтенә күрә хөрмәте дигәндәй, комбайнчылар начар эшләми хәзер. Бар эшләгән, бар тапкан бер табынга кайта башлагач, ел әйләнәсенә байтак кына җыйнала. Өс-башка да җитә, өй җиһазларына да кала. Кыскасы, комбайнчының тормышы таза, өстәле мул. Дәһинең дә тормышы бик түгәрәкләнеп, очы-очына бик тигез, бик матур ялганып килә иде. Срогыннан алда да түгел, кирәгеннән дә соңармый, нәкъ үз вакыты белән, әле яшьли, малай чактан ук күзе төшеп йөргән, үзе белән мәктәптә сугышып үскән Фазыйлага өйләнеп җибәрде. Фазыйланың Дәһинең әнисе Фәрхисрур абыстайга шәфкатьле килен, иренә игелекле хатын булачы әллә каян беленеп тора иде. Беренче елны ук Фазыйла «су буеннан» Дәһинең нәкъ үз төсле сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле, имән бүкәне кебек тап-таза малай алып кайтып бирде. Дөрес, безнең заманнарда аның өчен имана җире аласы юк югын. Ләкин семьяда малай туу шулай да зур шатлык бит инде ул.

Дәһи казык кагудан башласа да, тиз арада йорт өлгертте, имән баганалардан капка җиткерде. Алдагы көннәргә дә планнары зур иде әле егетнең. Киләсе көз уңышын җыйгач, өйне бераз зурайта төшәргә, тагын бер почмак өстәргә, чамасы җитә калса, ак мунча тәвәккәлләргә хисаплап тора иде. Ата-анасы тигез, агасы-энесе булган яшьтәшләре йорт-җир коруны Дәһидән алда тәгәлләделәр. Аларның күбесе кичләрен, култык асларына китап-дәфтәр кыстырып, мәктәп юлын таптарга керештеләр. Шунсыз ярамаганын аңлап, хәзер халык башын укуга салды бит. Мондый уй инде күптәннән Дәһинең күңелендә дә йөри иде. Ләкин бит торырга йортың, йокларга урының, ашарга өстәлең булмый торып, укып йөрү мөмкин түгел иде. Авыл халкы теленә бер эләксәң, әллә нинди мәзәкләр чыгарып бетерер. Әмма бер кат хуҗалыкны рәткә салгач, дәреслекләр булдырып мәктәпкә йөрергә дип кенә торганда, зур кайгы килде: хатыны Фазыйла дөнья куйды. Өч яшьлек баласы белән Дәһи тол утырып калды. Кая монда уку. Ишек алды гөлы мал, өйнең түбәсе ябылып бетмәгән. Яңабаштан тормыш корып җибәргәнче, тагын ике-өч ел авышты. Ләкин: «Укырга иде, һич югында сигезне бетерергә иде», дигән теләк аның күңел түрендә кала бирде. Матур, аяз

күзләрнең берсендә, шундый уйлар аны мәктәпкә китерде. Ул көзне кечке мәктәпкә йөрүчеләрне рус теленнән укытырга әле яңа гына институт бетереп килгән бер яшь кенә кызны билгеләгәннәр иде. Аны да гаепләп булмый, иң изге теләкләрдән чыгып эш иткән булгандыр. Үзендә укыячак колхозчы егетләрнең белем дәрәҗәсен билгеләү, соңыннан һәрберсе белән аерым-аерым эшләү өчен тырышкандыр. Әлеге яшь укытучы кыз аларга иң башлап диктант яздырды. Дәһи ихлас күңел белән бик тырышып, бик тырмашып язган булган иде. Хәтта янып-пешеп чыкты. Маңгаеннан бөртек-бөртек тирләр тамды. Бәп-бәләкәй, арыш саламыннан әллә ни юан булмаган ручка сабын тотуга караганда күбрәк тимер-томыр, авыр чүкечләр, ачкычлар белән эш итәргә күнеккән куллар, бармаклар тәмам арып, бүртеп чыкты. Әмма иртәгесен укытучы кыз:

— Дәһи Шәрифуллин кайсыгыз әле ул? — дип сорап куймасынмы.

Класстагылар барысы да аңа таба борылдылар. Дәһи урыныннан күтәрелде.

— Бу диктантта сез хата ясау буенча моңа чаклы булган бөтен рекордны уздыргансыз. Шушы кып-кыска текстта сиксән ике хата ясагансыз,— диде укытучы. Класс гөр килеп көлеп җибәрде. Уналты-унсигез яшьлек яшь җилкенчәкләргә көләргә генә булсын инде аларга. Дәһи кебек ир уртасы кеше ике-өч кенә. «Их, мин тиле баш, кырыкка җиткәндә нинди уку булсын, ди инде. Укып кая барасым, министр буласым бармы. Җыен малай-шалай арасында. Шушы хурлыкка кал инде менә. Герой башым белән, җитмәсә», дип уйлап алды ул.

Яшь укытучы үзенең нинди хата эшләгәнен аңларга да өлгермәде. «Сезнең башны катырып, үземне газаплап йөргән мин сакаллы сабыйны гафу итегез инде бер юлга, ялгышлык миндә булган икән, сеңелкәш», дип, Дәһи шартлатып ишекне ябып класстан чыгып китте. Шул китүдән Дәһи озак вакытлар мәктәпкә аяк басмады. Әлеге укытучының аның өенә килеп гафу үтенүе, тагын мәктәпкә чакыруы да файда итмәде.

Эш кешесен халык зурлый да, олылый да бит аны. Ә эшкә дигәндә Дәһи үзен кызгана да, чикли дә белми. Үзенә Социалистик Хезмәт Герое исеме биргән елны ул җиде мең центнер икмәк суктырган иде. Аннан соңгы елларны шуннан ким суктырганы юк. Герой исеме бирүнең икенче елында нәкъ урак өстендә шул әлеге дә баягы биле кузгалды. Барысы да шул радикулит галәмәтләре инде. Бер штурвалга менеп утырса ярый әле, билне телогрейка белән урагач, түзәргә була. Ә менә штурвалга менеп утыру, төшү галәмәтләре аның өчен чын гүр газапларына әверелә. Колхоз председателе Ядкәр Шәфиков, аптырагач, дәваланып карарга дип киңәш биреп тә караган иде.

— Районда без бит йөз илледән артык комбайнчы, иптәш Шәфиков, дип җавап бирде ул. Бик белеп торам, быел аларның һәркайсы: «Кая, быел безнең герой ничек ура икән», дип көнлек сводканы бик җентекләп карап баралар инде. Алардан «былтыр Герой исеме бирделәр, ә быел үзеннән чыш та чыкмады», дип әйттерә алмыйм инде. Хәлемне аңлагыз, үлсәм дә шушында үләм. Башка чарам юк. Һәм ул тагын штурвалга басты. Бу көзне дә иң күп икмәк суктыручы булып районда беренчелекне алды. Андый кешене халык ничек зурламасын да, ничек хөрмәт итмәсен. Башына кайгы төшсә дә, авылдашлары аңа баралар, зур шатлык килсә дә, аның белән уртаклашалар. Шулай булырга тиеш тә инде ул. Башкача мөмкин дә түгел: ул авыл Советы депутаты, Лениногорск шәһәр партия оешмасы пленумы члены. Мондый ихтирам, мондый хөрмәт аның үзенә дә зур бурычлар йөкли. Дөнья булгач, тормыш булгач, аңа механизмнар белән генә түгел, кешеләр белән дә эш итәргә туры килә. Авылдашларның кайсы акыллы киңәш, кайсы ярдәм сорап килә. Кайсын матур сүзләр белән үгетләргә, кайсын яхшы гына кыздырып чыгарырга да туры килгәли. Моның өчен үзенә тәпле белем дә бик кирәк шул. Ә ул Дәһидә чамалы. Бәлкем, тагын тибрәнеп, тырышып карарга дыр?

Беркөн шулай арып-талып эштән кайтса, күз яшьләрен коеп, өйдә күрше хатыны утыра. Янында ат кадәр малае да бар.

— Быел көз менә сигезгә укырга барырга тиеш иде. Укымыйм, җитте, ди, тискәре. Күңеленә кем коткы салгандыр, ике сүзнең берендә эшкә керәм, шахтага китәм, ди. кулында сигезне бетергәнлеккә язуы булса, бер хаер иде. Бу килеш аны кем эшкә алсын, аның белән кем сөйләшеп торсын,— дип тезеп китте күрше.— Инде, Дәһи, булмаса, син сөйләшеп кара, бәлкем синең сүзеңне колагына алыр.

Тузанга баткан өстен-башын да алыштырмыйча, Дәһи бу малайга байтак вакыт үгет-нәсихәт укып утырды. Бушка гына булган икән. Теге малай күзен дә йоммыйча әйтеп куймасынмы: — Дәһи абый, син үзең дә укып кеше шаккатырганың юк,— дип. Дөрес сүзгә җавап юк. Бик уңайсыз булды аңа. Борын асты да кипмәгән малай күзен дә йоммыйча сиңа шулай дип утырсын әле.

Икенче көнне үк, кибеткә төшеп, бер кочак китап һәм башка уку кирәк-яраклары җыеп менде. Ә кичен исә мәктәпкә атлады...

Бер читтә олы малае Сирень борынын тарта-тарта сызым сыза. Дүртенчедә укучы Нәфис мич арасына, чаршау артына кереп пышылдый-пышылдый шигырь ятлый. Икенче класс укучысы Нәфисә санау таякларын шалтыр-шолтыр китереп арифметикадан дәрес әзерли. Шунда ук барысына комачаулык итеп, берсен кычкыртып, икенчесен елатып, иң кечесе Атлас бутала, абыйсының ручкасын чәлдереп китә, апасының карандашын. Дәһи үзе дә дәрес хәзерләүчеләр арасында: тегесен тыя, монысын юата. Үзенең кулында да китап. Синус, косинус, тангенс, котангенс, дип кабатлап, баш ватып утыра. Башыңа төшкәч башмакчы буласың икән аны. Геометрия укытучысы бик кырыс кеше. Бала-чага атасы дип скидка ясамый, класстагы яшьләр белән тиң күреп, материалны бик җентекләп сорый. Белмәсәң — «ике»ле тотып балаларың янына ничек кайтасың да, алардан яхшы укуларын ничек таләп итәсең?

Шулай азаплана торгач, Дәһи сигезне генә түгел, унберне бетерде, барлык имтиханнарны да уңышлы тотып, өлгергәнлек аттестаты алды. Кырыктан узып барганда, егет тәмам «өлгереп» җитте...

## Йолдызлар сүнәр өчен кабынмый

Узган елны мин Дәһи агрегатында комбайнчы ярдәмчесе булып эшләдем. 14 август көнне, мәсәлән, без биш йөз егерме центнер илле килограмм икмәк суктырдык. Ашаган белми, тураган белә дигәндәй, бу кадәр икмәк күпме була соң? Анысын мин соңыннан исәпләп чыгардым. Балалар бакчасына көненә унике-унбиш килограммнар чамасы ипи кирәк. Бер елга, димәк, илле дүрт центнер чамасы китә. Дәһинең бер көн эчендә суктырган бодае гына да шушы балалар бакчасын ак күмәч белән ун елга якын тәэмин итеп торырга җитә икән!

Җиде мең центнер икмәк!

Күпме була соң ул, аны ничек күз алдына китерергә була? Бер караганда «җиде мең» гади һәм коры сан. Аны күзаллау өчен тагын бер матур гына чагыштыру китерик. Уртача утызар центнердан гына исәпләгәндә дә шушы икмәкне ташып бетерү өчен «ГАЗ-51» маркалы ике йөз утыз өч йөк машинасы кирәк, ике йөз утыз өч машина икмәк зур байлык инде ул. Шул машиналарны берсе артыннан берсен тезеп куйсаң бер очыннан икенчесе күренми.

14 897 нче номерлы Алтын Йолдыз һәм Ленин ордены аңа юкка гына бирелмәгән шул — Алтын Йолдыз геройны яңа җиңүләргә чакырып балкый.

Ә йолдызлар сүнәр өчен кабынмыйлар.

⁂ ● ⁂



# ТАТАРСТАННЫҢ ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

# «ЧУЛПАН» — БЕРЕНЧЕ СОВЕТ ГАЗЕТАСЫ

«Правда» газетасының 1918 елгы 17 август санында «Кем җиңәр?» исемле бер мәкалә басыла. Авторы — Ярославский, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм танылган галим. Үзенең әлеге мәкаләсендә ул революция нәтиҗәсендә ирешелгән казанышлар белән горурлана, Советлар Россиясендә яшәүче халыкларда яңа, социалистик эчтәлекле әдәбият, культура үсүен күреп куана. Һәм, шул хакта сөйли торган мисалларның берсе рәвешендә, «Чулпан» газетасын телгә ала. Бу көннәрдә «Чулпан»ның чыга башлавына нәкъ җиде ай тулып килә иде.

Мәгълүм булганча, «Чулпан»ның дөньяга килүе икенче бер әһәмиятле вакыйга белән тыгыз бәйләнгән. 1918 елның январь көннәре. Россиянең бөтен почмакларында каты көрәшләр, Совет властен урнаштыру һәм ныгыту өчен канлы бәрелешләр бара... Әнә шундый авыр көннәрдә, 1918 елның 5 январенда, Петроградның Таврида сараенда учредительное собрание ачыла. Ләкин ул озак эшли алмый. Яшь Совет хөкүмәтенең декретларын танудан баш тартканнан соң, учредилканың контрреволюцион асылы ачыктан-ачык фаш ителә. Большевиклар һәм башка сул депутатлар эшче халык ихтыяҗларын үтәргә теләмәгән бу собраниене ташлап чыгалар. Алар арасында күренекле татар революционерлары Мулланур Вахитов белән Галимҗан Ибраһимов һәм башкорт халкының күренекле җәмәгать эшлеклесе Шәриф Манатов та була.

Шул вакыйгалардан соң күп тә үтми, Милләтләр халык комиссариаты каршында эчке Россия мөселманнары эше буенча Комиссариат (Комиссариат по делам мусульман внутренней России) төзелә[1]. 1918 елның 17 январенда шул хакта В. И. Ленин имзасы белән махсус декрет чыга[2]. Комиссариатның председателе итеп татар халкының турылыклы улы Мулланур Вахитов, аның урынбасарлары итеп Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Манатов билгеләнә. Икенче көнне үк, 1918 елның 18 январенда, Петроградта Комиссариатның басма органы — «Чулпан» газетасы чыга башлый[3]. «Правда» «Чулпан»ны интернационализм рухы белән сугарылган социалистик газета, дип атый һәм анда күренекле татар язучысы Галимҗан Ибраһимов та эшләвечәген аерым билгеләп үтә[4].

Минем алда «Чулпан» газетасы саннары тегелгән подшивка. Төсе унган кәгазь, энҗедәй тезелеп киткән гарәп хәрефләре. Кайбер саннары ертылып-тетелеп беткән... Менә газетаның беренче саны. Алты биткә рус һәм татар телләрендә: «Большая ежедневная газета лево-социалистического направления», «Сәяси, иҗтимагый вә әдәби сул социалистлар газетасы» дигән сүзләр язылган. Шунда ук газетасының тоткан юлын, юнәлеш һәм максатларын аңлаткан баш мәкалә урнаштырылган. Әлеге мәкаләдән

---

[1] Ул соңрак Үзәк мөселман комиссариаты һәм Үзәк татар-башкорт комиссариаты дип тә йөртелә.

[2] Совет властеның декретлары. Рус телендә. Мәскәү. 1957 ел. 367 бит.

[3] 1918 елның март аенда, Совет хөкүмәте белән бергә, Үзәк мөселман комиссариаты Петербургтан Мәскәүгә күчә. 13 санынан башлап, «Чулпан» да Мәскәүдә басыла.

[4] «Правда» газетасы. 1918 ел. 23 январь

күренгәнчә, «Чулпан» мөселман халыклары арасындагы бөтен демократик көчләрне Совет властен ныгыту өчен көрәшкә тупларга тиешле газета була. «Чулпан» үзенә хәбәр җибәрүчеләрнең Совет платформасында торуларын шарт итеп куя һәм редакциянең тоткан юлын: «...Үз көче белән көн итүче халыкның иктисади коллыктан камил азат ителүе... мәркәздә дә, урыннарда да бөтен хакимиятнең эшче, солдат һәм авыл халкы шуралары кулында булу»ы өчен көрәшү дип билгели.

«Чулпан» ил тормышы белән яшәде. Аның һәр санында диярлек Совет власте өчен актуаль булган эчке һәм тышкы политика мәсьәләләренә киң урын бирелде. Ул һәр вакыйгага эшче, крестьян халкы интересларыннан чыгып сыйнфый бәя бирде, Совет хөкүмәтенең политикасын эзлекле яклап, аңлатып килде.

Баштарак Комиссариаттагы күп төрле эшләрне дә, «Чулпан»ны чыгаруны да югарыда исемнәре күрсәтелгән өч кеше алып бара. Газета редакциясендәге йөкнең иң авыр өлеше исә «Чулпан»ның беренче редакторы Галимҗан Ибраһимов өстенә төшә. Беркадәр вакыттан соң, Үзәк татар-башкорт комиссариаты кушуы буенча, Галимҗан Ибраһимов Псковка бара һәм биредәге мөселман солдатлары комитетын тулы составы белән (барлыгы 11 кеше) Петроградка кайтырга күндерә [1]. Комитет членнары арасында татар халкының күренекле революционерлары Иосыф Ибраһимов, Һади Кильдебяков, Минһаҗ Коновлар да була. Алар килгәч, редакциядәге эшләрне җиңеләйтергә һәм киңәйтергә мөмкинлек туа. Газетаның авторлар коллективы да торган саен тулылана, күбәя бара.

«Чулпан» битләрендә ул вакыттагы күренекле татар һәм башкорт революционерлары актив катнашып киләләр. Анда без Дулат-Али, Салах Атнагулов, Мостафа Сөбхи, Фатих Сәйфи-Казанлы, Һади Кильдебяков, Шәриф Манатов кебек революционерларны һәм журналистларны күрәбез. Газетада Үзәк татар-башкорт комиссариатының председателе Мулланур Вахитовның күп кенә мөрәҗәгатьләре һәм башка материаллары урнаштырыла. «Чулпан»ның һәр санында диярлек газетаның редакторы Галимҗан Ибраһимовның тирән эчтәлекле мәкаләләрен очратырга була. Имзасыз яки псевдоним астында чыккан материалларның да күбесе Галимҗан Ибраһимов яки Мулланур Вахитов тарафыннан язылган булырга тиеш.

Эшче һәм ярлы крестьян халкы интересларын актив яклаучы булганга, «Чулпан» тиз арада зур популярлык казана. Газетаны күбрәк җибәрүләрен сорап, «Чулпан» редакциясенә, Үзәк татар-башкорт комиссариатына һәм башка үзәк органнарга күп кенә хатлар килә. Архивларда хәрби оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләрне бигрәк тә еш очратасың. Мәсәлән, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты нәшриятының хәрби бүлеге 1918 елның 12 ноябреннан үз карамагына җибәрелә торган «Чулпан» газетасын 5.000 данәдән 10.000 данәгә җиткерүен сорый. Газета хәрәкәттәге армиягә җибәрелергә тиеш була [2].

«Чулпан»да басылган мәкаләләрне халык арасында агитация-пропаганда эше алып баручы партия һәм совет хезмәткәрләре дә көтеп алалар. Бу турыда 1918 елда Казан губерна мөселман комиссариатында эшләгән, хәзер персональ пенсионер Латыйф Гомәр кызыклы гына бер эпизод сөйли [3].

«Чулпан»да басылган материаллар, ул материалларның эчтәлеге һәм характеры турында күп һәм озак сөйләргә булыр иде. Без исә газета эшчәнлегендәге кайбер моментларга һәм безнең карашка аеруча әһәмиятле күренгән аерым мәсьәләләргә генә тукталырга уйлыйбыз.

1918 ел шартларында контрреволюцион учредительное собраниенең чын йөзен фаш итү бик кирәкле һәм мөһим мәсьәлә санала иде. «Чулпан» газетасы бу юнәлештә зур эш башкарды. «Учредительное собрание куылды һәм куылырга тиеш иде. Чөнки ул халыкка иң кирәк булган декретларны кабул итмәде»,— дип язды Г. Ибраһимов үзенең «Сайлаучыларга хисап урынында» исемле мәкаләсендә.

Совет дәүләтенең башка типтагы барлык идарәләрдән чагыштыргысыз өстен бу-

---

[1] Г. Ибраһимов. Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы. Казан. 1922 ел. 144 бит.

[2] Р. Нафигов. Мулланур Вахитов. Таткнигоиздат. Казан. 1960. 130 бит. (Рус телендә.)

[3] Л. Гомәр. Әдип һәм көрәшче. Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр. Татарстан китап нәшрияты. 1966 ел. 185—187 битләр.

луы һәм аның гына хезмәт халкына ирек, яшәргә мөмкинлек тудыруы турында «Чулпан» шулай ук үзенең беренче саннарында ук аңлата башлады. «Шуралар хөкүмәте ни дигән сүз?» һәм башка күп кенә мәкаләләр Совет властеның асылын, аның хезмәт ияләренең үз власте икәнен аңлату өчен язылганнар иде. Совет хөкүмәтенең беренче декретларын татар теленә тәрҗемә итү һәм аны газета битләрендә бастырып чыгаруны «Чулпан» үзенең әһәмиятле бурычы санады. Катлаулы политик мәсьәләләрдә үзенең юнәлешен билгеләүдә «Чулпан»га партия һәм Совет властеның үзәк органнары «Правда» һәм «Известия» газеталары зур ярдәм күрсәттеләр. «Чулпан» редакциясе, бу газеталардагы хәбәрләрне тәрҗемә итеп барды, аларны татар һәм башка төрки халыкларга җиткерә килде[1].

«Чулпан» большевиклар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең милли политикасын, бигрәк тә аның тынычлык һәм халыклар дуслыгы иле булуын һәрвакыт яктыртып күрсәтеп барды. «Империализм, халык революциясе һәм милләтләр хокукы» исемле имзасыз мәкаләдә ачыктан-ачык болай диелә: «Социал-демократ большевиклар милләтләрнең аерым үзләре теләгәнчә торуларына бервакытта да каршы килмәделәр, килмәячәкләр. Бу эш аларга тугры да килми... Милләт ягыннан кешене кысуны, кешене шул яктан берсен югары, берсен түбән куюны алар бервакытта да ихтыяр итәчәк түгелләр»[2]. Чөнки, диелә анда, әгәр дә бер милләт икенче милләттән өстен куелса, ул вакытта эшчеләр арасында дошманлык туачак һәм бу — эшче сыйныфы файдасына каршы бару булачак.

«Милләт ягыннан кысылудан куркырга Керенский... заманында урын бар иде. Октябрь революциясеннән соң инде милләт ягыннан курку бик гаҗәп эш!» — ди «Чулпан», буржуаз газеталар йогынтысында икеләнүчеләргә, шикләнүчеләргә мөрәҗәгать итеп. Газета барлык милләт эшчеләрен һәм крестьяннарын буржуазиягә каршы көрәшергә чакыра, халыклар арасындагы дуслыкның һәр милләткә дә бик кирәк булуын күрсәтә: «Без, төрле милләттәге ярлылар яклы кешеләр, бер беребезне аңлаша алмасак, Россия эчендәге капиталистлар, шуннардан оста файда итеп, төрле милләт вә төрле милләтнең байлары бергәләшеп, тагын безне кол итәрләр»[3].

Шулай итеп, «Чулпан» илебездә Совет властеның җиңеп чыгуы өчен пролетар интернационализм принципларын тормышка ашыруның ни кадәрле әһәмиятле булуын тирән төшенде, бөтен дөнья хезмәт ияләренең көрәшенә теләктәшлеген белдерә килде һәм аларны социализм идеяләре өчен көрәшкә туплашты.

«Милләт һәм сыйнфый көрәш» исемле теоретик планда язылган редакцион мәкаләдә дә милли мәсьәлә һәм сыйнфый көрәш турында дөрес марксистик караш алга сөрелә. Октябрь социалистик революциясеннән соң «...һәрбер милләтнең диярлек буржуазиясе, милләт пәрдәсе астына качып, эшче вә авыл халкына каршы көрәш башлады»,— дип яза газета. «Чулпан» татар буржуазиясенең дә, шушы ук методны кулланып, үз хакимлеген саклап калырга омтылуын һәм аның милләт турында бөтенләй кайгыртмавын фаш итә. Бу көннәрдә халыкларны милләт буенча түгел, ә бәлки сыйнфый яктан карап аерырга кирәклеген, илдә барган көрәшкә нәкъ менә шул күзлектән чыгып карарга кирәклеген «Чулпан» аеруча басым ясап аңлата.

«Чулпан», ил тормышыннан алынган конкрет мисалларда, татар буржуазиясен һәм аның «Ил», «Корылтай», «Алтай» кебек рупорларын ачы фаш итте, аларга каршы каты идеологик көрәш алып барды. Бу көрәштә Советлар хөкүмәтенең, Коммунистлар партиясенең милли программаны тормышка ашыру юлындагы практик эшләрен яктырту, аеруча автономия мәсьәләләрен аңлату зур әһәмияткә ия иделәр. Бүген, республикабыз хезмәт ияләре Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасының 50 еллыгын каршыларга хәзерләнгән көннәрдә, Совет властеның беренче елларында милли автономия төзү өчен барган көрәш тарихының беренче адымнарын искә алу урынлы булыр дип уйлыйбыз.

Милли автономия төзү мәсьәләсе элекке изелгән халыкларның барлык катлаула-

---

[1] Бу турыда ул вакытта «Чулпан» редакциясендә әдәби сотрудник, тәрҗемәче булып эшләгән, соңыннан күренекле язучы һәм тәрҗемәче булып киткән Мәхмүд ага Максуд та хәтергә ала (Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр. Татарстан китап нәшрияты. 1966. 141 бит).

[2] «Чулпан» газетасы. 1918 ел. 23 февраль.

[3] Шунда ук.

рында диярлек зур кызыксыну уятты. Бу — аңлашыла торган нәрсә, билгеле. Партиябез һәм яшь Совет хөкүмәте дә бу мәсьәләгә җитди игътибар бирделәр.

Совет автономиясе төзү эше илебезнең барлык почмакларында диярлек милли буржуазия белән каты көрәш шартларында барды. Татар буржуазиясе шулай ук үзенчә автономия өчен көрәште һәм бу көрәш Октябрь революциясе көннәрендә аеруча кискен төс алды. 1917 елның 20 ноябреннан 1918 елның 11 гыйнварына кадәр Уфада эчке Россия һәм Себер мөселманнарының «Милли мәҗлесе» җыелды.

Күпчелеге буржуазия вәкилләреннән торган «Милли мәҗлес» Идел һәм Урал буендагы территориядә автономияле штат төзү турында карар кабул итте. Һәм шул карарны тормышка ашыру өчен аерым коллегия дә төзеде. Билгеле, «Милли мәҗлес» буржуаз автономия төзү турында уйлый һәм Совет хөкүмәте игълан иткән үзбилгеләнү принципларын үз файдасына әйләндермәкче була иде. Совет һәм мөселман революцион оешмалары бу милли автономиядә хөкүмәт башында эшче һәм крестьян вәкилләре торырга тиеш диделәр һәм шул максатка ирешү өчен кискен көрәш башлап җибәрделәр. Бу көрәштә Үзәк татар-башкорт комиссариаты һәм «Чулпан» редакциясе актив катнаштылар һәм хезмәт ияләре арасында аңлату эше алып бардылар. «Чулпан»да бу мәсьәлә буенча күп кенә мәкаләләр урнаштырылды. Галимҗан Ибраһимов тарафыннан язылган «Федерация, туфраклы мөхтәрият һәм шуралар хакимияте», «Идел-Урал җөмһүриятендә хакимият мәсьәләсе», «Туфраклы мөхтәрият хакында» исемле һәм башка күп кенә мәкаләләрдә бу мәсьәләләргә принципиаль бәя бирелә, татар буржуазиясенең планнары фаш ителә. Милли автономиядәге хакимиятнең кем кулында булу мәсьәләсе «...безнең өчен зур, гадәттән тыш зур, яшәмәк яки үлмәк дияр дәрәҗәдә зур бер мәсьәлә...» дип язды Галимҗан Ибраһимов.

Башка кайбер урыннардагы кебек үк, «безнең булачак җөмһүриятебездә дә үз буржуазиябезне җимереп, изеп читкә ыргыту өчен, үз өлкәбездә хакимиятне эшче, солдат вә ярлы авыл халкы кулына бирү өчен» кан түгәргә кирәк ихтималы барлыгын газета алдан ук кисәтеп куйды. 1918 ел башында контрреволюцион татар буржуазиясе тарафыннан «Болак арты республикасы» төзергә маташу бу кисәтүнең бик урынлы булуын тагын бер кат раслады.

Шушы катлаулы көннәрдә «Правда» газетасы Совет хөкүмәтенең (Үзәк татар-башкорт комиссариаты катнашында эшләнгән) «Татар-Башкорт Совет республикасы» төзү турындагы декретын бастырып чыгара. Башка дәүләт эшлеклеләре белән бергә, Мулланур Вахитов, Шәриф Манатов һәм Галимҗан Ибраһимовлар кул куйган бу документ рус һәм татар телләрендә «Чулпан» газетасында да басыла. Буржуазия тарафыннан алданган яисә икеләнүче гади халык массаларын Совет власте тирәсенә туплауда бу документның зур әһәмияте булды. Ул «Болак арты республикасын» тизрәк таратырга ярдәм итте. Соңрак танылган татар большевигы Камил Якубов бу декретны татар буржуазиясенең тамыры киселүе белән чагыштырды.

Билгеле булганча, Идел һәм Урал буенда гражданнар сугышы башланып китү сәбәпле, Татар-Башкорт Совет республикасы проектын тормышка ашыру эшләре тоткарланып тора. Соңыннан, татар һәм башкорт хезмәт ияләренең үз теләкләре буенча, һәр ике халык өчен аерым автономияле республикалар төзелә.

Кыска гына күзәтүдән дә урыннарда Совет властен урнаштыруда, татар, башкорт һәм башка төрки халыклары арасында социализм идеяләре таратуда «Чулпан» газетасының зур роль уйнавын күрергә мөмкин. Дөрес, хәзерге көн күзлегеннән чыгып караганда, газетаның кайбер мәкаләләрендә аерым җитешсезлекләр, баштарак сул эсерлар политикасына карата берникадәр иллюзияләр чаткысы күрергә мөмкин. Ләкин катлаулы бөек революция көннәре күзлегеннән караганда, ул моментлар тулысынча аңлашыла һәм газетаның, гомумән алганда, Коммунистлар партиясе платформасында торуын күрергә комачаулык итмиләр.

Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк, «Чулпан»да басылган мәкаләләр тарихи яктан бик әһәмиятлеләр. Кызганычка каршы, бу газета әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Аны төрле яктан өйрәнү, тикшерү бу катлаулы һәм даннлы елларда рус булмаган халыклар арасында Совет власте урнаштыру өчен барган каты көрәшне тулырак ачыкларга, һичшиксез, ярдәм итәчәк.

Р. ХӘЙРЕТДИНОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

М. Гайнуллин,
филология фәннәре докторы,
М. Һадиев.

# ШАГЫЙРЬ ҺӘМ РЕВОЛЮЦИОНЕР

Хезмәт ияләре Советының Бохара шәһәре Башкарма комитеты 1964 елның 17 ноябрендә, Галимҗан Акчурин исемен мәңгеләштерүне күздә тотып, шәһәр урамнарының берсенә аның исемен бирү турында карар чыгарды.

Кем соң ул Галимҗан Акчурин?



1917 елда, Октябрь социалистик революциясенең беренче елында ук, Коммунистлар партиясе сафына кергән Акчурин Бохараны азат итүдә генә түгел, гомумән Төркстанда Совет дәүләтен урнаштыру һәм ныгытуда гаять әһәмиятле эшләр башкарган кеше ул. Урта Азиядә басмачыларга каршы көрәштә күрсәткән сәләте, батырлыклары өчен аны Бохара Совет республикасы беренче һәм икенче дәрәҗә Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкли. Галимҗан Акчуринның тормыш юлы гыйбрәтле. Аның, партиябезнең турылыклы улы буларак, хезмәт ияләре бәхете өчен көрәшкә керткән өлеше гаять зур.

Озын буйлы, матур сынлы, мөлаем, йомшак табигатьле, ягымлы сүзле, яшьтән үк шагыйрь булырга, туган халкына каләме белән армый-талмый хезмәт итәргә хыялланган кеше була ул.

Галимҗан Акчурин 1895 елда элекке Пенза губернасы Рахманка авылында туа. Башта Кышкар мәдрәсәсендә, 1910 елдан Казанда укый. Казанда булган чорларында Хөсәен Ямашев, Гафур Коләхметов, Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирханнар белән аралаша. Революционерлар һәм алдынгы язучылар белән бәйләнешкә керү шәкерт Акчуринның иҗтимагый-политик аңы формалашуга зур ярдәм итә. Һәм озакламый ул үзе дә хезмәт ияләре бәхете өчен көрәш сафына баса. Башта ул үзе укыган «Касыймия» мәдрәсәсендә шәкертләрне оештырып, андагы уку планнарына дөньяви фәннәрне кертү кирәклеге таләбен куюдан гына башлый. Мәдрәсә идарәсе шул таләпне кабул итмәгәч, бер төркем иптәшләре белән, мәдрәсәне ташлап чыга һәм,

аерым квартирада торып, русча укый башлый. Тукай белән танышу, аның әсәрләрен яратып уку Акчуринның үзендә дә калəм тибрәтү теләге уята. Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Татар шагыйрьләре антологиясе»нә никтер кертелмәгән бу шагыйрьнең үз вакыты өчен актуаль, көннәрдә нечкә хисләр уятырдай матур шигырьләре, нәсерләре шактый. Г. Акчуринның 1913—15 елларда «Шура», «Ак юл» һәм «Сөембикә» журналларында басылган әсәрләре шул турыда сөйли. Дөрес, аның империализм сугышының дәһшәтле елларында язылган кайбер шигырьләреннән шул чакларның борчылулы хисләре аңкый, төшенкелек рухы сизелә. Бу яктан аның 1914 елда «Сөембикә» журналында чыккан «Көннәрем вә төннәрем» дип исемләнгән шигыре бик характерлы. Бу чорда Мәҗит Гафури иҗатында күренгәнчә, Акчурин шигырендә дә гаделсезлеккә нәфрәт, шул гаделсезлекләргә чик куя алмаган «аллага» үпкә, рәнҗү чагыла:

Юк рәхәт һич кайда,
Ачудан йөрәк селкенә.
Сагыштан тулган күңел
Җанга азык эзләп —
Гаршегә очарга җилкенә.

Туйдым, бөтен бардан үлем артык,
Чәнчелеп китсен бөтен дөньясы,
Күзен атмый алласы да,
Мин көн дим, ул һаман төн ясый.

Шуның белән бергә шагыйрь үз чорының гаделсез, караңгы тормышы тудырган авыр уй-хисләрне җиңәргә дә омтыла. Моңа мисал итеп 1915 елда «Сөембикә» журналында басылган «Ике моң» һәм «Минем күңелем» дип аталган шигырьләрен күрсәтергә була. Соңгы әсәрендә ул саф күңелдәге якты уйларны, киләчәккә булган өмет чаткыларын күрсәтеп:

«Тугъры әле мина, ап-ак әле
Якты әле хәят юллары»,—

дип яза.

Галимҗан Акчурин 1914 елгы герман сугышы башлангач, патша хакимлеген, хуҗалар һәм алпавытлар интересларын корал белән саклаудан баш тартып, Урта Азиягә китә. Ташкент — Красноводск тимер юлындагы Кызыл Түпә станциясе янкынына урнашкан мамык чистарту заводына эшкә керә. Ул анда да шигырьләр язуын дәвам иттерә, эшчеләр арасында актив аңлату эшләре алып бара.

Галимҗан Акчуринның хатыны Камилә ханым Бурнаева кулында сакланган материаллар арасында аның орденнары һәм күп кенә шигырь кульъязмалары бар. Шулардан берсе — зур күләмле (2800 юллы) поэмасы «Җен падишасы кызы» дип атала. Романтик мәхәббәт поэмалары жанрында язылган бу әсәрнең ахырында: «Язылa башланды 15 нче май, 1915 нче ел, язылып бетте 14 июль, 1918 нче ел. Галимҗан Акчурин», дип куелган һәм тагын «Язылa башланды Казанда. Язылып бетте Бохарада», дип тә өстәлгән.

Икенче бер кульъязмасында шагыйрьнең лирик парчалары тупланган. «Бер матурга», «...гә», «Кем ул» дип аталган шигырьләрен ул 1915 елда Яңа Бохарада язган һәм аларда Акчуринның шактый оста шагыйрь булуы күренеп тора. Менә аның шул «Кем ул» дип аталган шигыреннән бер өзек:

«Сөйләгән сүзне —,сайлап сөйли,
Сөелгәнен миннән ул белә,
Ни ятканын минем йөрәгемдә
Тик ул гына белеп —
Ул күрә.
Көлеп куйса янлыш
Гүя шунда,
Оҗмах ишекләре ачыла,

Оҗмахтагы хурлар ишегеннән
— Тирә-якка нурлар чәчелә.
Ике бите чокыр,
Чем-кара күз,
Керфек очларыннан нур чәчә.
Нур чәчми лә, янлыш зәһәр катыш
Минем йөрәгемә ут чәчә.

Галимҗан Акчурин Пушкин һәм Лермонтов шигырьләрен тәрҗемә итү буенча да шактый күп эшләгән. Аның кульъязмалары арасында кечерәк күләмле шигырьләр рәтеннән Лермонтовның «Хаджи Абрек» исемле зур әсәренең тәрҗемәсе сакланган. Бу материаллар Акчуринның сәләтле тәрҗемәче булуын бик ачык күрсәтәләр. Ул гомуман рус классик поэзиясенә тирән хөрмәт белән карый. «Михаил Юрьевич Лермонтов хәзрәтләренең рәсеменә карап» дип аталган шигырендә аны түбәндәгечә олылый:

«И, Михаил хәзрәте! Урның синең иң, иң гали,
Бел, алалмый ул урынны «изге җан», Гайса җаны.
Калдырып киткән эзең нур вә төрле шан берлән тулы.
Мәгънәдән зур бостанында дөнья нур берлән сулый.
Юк үзең, калдың җиһанда инде тик бу рәсмилә,
Иң гали хис берлә янганда карыйм шул рәсеменә».

*(1917 ел, декабрь 27, Кызыл Түпә)*

Революция елларында Акчуринның заман темасына язган шигырьләре һәм мәкаләләре бар. Аларның бер өлеше «Азад Бохара» газетасында басылган. Шулардан «Эшче халык сүзе» һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин. Ләкин аңа бу җаваплы чорда бөтен көчен, талантын революцион көрәшкә салырга кирәк була.

Акчурин февраль революциясен Кызыл Түпә мамык чистарту заводында каршы ала. Завод эшчеләре арасында политик аңлату эшләрен киң җәелдереп җибәрә. Бу чакларда ул еш кына Яңа Бохара (Каган) шәһәренә барып йөри. Анда Төркстанда яшерен большевиклар оешмасы җитәкчеләренең берсе булган П. Полторацкий[1] белән очраша. Полторацкий, мөселманнардан шундый ышанычлы кеше табылуга куанып, аны партия эшенә якынайта һәм шул ук елда Г. Акчурин рәсми рәвештә коммунистлар партиясенә кабул ителә.

Бохара, Хива ханлыклары әле ул вакытта һаман элеккечә, феодал стройның көчле изүе астында хокуксыз коллар хәлендә яшиләр иде.

Еллар буенча шул мохит эчендә яшәп, изелгән, рәнҗетелгән хезмәт ияләренең аяныч хәлен күреп, фанатик дин әһелләренең йөгәнсез чиновникларның, байлар һәм алпавытларның кылган җәбер һәм кыерсытуларына шаһит булып, җаны әрнегән Галимҗан Акчурин җирле халыкларның алдынгы вәкилләрен Россия пролетариатының революцион көрәш тәҗрибәсе белән таныштыруга зур көч куя.

Завод эшчеләре өчен Г. Акчурин якын кеше булып әверелә, бертавыштан аны завком председателе итеп сайлыйлар. Завком председателе һәм партия члены буларак, Акчурин эшчеләр интересы өчен зур көрәш алып бара. Ул чакларда әле урыннарыннан алынмаган завод хуҗалары «бу тынгысыз» кешедән котылу өчен, аны солдатка озаттыралар. Акчурин анда да революцион эш алып бара, соңрак, кулына корал алып, революция дошманнарына каршы көрәш сафына баса.

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәч, Урта Азиядә мамык чистарту һәм май эшкәртү заводлары да национализацияләнә. Акчурин үзе эшләгән «Кызыл Түпә» заводын завком председателе сыйфатында кабул итеп ала. Ләкин озак та үтми, шул тирәләрдәге кара көчләр дә баш күтәрәләр, руханилар коткысына ияреп, дин исеменнән фанатик сугыш башлаган толпа заводны яндыра. Акчурин алдынгы эшчеләрдән Кызыл Гвардия отрядлары оештыра.

Бу көннәрдә Бохара шәһәреннән көн саен күңелсез хәбәрләр килеп тора. Бохара әмиренең, бик нык коралланып, Каган, Чарджоу, Катта-Курган шәһәрләренә һөҗүм башларга, бу шәһәрләрдәге большевикларны, революционерларны юк итәргә әзерләнүе мәгълүм була.

Озак та үтми, Бохара әмире, бөтен ханлыгына фәрман таратып, большевикларга, русларга, татарларга һәм яшь бохаралыларга каршы газават — «изге сугыш» игълан итә. Фетнә киң колач ала, Кызыл Түпә тирәсендәге фетнәчеләр, «денен каферләргә саткан нугай Акчуринны үтерергә» карар кылалар. Фетнәчеләр, Кызыл Түпәдән Каган шәһәренә бара торган тимер юлның рельсларын сүтеп, Кызыл Гвардиянең юлын кисәләр, дигән хәбәрне ишеткәч, Акчурин күп уйлап тормый, 20 кешелек отряд ала да юлны карарга үзе китә. Фетнәчеләр, чыннан да, бау белән дөя муенына бәйләп, рельсларны тарттырып маташа икән.

Г. Акчурин отряды, көтмәгәндә, зур тавыш күтәреп, фетнәчеләргә ташлана. Фетнәчеләр, котлары чыгып, качып китәләр. Юлны төзәтеп Кызыл Түпәгә кайтып керүгә, отрядны тагы җәнҗал каршы ала. Фетнәчеләр монда да: «Динем өчен җаным фида!» дип кычкырып, тәкбир әйтә-әйтә, Акчурин отрядына һөҗүмгә киләләр. Ләкин Кызыл

---

[1] П. Полторацкий — Бөек Октябрь революциясеннән соң Төркстанда хезмәт халык комиссары. 1918 елда Мары шәһәрендә аклар тарафыннан атып үтерелә.

Гвардиягә каршы тора алмый чигенәләр. Шулай булса да көн саен борчып, тынгысызлап торудан туктамыйлар.

Төркстан Совет Социалистик Республикасы белән Бохара әмире арасында солых договоры төзелгәч, хезмәт иярә жирле халык арасында гаять зур ихтирам казанган Акчуринны Төркстан Советлар съездына һәм Коммунистлар партиясенең край конференциясенә үзләренең делегаты итеп сайлап Ташкентка жибәрәләр.

Г. Акчурин съездга да, конференциягә да актив катнаша һәм Төркстан Үзәк Башкарма Комитеты члены итеп сайлана, тышкы эшләр комиссариатының коллегия члены булып тора. Шунда ул 1920 елга чаклы эшли.

Төркстан территориясендә ул заманда Ташкентта төзелгән Төркстан Совет Социалистик Республикасы һәм Бохара ханлыгыннан башка тагын бер ханлык — Хива ханлыгы булып, аның үзенә күрә ханы, территориясе, чиге, гаскәре, чиновниклары бар иде. Ул ханлыкның халкы да, Бохара әмире кул астындагы халыклар кебек, феодал тормышта, коллыкта, ярлылыкта, томана хәлдә яши иде.

Бөек Октябрь революциясе тәэсире белән Хива халкы да, үзенең аяныч хәлен аңлап, ирекка, азатлыкка, бәйсезлеккә чыгарга омтыла.

1920 елның февраль аенда Хиваның соңгы ханын халык тәхеттән төшерә, анда революция жиңеп чыкканнан соң, илне идарә итү эшенә ярдәмгә Партия Үзәк Комитеты члены Г. И. Бройд житәкчелегендә гадәттән тыш комиссия жибәрелә. Комиссиягә зур хокуклар бирелә. Иптәш Бройдка урынбасар итеп Галимжан Акчурин, комиссиянең члennары итеп **Бохара революцион партиясе члennары билгеләнә.**

Чарджоудан Хивага бару өчен ике генә юл бар: берсе атка, дөягә атланып, эссе ком чүле аша, икенчесе — Аму-Дарья елгасы. Кайсыннан гына барсаң да, зур тәвәккәллек кирәк, чөнки елганың бер ягында аклар, басмачылар сагалый, икенче ягында ханның калдык гаскәрләре һәм Емудлар мыжгып тора. Әле бу вакыйгалар алдыннан гына анда безнең батыр якташыбыз, ялкынлы комиссар Бәкер Белоусов ерткычларча үтерелгән. Галимжан Акчуринның жирле халыкның теле, гореф-гадәтләре белән яхшы таныш булуы басмачыларның хәйләкәрлекләрен, сугыш һәм һөжүм итү алымнарын яхшы белүе монда да ярдәм итә. Комиссия Хивага хәвеф-хәтәрсез барып житә.

Хивага барып житү белән үк комиссия Хорезмда беренче корылтай (съезд) чакырырга дигән карарга килә. Съездга сайлау комиссиясенең председателе итеп Г. Акчурин билгеләнә. Ул, көнне-төнне белмичә, сайлау өчен кирәкле чараларны күрә башлый. Өндәмәләр, инструкцияләр яза, инструкторлар жибәрә.

Ул чакта үзбәкләр белән төрекмәннәр арасындагы дошманлыкларның, һәр үтерелгән кеше өчен үч кайтаруларның («Кыйсас» дип аталган дини йолалар) хөкем сөрүен искә алсак, ул съездны жыюның никадәр кыен эш булуын күз алдына китерергә мөмкин.

Партия тарафыннан Акчурин кебекләргә йөкләнгән вазифаларның иң зурысы шул — гасырлар буе милли антагонизм рухы белән сугарылып, үзара дошманлык, дини кыйсас традицияләрендә тәрбияләнеп килгән халыкларны берләштереп, шул халык вәкилләреннән чын кешелеклелек нигезенә корылган Совет хөкүмәте төзү иде.

Хорезм республикасының 1920 елның 27—30 апрелендә кабул ителгән конституциясе Г. Акчурин тарафыннан языла.

Галимжан Акчурин съездда Хорезм халык республикасының хөкүмәт члены һәм Югары хәрби революцион трибунал председателе итеп сайлана.

Шул ук елның май аенда Хиваның үзендә һәм урыннарда Хорезм Коммунистлар партиясе вәкилләренең жыелышын үткәрү эше башлана. Монда да иң актив эшләүче Акчурин була. Бу жыелышта Хорезм Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты оештырыла, аның секретаре итеп Г. Акчурин сайлана.

Хивада бер ел эшләгәннән соң Галимжан Акчурин, Бохара революциясен хәзерләү өчен, Чарджоу шәһәренә чакырыла. Анда 1920 елның августында булган партконференциядә Акчурин «Агымдагы вакыйгалар» һәм «Бохара әмирлеген туздыру һәм Бохарада Совет республикасын булдыру» турында докладлар белән чыга. Бу конференциядә Галимжан Акчурин Бохара Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының беренче секретаре итеп сайлана.

Бохараны контрреволюцион көчләрдән яулап алуның генераль планы Ташкентта, Төркстан фронтының командующие Фрунзе житәкчелегендә өзерләнә. Акчурин анда

Фрунзе белән якыннан таныша. Әзерлек эшләре тәмамлангач, 29 августта, ул һәм Бохара партия Үзәк Комитеты членнары утырган вагонны Фрунзе поезды составында фронтка озаталар. 30 августта, поезд Самаркандка килеп җиткәч, Фрунзе Акчуринны, Нәҗип Хөсәеновны һәм Фәйзулла Ходжаевны үз вагонына чакырып киңәшә һәм аларга соңгы инструкцияне бирә. Фрунзе үзе Самаркандта кала. Бохара коммунистлары урнашкан вагонны, махсус паровоз белән, Акчурин җитәкчелегендә Каган шәһәренә озаттыра. Акчурин, үз штабы белән Каганда торып, Бохара өчен көрәшкә конкрет җитәкчелек итә, еш кына фронтка килеп Бохара өчен сугышучы гаскәри частьлар арасында була.

Бохара алынып, әмир гаскәрләре тар-мар ителгәч, Акчурин, беренчеләрнең берсе булып, анда Совет төзелешен урнаштыру буенча тиешле чараларны күрә.

«Бохараны алган вакытта шәһәр әмир чиновниклары тарафыннан усал ният белән тертелгән уттан яна иде. Без Акчурин белән шәһәрне алган көнне үк, берничә кызылармеец алып, Бохара әмиренең шәһәр читендәге сараена киттек... Сарайда без беркемне дә очратмадык. Ишекләр шар ачык иде. Без анда барлык кыйммәтле нәрсәләрне бер бүлмәгә җыеп бикләдек һәм печатьләдек. Кыйммәтле әйберләрне җыйганда, бу сарайны карарга иптәш Фрунзе да килеп җитте. Шул чакта мин беренче һәм соңгы мәртәбә, бик якында торып, Фрунзе иптәшне күрдем. Ә Акчурин белән алар күптәннән танышлар иде. Бер-берсе белән кул биреп күрештеләр һәм озатыштылар» [1].

Бохара революциясеннән соң, контрреволюцион көчләрне бастыру өчен ЧК төзелә, ревтрибунал оештырыла. Бу җаваплы эшкә М. В. Фрунзе һәм В. В. Куйбышев тәкъдиме буенча Галимҗан Акчурин билгеләнә. 1920 елның ноябреннән 1923 елга кадәр Галимҗан Акчурин Бохара Совет республикасының ревтрибунал председателе булып эшли. Халык малын ашаган, халык канын койган әмир чиновникларын һәм палачларын хөкем итү миссиясен ул башкара. Бохараның Әфганстанга качып барган җиреннән тотып китерелгән баш вәзире Кушбигине, баш казый Каланны һ. б. ерткыч чиновникларны Ригстан мәйданында, меңләгән халык алдында гаепләрен фаш итеп, атарга хөкем чыгаручы да Акчурин була.

Акчуринның, андагы гореф-гадәтләрне саклаганы хәлдә, палачларны рәхимсез хөкем итүе, партиябезнең турылыклы улы булуы турында запастагы генерал-майор, 1919 елдан партия члены, хәзерге вакытта Фирганәдә яшәүче персональ пенсионер Нигъмәт Еникеев түбәндәгечә яза: «Мин Бохара әмиренең баш вәзирен хөкем итү процессында катнаштым. Хөкем итү ачык һавада — Ригстан мәйданында (Бохара әмиренең кышкы сарае янында — М. Г.), күп меңләгән кеше катнашында барды. Мәйдан кышлаклардан, районнардан, Бохара тирәсеннән җыелган халык белән тулган иде. Иптәш Акчурин, андагы гореф-гадәтләрне саклап, казыйларча, өстенә ефәк чапан, башына ак чалма кигән хәлдә, катнашучыларның көчле кул чабулары астында ревтрибунал судының карарын игълан итте, әмирнең баш вәзире — Кушбиги өстеннән булган гаепләү актын укыды, халык трибуналының бу кан эчүчене үлем җәзасына хөкем итүен белдерде. Митингта катнашучы халык бу гадел хөкемне кул чабып, «ура» кычкырып каршы алды».

1922 елның беренче яртысында Бохараның көнчыгышында, хәзерге Таҗикстан территориясендә, басмачылар тагын котырына башлый. Анда Төркиянең элекке хәрби министры Әнвәр паша җитәкчелегендә 10 меңгә якын басмачылар туплана. Совет гаскәрләре Дүшәмбе шәһәрен калдырып чыгарга мәҗбүр булалар. Революция дошманнарына каршы гадәттән тыш вәкаләт белән җибәрелгән комиссиягә Акчурин җитәкчелек итә. Җирле халыкның телен һәм тормышын яхшы белгән Акчурин сугышлар барганда Кызыл Армия частьларын урнаштыруда һәм азык белән тәэмин итүдә гаять зур булышлык күрсәтә. Бохара Халык Республикасы янындагы РСФСР полпреды шул хезмәтләренә рәхмәт белдерү йөзеннән Галимҗан Акчуринны исеме язылган почетлы винтовка белән бүләкли. Басмачыларны җиңгәннән соң, партиябез Галимҗан Акчуринга Урта Азиядә хуҗалык һәм культура эшләрен юлга салу бурычын йөкли. Ул

---

[1] 1918 елдан партия члены Әхмәт Сөбханкулов истәлегеннән. Ул 1916 елдан Галимҗан Акчурин белән бер заводта эшли, революция елларында Акчурин эшләгән учреждениеләрдә һәм ревтрибуналда секретарь була. Хәзер — Ашхабадта, персональ пенсионер.



*Галимҗан Акчурин Каган шәһәрендә. Утырганнардан: сулдан беренче — Г. Акчурин, басканнардан: уңнан икенче — Һ. Такташ.*

Бохара һәм Таҗикстан республикаларының мәгариф һәм финанс комиссариатларында җаваплы эшләр башкара. Бер үк вакытта Г. Акчурин, төп хезмәте белән беррәттән, партия комитеты янында партия тарихын өйрәнү буенча төзелгән бүлекләр белән дә җитәкчелек итә.

Бохарада эшләгән елларында Акчурин Һади Такташ белән һәм культура өлкәсендә эшләүче башка кешеләр белән дә очраша. Аларның бергә төшкән рәсемнәре әле дә сакланган. Әхмәт Сөбханкулов истәлегенә караганда, 1921 елның ахырларында Бохара якларына килеп чыккан Салих Сәйдәшев озак вакытлар Акчурин квартирасында торган. Хәтта Акчурин Сәйдәшевкә Италиягә укырга китәргә дә тәкъдим ясый һәм бу эштә ярдәм итәргә алына. Ләкин гражданнар сугышы шартларында бу планны тормышка ашырырга, әлбәттә, мөмкинлек булмый.

1926 елда Галимҗан Акчурин, сәламәтлеге начарлану сәбәпле, Казанга кайта. Партиянең Татарстан өлкә комитеты тәкъдиме буенча ул финанс халык комиссары урынбасары итеп билгеләнә. Ләкин ике елдан соң, авыруы көчәю сәбәпле, бу эшеннән дә китәргә мәҗбүр була. Беркадәр дәвалангач, 1930 елда, яңадан Үзбәкстанга китә һәм Ташкентта партия тарихын өйрәнү институтында эшли. Әмма сәламәтлеге бер дә яхшырмый. Дәвалану өчен Мәскәүгә килә. Ләкин авыр көрәш елларында, канлы сугыш кырларында какшаган сәламәтлеген кайтару инде мөмкин булмый. Күренекле революционер, ленинчыл большевик Галимҗан Акчурин 1933 елда утыз сигез яшендә Мәскәүдә больницада үлә.

Галимҗан Акчуринның данлыклы эшләрен Үзбәкстан һәм Төркмәнстан галимнәре үз хезмәтләрендә тирән хөрмәт белдереп язалар. Шулардан 1930 елда Ташкентта басылган «Хива һәм Бохара турында егерменче ел истәлеге» дигән җыентыкта бай материаллар бирелә. Бу китапка Акчуринның үз истәлеге дә кертелгән. 1963 елда Ташкентта басылган «За Советский Туркистан» дип аталган җыентыкта да аның турында материаллар күп. К. Мөхәммәтбирдеевның Төркмәниздат бастырып чыгарган «Хорезмда совет халык революциясенең җиңүе өчен көрәш» (1959) дигән китабында Галимҗан Акчуринның Урта Азияда Совет властен урнаштыруда куйган хезмәтләренә гаять югары бәя бирелә.

Без бүген, Татарстан республикасының 50 еллык бәйрәменә әзерләнгәндә, авыр елларда зур эшчәнлек күрсәткән ялкынлы якташыбызны — революционер һәм шагыйрь Галимҗан Акчуринны хөрмәт белән искә алабыз, аның героик хезмәте яшьләребездә яңа дәрт, яңа рух тудыруына ышанабыз.

Ибраһим Гази

## Су шигърияте



Язгы матур көн. Казанка буендагы Фукс бакчасына барып чыктым. Яр астында әйләндереп капланган көймәләр, үлгән кит балыкларын хәтерләтеп, сузылып-сузылып яталар. Елга инде кабыгын салып ташлаган, болганчык сары су өстендә пычрак бозлар айкала.

Бакчада кар эри. Бер җирдә чылтыр-чылтыр кар суы, киндерә генә юанлыгы булып, сикеренгәләп ага... миңа ул ни өчендер сабый баланы хәтерләтте. Яңа гына тәпи йөри башлаган баланы... Шундый ук сөйкемле, шундый ук гөнаһсыз, саф. Җан иясе шикелле, койма кырыена ялт кына сикерә дә яр битендәге эреп бетмәгән кар астына кереп күздән югала. Әлегә ул бик көчсез, бик зәгыйфь. Елгага барып төшкәч, ул инде күпердәй бозларны мәтәлдереп агызыр. Ә диңгезгә барып җиткәннән соң, биш катлы шәһәр йортларына охшашлы корабларны үз сыртында чөеп-чөеп йөртер...

...Бер карыйсың — сабый әле анасының күлмәк итәгенә ябышып йөри, икенче карыйсың — ул инде ярты дөньяны үз җилкәсенә алган.

1958

## Тирәкләр

Уч төбе хәтле генә җирдә дүрт тирәк агачы үсеп утыра. Алар, ахрысы, бер тамырдандыр: агай-энеләр кебек, бер-беренә сыенышып, кочаклашып басып торалар. Барсы да буйга җиткән, барысының да башы күктә. Тик арада берсе инде картайган. Бусы агалары булса кирәк. Корган ботаклары күп, очы кипкән. Бүтән агай-энеләре, каты җилдә рәхәтләнеп сыгылышып, үткән-барган кешеләргә башларын иеп калганда, агалары сыгылмый, чайкалмый. Кәүсәсе каткан, ә корган ботаклары кап-кара булып каралган. Җил килеп бәрелгәндә, бөтен гәүдәсе белән калтырана башлый, ыңгырашып, сәер тавышлар чыгарып, купкан кайрыларын селкергә тотына... Мондый чакта аңа карап торуы да куркыныч.

Яшьләр агаларының хәлен аңлап бетермиләр, ахрысы. Алар, башларын салмак кына селкеп, көяз генә боргаланалар. Аларга бу дөньяда бик күңелле.

...Бер вакыт миңа, яңгыр туктаганны көтеп, шушы тирәкләр янында басып торырга туры килде. Яшен вакытында биек агачларга сыенырга

ярамый дигәнне ишеткәнем булганлыктан, мин, тирәкләргә ышыклан-мыйча, плащыма төренеп, күрше куакларның яшел ябалдашлары астына кереп бастым.

Яшь тирәкләр каты җилдән җиргә тикле сыгылдылар. Агалары, сыгыла алмыйча, ыңгырашып, бөтен барлыгы белән тетрәнеп, яңгыр астында басып калды. Җил дуамал атлыгып килгән чакта, ул менә-менә шартлап сынар да энеләренең аяк асларына ларк итеп килеп тө-шәр кебек тоела иде.

Яңгыр болыты җилнең бик көчлесен алып килгән, ахры. Тирәк баш-лары айкалды, бөтерелде. Плащ астында утыра-утыра, мин бәреп яуган яңгырда ләчмә су булып чыландым. Инде тынамы дип торганда гына, җил тагын да ярсыбрак дуларга тотынды — җилнең иң атаманы болыт койрыгына ябышып килгән икән. Тирәкләрне арыш саламы урынына болгарга, бөтерергә кереште, яшь ботакларны, пычак белән кискән ке-бек, кисеп-кисеп җиргә атты.

Бу инде җилнең соңгы котырынуы иде, ахры, бераздан ул бер дә булмаган кебек тынды. Яңгыр да туктады, тик яфраклардан гына тач-тач итеп тамчы тама иде әле. Мин яшеренгән урынымнан чыктым да, плащымны беләгемә салып, тирәкләрне тагын бер тапкыр күздән кичердем. Яфраклары таланган, башлары тузгыган хәлдә, алар тын гына басып торалар иде. Ә агалары, сынганнан калган кара ботакла-рын тырпайтып, баһадирларча туп-туры баскан.

Мин әкрен генә үз юлым белән китеп бардым. Күпме җир киткән-мен, бер заман шарт! һәм чатырт! иткән тавышка әйләнеп карасам, яшь тирәкләр баягыча сабыр гына басып торалар, ә агалары калты-ранып җирдә аунап ята... Каты давылга чыдады, давылдан соңгы тын-лыкка чыдый алмады бичаракай...

Икенче килүемдә, үлгән тирәк ятып калган урында пычкы ярмасы гына сап-сары булып җирдә чәчелеп ята иде.

1961

## Яңгыр астындагы мәхәббәт

Көзге көннең көлүе, көлүе дә елавы... Әле генә ялтырап кояш килеп чыга, ул да булмый, тагын болыт, тагын яңгыр... Шәһәр бакчасында умырылып-умырылып яфрак коела. Сары яфрак. Бакча юлы яфрактан чуп-чуар...

Бакчачы хатын, себерке белән себереп, яфракларны куч-куч өеп бара. Ул себереп киткән җиргә шундук тагын умырылып-умырылып кызыл яфрак төшә...

Аулак бер эскәмиядә егет белән кыз бер-berенә сыенып утырганнар. Кызның иңбашларында, чуәлә итеп өелгән чәчләрендә юеш яфрак. Егетнең аркасына каз тәпие сыман өрәңге яфрагы кунган, шундый ук яфрак тезләрендә дә... Яңгыр бер ява, бер туктый. Кояш бер күренә, бер кача. Әллә кайда, бик еракта, пароход тавышы... Гүя: «Туңам! Бик туңам!» дип зарлана.

Бакчачы хатын, себерке сабына таянып, яфрак бураны астындагы кыз белән егет ягына елмаеп карап тора. Тегеләр бер-берenә сыенышып утырганнар, кыймылдап та бакмыйлар. Аларның кешедә эшләре юк. Аларга яңгыр ни дә яфрак коелу ни... Хатын карап-карап тора да аннары тагын юеш кызыл яфракларны себерергә, өем-өем өяргә тотына... Үзе һаман елмая...

Ә бакчада умырылып-умырылып сары яфрак коела...

1958

## Мунчада

Киенеп утырам. Кулына ләгән белән юеш каен себеркесе тоткан, чабына-чабына бурлаттай кызарган яшь кенә бер кеше юына торган яктан килеп чыкты да:

— Әй, банщик! — дип кычкырды.

«Банщик» дигәннәре сөяк белән сеңгердән генә торган ап-ак чырайлы бер татар карты икән. Чыбыркы белән сыдыргач, ат ничек сискәнеп чабарга тотынса, бу да кычкырган тавышка шулай сискәнеп китеп, теге кешенең кием шкафын ачарга йөгерде. Шул вакыт минем башыма шундый уй килде: «банщик» булганчы бу карт әүвәле бишектәге бала булган бит инде. Барлык әниләр кебек, аның да әнисе үзенең улын чалт-чалт сөйгәндер. Идәндә мүкәләп йөри башлагач, бүтәннәр кебек үк, ул да мәче белән бер табактан ашаган, әлбәттә. Үсеп буйга җиткәннән соң, кызлар артыннан да йөргән булырга тиеш. Битенә, гәүдә төзелешенә караганда, ул матур, таза егет булган булырга кирәк. Димәк, кызлар да аны сөйгәннәр инде. Заманында ул җир җимертеп эшләп йөргән. Картайган көнендә ни өчендер ул шәһәргә киләсе иткән, мунчага «банщик» булып кергән. Саргаеп беткән халат киеп алып, мунчада шкаф ачып, шкаф ябып, каен себеркесе сатып утыра. Юынып чыгучы кызарынган кешеләр ләгәннәрен шалт иттереп шкаф башына куялар да кычкыралар.

— Әй, банщик, ач!

— Әй, банщик, тиз бул!

Әйтерсең ут капкан.

Ә ул сискәнеп сикереп баса да, кылтый-мылтый килеп, тизрәк кием шкафы янына йөгерә. Ачкан өчен әллә ни рәхмәт тә ишетми, чөнки бит ул «банщик» кына.

Аның күңелендә яшь чагы, егет чагы, сабан туйлары, гармун сыздырып урамда җырлап йөргән заманнары, типсә тимер өзәрдәй таза чаклары, солдатка алынган булса, мылтык күтәреп «ярманга» каршы сугышып йөрүләре — барсы да, кичә генә булып үткән кебек, бик газиз, бик кадерле булып саклана бит инде. Ә бүген аңа: «Әй, банщик!» дип кенә кычкыралар, тизрәк кыймылдамаса — ачулана башлыйлар. Ни өчен, бүтән кешеләргә эндәшкән кебек, аңа «иптәш!» дип кенә эндәшмәскә? Ни өчен «Әй, банщик!» дип кычкырырга? Идәндә мүкәләп йөри-йөри, мәче белән бер табактан ашый-ашый, ул шушы тупас «банщик» сүзен ишетү өчен үскәнмени! Әнкәсе аны шушы көнелсез, ямьсез сүзне ишетсен өчен тач-тач кыйнап иркәләгәнмени!

1959

## Профессорда кунакта

Без, татар язучылары, күрше тугандаш республикаларның берсендә булган идек. Мәктәп балалары янына барырга дип, гостиница каршында машина көтеп торганда, чуенның бертуган абзыйсыдай кап-кара, өстәвенә яп-ябык бер олы яшьләрдәге агай безнең яныбызга килеп туктады да:

— Татар туганнарга сәлам! — диде.— Мин фәлән атлы кеше булам, әйдәгез мина. Хатын, бала-чага өйдә юк, бер рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз,— дип, үзенең квартиры «менә бу борылышта гына» икәнен әйтте.

Кунакка йөреп бик арган чак иде. Аның янына керсәң, ул эч дип кыстаячак. Эчми торган начар гадәтем бар дисәң, ышанмаячак. Кыстап-кыстап та эчмәсәң, үпкәләргә тотыначак. Анннары мәктәп балалары янына барыр вакыт та җитеп килә.

Бу агай үзен галим дип, фән докторы дип тәкъдим иткән иде. Андый кешенең янынннан тиктомалга гына китеп бару уңайсыз. Нишләргә инде? Ничек котылырга? Житмәсә ул инде безнең җиңнәребездән элэктереп тә өлгерде, суларга да ирек бирми — әйдәгез дә әйдәгез!

Шунда минем башыма кызык уй килде. Доктор һәм профессор булгач, бу иптәшнең китаплары күп булырга тиеш, ә китап дигәндә мин профессорга гына түгел, пәриләр башлыгының үз янына керергә дә риза.

Җинне өздергәнче баруны кулайрак күрдем. Без киттек. Кузгалыр алдыннан ул үзе төсле үк бер «чуен кыйпылчыгына» нидер пышылдады да, тегесе чатыр-чотыр чабып каядыр китеп барды.

Тагы да кызыгракы шул: мин сөйләшеп торган арада иптәшләрем шылып беткәннәр, мин бер үзем торып калганмын, шуны сизми дә барам.

Чынлап та, профессор агай якын гына тора икән. Дүрт катлы яңа йортның баскычыннан күтәрелеп, бу агайның квартирына, дөресрәге, кием-салым өчен элгечләр куелган коридор кебек җиренә килеп кердек. Эшләпәләребезне салып элдек.

— Рәхим ит, туган, рәхим ит. Менә бу минем квартирым була инде, дүрт бүлмәле,— дип, ул, кисәү башыдай кара кулы белән алга таба күрсәтеп, мине эчкә уздырды һәм бер зур бүлмәгә алып керде.

Түрдә гөберле бака шикелле җәенке рояль, стена буйларында пыяла битле китап шкафлары. Эчтәрәк тагын бер бүлмә.

— Менә монда бичәм белән минем йокы бүлмәм,— дип, янәшә куелган, өсләренә ак җәймәләр ябылган, бик затлы агачтан эшләнгән ике агач караватка күрсәтте.— Балаларны алып, бичәм әниләренә авылга кайтып китте, миндә хәзер аулак өй, бер дә тартынма!

Әле урамда чакта ук, мин, сездә хатын-кыз заты бардыр, мин хатын-кыздан тартынам дип, киреләнеп маташкан идем, бу шуна җавап булды инде.

Йокы бүлмәсеннән кире зур бүлмәгә чыкканнан соң, ул әлеге гөберле бакага ишарәләде:

— Уйнап җибәр.

— Рөхсәт итсәгез, мин китапларыгызны карар идем.

— Китаплар качмас. Башта уйнап җибәр. Тукта, бу рояль расстроенный, балалар дыңгыр-дыңгыр гел шуның янында. Әйдәле күрше бүлмәгә, анда яңасы бар.

Бу мине өченче бүлмәгә ияртеп китте. Бусында балалар караваты, кызыллы-яшелле уенчыклар һәм пианино бар иде.

— Уйна, туган, тартынма, уйна-уйна.

Кулымнан тотып, ул мине пианино янына алып килде.

— Бусы яңа, расстроенный түгел, уйна, тартынма, миндә аулак өй.

Мин, сыңар бармагым белән төртеп, «Галиябану»ны уйнадым да пианино яныннан читгендем.

— Юк, син тагын уйна, әйбәт уйныйсың.

— Мин уйный белмим.

— Белмәсәң дә уйна, тартынма. Бәлки, син аккордеонда уйный торгансын? Аккордеонны китеримме?

Мин үземнең патефоннан башка бүтән бер нәрсәдә дә уйный белмәвемне әйтергә мәҗбүр булдым.

— Нишләп генә беләсең соң син болай булгач? Әйдә булмаса эчәбез! Эчә беләсеңме?

Балалар янына барасымны сылтау итеп, эчүдән дә баш тарттым.

— Юк, син эч. Эчмәгәч тә нинди кунак инде ул?

— Миңа китапларыгызны күрсәтегез.

Без китап шкафлары торган бүлмәгә чыктык. Ул бер шкафны ачты да тезелеп торган китапларга күрсәтте:

— Болар минем дусларым. Хатын минем яшь. Китаплар минем дусларым да, сердәшләрем дә...— Аннары ниндидер кызыл папкалар алып, аларны миңа сузды.

— Менә укып бак әле шуларны, укы, укы...

Мин папкаларны ачып-ачып карый башладым. Алтын путалар белән язылган мактау кәгазьләре иде болар — берсе министерстводан, икенчесе кафедрадан, өченчесе хөкүмәттән... Юбилей көнне бирелгән булганнар.

— Син укый тор. Мин тиз генә әбигә әйтеп керим, чәй әзерләсен.

Папкалардан күренә, бу агай алдамый: ул чынлап та фәннәр докторы, профессор, байтак еллар министр урынбасары булып эшләгән. Хәзер пенсиядә. Мин папкаларны карап бетердем дә шкафтагы китапларга сузылдым. Арада бик кызыктыра торганнары бар иде. Мин берсен алып битләрен актарырга тотындым.

Агай борылып керде дә консерва тартмасы ачарга кереште.

— Куй китапларны. Хәзер ашыйбыз, эчәбез.

Өстәлгә капланган «Медицинский работник» газетасын алып ташлады. Газета астында төрле ашамлыклар булган икән, аларны төзәткәләгәннән соң, әлеге яңа ачылган консерва тартмасы белән ике шешә кызыл аракыны да шунда китереп куйды. Күрәм, бу кеше мине эчертмәкче була. Ничек чыгып китәргә? Мин, мәктәпкә ашыгуымны унынчы кат әйтеп, китәргә рөхсәт сорадым.

— Юк, рөхсәт бирмим,— диде бу, мөлдерәмә тутырган рюмканы минем каршыма китереп куйды.— Рөхсәт юк сиңа. Ишекне бикләдем, ачкычны тәрәзәдән аттым. Кунак — хуҗаның ишәге. Син министрда кунакта утырасың, беләсеңме шуны? Пенсиягә чыккан министрда. Мин зур балык идем, тирән суларда йөздем. Пөрәк чыдамады,— ул күкрәгенең сул ягына күрсәтте.— Пөрәк... Хәзер менә балык комда...

Агайның кызмача икәнен урамда чакта ук сизгән идем. Ул, күрәсең, үзенә эчәргә компанион эзләп йөргәндер, шул вакыт аның күзенә мин чалынганмын. Бәлки, алай да түгелдер, ул чынлап та мине сыйламакчыдыр, аның аңлавынча сыйлау эчертү булганлыктан, ул мине эчертмәкчедер. Хәзер миңа бердәнбер котылу чарасы булып тәрәзәдән сикерү генә калып бара иде.

Ишектә звонок шалтырады да мине бу четерек хәлдән коткарды. Бая чатыр-чотыр чабып киткән кеше, ниндидер төргәкләр тотып, минем бәхеткә, кайтып керде. Агайга компанион бар, мине кыстап аптыратмас.

— Кайттыңмы? — диде агай, тегенең кулындагы төргәкләрне алып, өстәлгә китереп куйды.— Минем кунак бөтенләй һөнәрсез кеше булып чыкты: эчә дә белми, уйный да белми. Ярый әле, син кайтып җиттең. Давайгыз, өстәл янына рәхим итегез.

Мин тагын мәктәп хакында сүз кузгаткач, хуҗа бер дә борчылмаска кушты.

— Мин сине үземнең машина белән мәктәпнең капка төбенә үк илтеп куярмын,— диде.— Закир, минем «Волга»ның ачкычы синдә бит әле?

— Гыйлемхан абый, нишләп сезнең машинаның ачкычы миндә булсын!

— Беләм-беләм, болай гына әйттем. Әйдәгез табын янына, әби тәмле нәрсә пешереп китергән.

Без әйдәдек. Рюмкаларны тотып,— мине дә күндерделәр...— өстәл янында аягөст кенә басып торабыз.

— Закирҗан туган,— диде хуҗа,— бу кешедән чыкмады, булмаса син уйнап җибәр. Музыкасыз тамактан үтми. Теге яктагысына чыгып уйна, бусы, беләсең, расстроенный. Туктале, рояльдә уйнама. Аккордеонның кайда икәнен беләсең.

Закир сандык хәтле аккордеонны күтәреп килде дә каерылып торып уйнап җибәрде.
Без рюмкаларыбызны авызга китердек.
— Иех, Закирҗан... Өзәсең үзәкләрне! Җырлап та җибәрсәнә, апаем! — дип Гыйлемхан агай идәнгә җиңелчә типте дә карт кеше өчен матур гына тавыш белән Закирдан алда ук җырлый башлады. Аңа без дә кушылып киттек.

Кара урманны чыккан чакта
Калды камчым каерылып...

...Шулай беркадәр юангannан соң, мин китәргә җыена башладым. Хуҗа, җибәрмим дип, каршы килеп караса да, Закир, минем яктан төшеп, балалар көтәләрдер ди башлагач, Гыйлемхан агай рюмкасын тиз генә авызына каплады.
— Әйдәгез алайса озатып куям. Закир, минем машинаның ачкычы синдә бугай? Беләм-беләм, юри генә... Ачкыч кесәдә...— Ул ян кесәсенә сугып куйды.
Хуҗа шактый күңелле күренә, үзе болай күп тә эчмәде шикелле.
— Мин сезне үземнең «Волга»да очыртып илтеп куям. Закир, машинаның ачкычын бир...
Хуҗа борылган арада мин Закирга пышылдап өлгердем.
— Ул безне юл чатында бәреп калдырмасмы соң?
— Машинага утыргач айный ул,— диде Закир.
Без урамга чыктык та Гыйлемхан аганың «Волга»сын көтеп тора башладык. Менә бер вакыт зәңгәр «Волга» безнең катка лихачларча выж итеп килеп туктады. Утырдык. Закир, баягы сүзен кабатлап:— рульгә утыргач айный ул, бер дә борчылмагыз,— дип, мине тагын бер тапкыр юатуны кирәк тапты.
Машина сикереп торып кузгалды да юл чокырларына чума-чума яман кызу чаба башлады. Закир, Гыйлемхан аганы бераз суытмакчы булып, ахрысы:
— Мин үз кеше, кунакны исән-сау илтеп җиткерергә кирәк бит,— дип куйды.
— Бер бөртек чәчегез дә төшмәс! — диде хуҗа, газны өстәп, машинаны тагын да «чыбыркылыйрак» төште. Борылышларда без янтаеп-янтаеп китәбез, Закир минем өскә ава, мин — Закир өстенә.
— Инспектор тотмасын үзегезне,— дип әйтеп тә өлгермәде Закир, тагын минем өскә ауды.
Гыйлемхан агай елмая гына:
— Тотканы бар. Алар мине белеп бетергәннәр инде. Туктатып честь бирәләр дә, так нельзя, Гилемхан Ямангулович, надо тише, убьетесь,— дип, шундук яңадан җибәрәләр. Мине бөтен шәһәр белә бит. Минем әти авыл көтүчесе иде, аны авылда белмәгән кеше юк иде, мине шәһәрдә белмәгән кеше юк... Көтүче малае, доктор, профессор. Син кайчан профессор буласың инде, Закир?
Мәктәп каршында мин машинадан төшеп калдым.
Гыйлемхан агадан мин көләргә уйламыйм. Мактану барлык кешегә хас нәрсә. Кайсы берәүләр доктор да түгел, машинасы да юк, ә шулай да мактанышмы мактана: янәсе, ул бер зур кеше белән мәҗлестәш булган да зур кеше аңа таба карап елмайган. Бәлки, аңа карап та елмаймагандыр, мәгәр бу кешегә елмайды булып тоелган, шул хакта ул менә ничә ел инде мактанып сөйли. Икенче берәүләр үзләренең чит илгә барып кайтулары белән мактаналар, өченчеләре курортта булулары белән, дүртенчеләре алма бакчалары белән, аның бакчасында нинди генә алма юк, кара миләшкә хәтле бар. Гыйлемхан ага мактана икән, аның исәмаса мактанырлык урыны бар. Көтүче малае, доктор, профессор. Әйдә, мактана бир, Гыйлемхан агай.

1961



**М. Гыймадиев**

# УТЛАР-СУЛАР КИЧКӘН КЕШЕ

*СССР Верховный Советы Президиумының 1943 ел 8 ноябрь Указы белән I, II, III дәрәҗә Дан орденнары булдырылды. Бу орденнар белән Совет Ватаны өчен сугышларда аеруча батырлык күрсәткән Совет Армиясендә хезмәт итүче солдатлар һәм сержантлар, авиациядә кече лейтенантлар да бүләкләнде.*

*Сугышчылар беренче батырлык өчен III дәрәҗә, икенче батырлык өчен II дәрәҗә, өченче батырлык өчен I дәрәҗә Дан орденнары белән бүләкләнделәр. I дәрәҗә Дан ордены — Алтын Йолдыз.*

*I дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнүчеләр бөтен илебездә 2500 чамасы гына. Шуларның иллегә якыны татарлар. Аларны Дан орденнарының тулы кавалеры дип йөртәләр.*

*СССР Верховный Советы Президиумының 1967 ел 6 сентябрь Указы белән Дан орденнары тулы кавалерлары льготалар белән файдалануда Советлар Союзы Геройларына тиңләштерелде.*

*Журналист М. Гыймадиев соңгы елларда татар халкының I, II, III дәрәҗә Дан орденнары белән бүләкләнгән батыр уллары турында материаллар җыю белән шөгыльләнә. Ул геройларның үзләрен, яки аларның туганнарын бөтенесен дә диярлек эзләп тапкан. Оборона министрлыгы архивында саклана торган сугыш еллары документлары арасыннан бу батырларның сугышчан юллары турында игътибарга лаеклы күп кенә материаллар тупланган.*

*Журнал үзенең укучыларына Дан орденнары тулы кавалерларыннан берсе булган якташыбыз Тимергалиев Корбанның фашист илбасарларга каршы сугышларда күрсәткән батырлыклары турындагы язманы тәкъдим итә.*



Атна буена туктаусыз яуган кар траншеяларны, артиллерия позицияләрен, пулемет нокталарын күмеп китте. Мина кырлары, тимер чыбык киртәләр дә кар астында калдылар. Җәяүле буран чокыр-чакырларны җир белән тигезләде. Юл һәм солдат сукмаклары да күздән югалдылар. Бөтен кыр гүяки үтүкләнгән ап-ак җәймәгә охшап калды. Хәтта бинокль белән караганда да фронт сызыгы каян үткәнен белергә мөмкин түгел иде. Аны тик командирлар гына картадагы кызыл һәм яшел сызыкларга карап чамалыйлар. Табигать бөтен нәрсәне әнә шулай күздән яшерде — маскировать итте.

Фронтның бу участогында сугышучы яклар инде күптән оборонада торалар, атышлар сирәк була иде. Бураннар башлангач, ике як та гүя табигать приказына буйсынгандай булды: снаряд һәм миналарга экономия ясауны күздә тотыпмы, әллә башка берәр сәбәп беләнме, атуларны киметтеләр, туп тавышлары сирәгәйде.

Корбан Тимергалиев фронтка әнә шундый көннәрдә килде. Әмма бу тынлык озакка бармады. Һавалар утыру белән, фронт тормышы яңадан элеккечә дәвам итә башлады.

Давыллы бураннардан соң немецлар үзләренең позицияләрен, тылларын, алгы сызыкка сугыш кирәк-яраклары ташу юлларын тәртипкә китерергә өлгергәнче безнең командование зур көч белән дошман оборонасына разведка ясарга булды.

Бу бурыч укчы полк подразделениеләренә һәм ефрейтор Тимергалиев хезмәт иткән, артиллерия һәм пулеметлар белән коралланган 504 нче аерым батальонга йөкләнде.

Алар бу операциягә тиешенчә һәм җентекләп әзерләнделәр. Подразделениеләрдә партия һәм комсомол җыелышлары да үткәрелде. Корбан комсомол җыелышында катнашты. Анда рота комсоргы хәрби антка турылыклы булу һәм комсомолецларның сугыштагы бурычлары турында сөйләде. Инде берничә тапкыр сугышта булган, дары исен туйганчы иснәгән, немец белән йөзгә йөз килеп очрашкан, штыкка штык килеп сугышкан һәм аны җиңеп чыккан тәҗрибәле «карт» комсомолецлар да сөйләделәр. Алар, Корбан кебек яшь солдатларга үзләренең киңәшләрен бирделәр, сугышчан тәҗрибәләрен уртаклаштылар.

Фронтта командирлар һәм политработникларның боерыкларын Корбан Ватан приказы дип кабул итә. Карт солдатларның акыллы сүзләрен игътибар белән тыңлый һәм кайчан да булса бер кирәге булыр, дип, күңел түренә салып куя.

...Аяз һәм салкын төн. Ай әле калыкмаган, күк йөзендә йолдызлар гына җемелди. Сугышчылар, тиздән кар ерып, дошман оборонасына таба киттеләр. Артиллеристлар, зур кыенлык белән булса да, орудиеләрен яңа позицияләргә күчерделәр. Ефрейтор Тимергалиев командалыгындагы пулемет расчеты да, ышанычлы дуслары «максим» пулеметын һәм кирәк кадәр патроннар алып, автоматчылар белән бер сафта барды. Алар дошман позициясенә якын ук килеп туктадылар да карга күмелеп, сигнал булу белән гитлерчылар өстенә ташланырга әзер тордылар.

Бу минутны озак көтәргә туры килмәде. Яктырып килгәндә уннарча тупларыбыз гитлерчыларга ут ачты. Әле кичә генә кар бураны котырган урында ут давылы күтәрелде. Бераздан ул «буран» дошман позициясенең эченәрәк күчерелде.

Шуны гына көтеп торган автоматчылар урыннарыннан сикереп тордылар да, өермәдәй булып, дошман позициясенә ташландылар. Тимергалиев расчеты да алар белән бергә булды.

Менә ул — дошман оборонасының беренче сызыгы. Анда безнең артиллериянең эше күзгә күренеп тора. Туп-туры килеп төшкән снарядлар траншеяларның, ут нокталарының астын өскә китергән. Кар өемнәре балчык белән аралашып буталган. Гитлерчыларның үле гәүдәләре ята.

Ләкин тагы да алга китү кыенлашты. Бераз арттарак, землянкаларда урнашкан немецлар аңнарына киләләр. Югалткан позицияләрен кире кайтарырга теләп, алар контратакага ташланды. Бер теркем гитлерчылар туп-туры Тимергалиев расчетына таба килә.

Корбан пулемет калканы өстеннән немецларга күз ташлый. Шул чакта комсорг сүзләре кылт итеп аның исенә төшә. Әле кичә генә җыелышта ул: «Үтер фашистны! Син аны үтермәсәң, ул сине үтерәчәк»,— диган иде.

Менә хәзер шул сүзләрнең дөреслеген практикада раслау минуты җитте. Тимергалиев гитлерчыларны прицелга ала һәм атмакчы була. Аз гына кичексәм дә фашистны үтерә алмам, ул мине үтермәгәе, дип уйлый.

— Тукта, атмый тор! Якынрак җибәр! — ди аңар взвод командиры.

Немецлар якынайганнан якынаялар. Ап-ак кар өстендә аларның соры киемнәре ярылып ята. Ара нибары илле-алтмыш метр чамасы гына инде. Корбанның йөрәге дөп-дөп тибә. Ләкин куркудан түгел. Фашистларны үтереп булырмы икән, дип борчыла ул. Чабыш ат сәбан туе алдыннан ярсыган кебек, Корбан да фашистларны кырырга ашкына.

— Инде, мөгаен, ярый торгандыр,— ди Корбан иптәшләренә һәм пулеметның гашеткасына баса, гитлерчылар өстенә кургаш яңгыры сиптерә башлый.

Дошманның контратакасы кире кайтарыла. Немецлар, яраланган солдатларын алып, чигенәләр. Бу участокта алты гитлерчының үле гәүдәсе кала. Яшь солдат Тимергалиев беренче сугышта ук үзен әнә шулай таныта.

Подразделениеләр дошманны кысрыклап алга китәләр. Ләкин анда тагын кыючаулык — гитлерчылар пулеметтан аталар.

— Әнә тегеннән әйләнеп барып, арт якларына төшсәк ничек булыр икән? — ди Корбан.

Взвод командиры бу планны хуплый. Тимергалиев үзенең расчеты белән дошманның ут ноктасына таба китә. Ул, гүя суда йөзгән кебек, йомшак карны куллары

белән ике якка ера-ера шуыша. Иптәшләре, «максимка» һәм патрон ящикларын өстерәп, аның артыннан шуышалар. Сиздермичә генә дошман пулеметына якын ук килеп җитәләр һәм флангтан ут ачалар. Ут ноктасы тынып кала.

Бу көнне Тимергалиев расчеты тагы бер пулемет утын бастыра һәм шуның белән һөҗүм итүче автоматчыларга алга китәргә мөмкинлек тудыра.

Корбан Тимергалиевнең фронт юлы әнә шулай башлана һәм беренче сугышта ук күрсәткән шушы батырлыклары өчен ул «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнә.

Икенче бер вакыт Корбан III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнде. Моңа ул җәйге сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен лаеклы булды.

Жлобин шәһәре тирәсендә немецлар ике елга якын тордылар. Бу вакыт эчендә алар анда көчле оборона корылмалары төзеделәр. Немец командованиесе бу тирәдәге обороналарын Совет гаскәрләре вата алмаслык «чикләвек» дип исәпли иде.

Менә шул чикләвекне «авыз итү» көннәре дә килеп җитте. 1944 елның җәендә безнең гаскәрләр фронтның бу участогында да һөҗүмгә күчтеләр. Башта, һәрвакыттагыча, артиллерия әзерлеге башланды. Ул ике сәгать дәвам итте. Нәтиҗәдә, яшел үсемлекләр белән капланган дошман оборонасы сөреп ташлаган такыр басуга охшап калды. Снарядлар төшеп ярылудан Друть елгасы да болганчык ташу суына әйләнде. Һава дары һәм көек исе белән тулды. Болай да эссе көн туплар кызудан тагын да эсселәнде.

Мондый әзерлектән соң сугышчылар дошман оборонасының алгы сызыгында инде бер җан иясе дә калмагандыр дип уйлыйлар. Ләкин калган икән. Безнең пехота атакага күтәрелү белән, немецлар пулеметтан ут ачалар. Һөҗүм итүчеләрнең кайберләре яраланып егыла, исәннәре дә ятырга мәҗбүр булалар. Немец пулеметы да атудан туктый. Сугышчылар урыннарыннан сикереп торалар да тагы йөгерә башлыйлар. Пулемет тагы ата башлый.

Рота командиры өлкән лейтенант Кратченко үзеннән ерак түгел җиргә урнашкан Тимергалиев расчеты янына килә:

— Ефрейтор Тимергалиев! Ничек тә дошманның ут ноктасын бастырырга кирәк. Бу бурычны Берлизов белән сиңа йөклим. Булдыра алырсызмы? — ди.

— Булдырырбыз, иптәш командир,— ди Корбан.

Калкулыкта урнашкан гитлерчыларның ут ноктасы янына барып җитәр өчен ике полоса үтәргә кирәк. Аның беренчесе — пеләш баш кебек такыр җир — дошмангаераграк, ләкин уч төбедәй ялтырап ята. Шунлыктан Корбан да, Берлизов та бу полосаны үткәндә башларын да күтәрмичә, җиргә сыланып бетеп шуышалар. Немецлар аларны күрми. Хәтта игътибар белән карап торган Кратченко үзе дә аларны күздән югалта.

Икенче полоса немецларга якынрак, ләкин аның каравы хәвефсезрәк. Ул элек колхоз басуы булган. Фронт полосасында калганлыктан, чәчелмәгән. Аны әрем һәм алабута баскан. Алар совет солдатларын гитлерчылар күзеннән яшерәләр.

Чүп үләннәр арасыннан шуышып бара торгач, бу ике батыр дошман пулеметына якын ук килеп җитә. Немецлар аларны күрми, Тимергалиев бер төп әремне йолкып ала да башына куя, аз гына күтәрелеп, немецларга карый. Пулемет артында ике немец күренә.

— Әйдә,— ди ул, пышылдап кына, бераз арттанрак шуышкан иптәшенә кулы белән ишарә итә.

Нишләргә кирәген аңлатып торулар артык. Егетләр бер-берсен күз карашларыннан аңлыйлар.

Менә дошман пулеметына бер юлы ике граната оча. Ышанычлырак булсын өчен, тагын берәрне тондыралар. Пулемет тына. Һөҗүм итүче пехотага юл ачыла. Алар, «ура!» кычкырып, алга ыргылалар. Шул арада бу биеклеккә Кратченко да килеп җитә. Ул уңышлы операция белән батырларны тәбрик итә һәм рәхмәт белдерә.

Безнең гаскәрләр һөҗүменнән дошман чигенә. Ләкин әле тегендә, әле монда контратакага ташлана. Шул атакаларның берсендә Тимергалиев расчеты янында гына немец снаряды төшеп ярыла. Расчетның ике кешесе — Перошков һәм Мәмәтов яраланалар. Пулемет ватыла.

Инде пулеметсыз калган Тимергалиевне рота командиры үзенең связное итеп билгели. Дошман автомат һәм пулеметлардан пуля сиптергәндә, туплар һәм минометлардан өзлексез атып торганда, Корбан, бернәрсәгә карамыйча, командирның телдән әйтелгән приказларын тапшыру өчен взвод командирлары янына йөгерә. Приказны тапшыргач, ул кире рота командиры янына ашыга.

Кызу сугыш вакытында ут астында ике арада йөгереп йөргән Корбанны күргән сугышчылар еш кына: «Ничек моңар пуля тими икән?» — дип гаҗәпләнәләр. Ә кайбер шук теллеләре: «Аның кай җиренә тисен, ул үзе дә пуля хәтле генә бит»,— дип шаярта.

Корбан җан-фәрман йөгереп килә дә рота командирына рапорт бирә. Аннары бераз ял итеп алырга уйлый. Ләкин шул чакта яннарына ук дошман минасы килеп төшә. Аның кыйпылчыгы тиеп рота командиры авыр яралана. Һава дулкыныннан Корбан да авып китә. Башын күтәреп караса, аңсыз яткан командирын күрә. Аның гимнастеркасы һәм кулмәге ертылган, канга буялган.

Корбан командирның бил каешын чишә, кулмәген күтәреп карый. Һәм Кратченконың ярасын бәйләп, сугыш кырыннан күтәреп алып чыга. Өлкән лейтенантны шунда ук медсанбатка озаталар. Бәхетенә каршы, аның ярасы каты булса да, тиз төзәлә. Бернича айдан Кратченко терелеп, яңадан үз подразделениесенә кайта. Беренче очраган солдатлардан ул:

— Кечкенә татар Тимергалиев исәнме? — дип сорый.

— Исән! — диләр аңа һәм егетнең кайда икәнен әйтәләр.

Рота командиры шунда китә. Тимергалиевне күрү белән кулларын җәеп килә дә аны кочаклап ала.

— Кадерлем! Син мине үлемнән коткардың бит,— ди.

Шул чакта Кратченконың күзләре Корбанның күкрәгенә төшә. Күрә: кечкенә буйлы, кап-кара чәчле, коңгырт күзле, бакыр кебек кызгылт-карасу йөзле Корбанның күкрәгендә ике Дан ордены ялтырый.

— Молодец, Корбан! Икенче дәрәҗә солдат даны ордены белән тәбрик итәм,— ди, Тимергалиевнең кулын кыса.

* * *

Немец җирендә барган сугышлар Корбанның күңелендә авыруча тирән эз калдырдылар. Ул көннәрне искә төшереп, Тимергалиев: «Әкияттәге кебек хәлләр баштан үтте», ди.

1945 елның апрелендә безнең гаскәрләр Нейсе елгасына килеп җитәләр. Мул сулы бу елга бераз вакытка ике якны бер-берсеннән аерып торучы фронт сызыгына әйләнә.

Бу рубежны үтү өчен безнең якта кызу әзерлек бара. Ләкин дошманның хәрби серләрен дә белергә кирәк. Разведчиклар «тел» алып кайту нияте белән бернича тапкыр ауга баралар, ләкин уңышка ирешә алмыйлар. Ә дивизия штабы начальнигы «тел» таләп итә.

Бер көнне ул разведчиклар ротасы командиры Таланкинны үзенә чакырта һәм мәсьәләне бик кискен куя:

— Кайчан син безгә «тел» тотып китерәсең? Ә!

Капитан:

— Иптәш полковник...— дип нәрсәдер әйтмәкче була, лакин полковник авызын да ачтырмый тегенең.

— Үзең бар! Әгәр кирәк булса, бөтен ротаң белән бар! Ләкин «тел» алмыйча кайтма! Әйтәсе сүзем шул. Бар, үтә әмерне! — дип кырт кисә.

Капитан сүзсез буйсына һәм:

— Тыңлыйм, иптәш полковник. Приказ үтәлер,— дип чыгып китә.

Бернича разведчик җибәреп кенә эш чыкмаячагын капитан яхшы аңлый. Шуңа күрә ул бу юлы разведкага җитмешләп кеше җибәрергә карар кыла.

Саперлар тиз генә саллар әзерлиләр. Караңгылану белән аларны суга төшерәләр. Разведчиклар, өч салга төялеп, уң як ярдан кузгалып китәләр.

Дошман елга өстенә әледән-әле яктырткыч ракеталар җибәрә. Туплардан, минометлардан ата. Снарядлар төшкән урында багана-багана булып су күтәрелә. Инде

яргы якка чыгып җитәбез генә дигәндә, арттагы сал янына снаряд килеп төшә. Аның дулкыннары салга китереп сугалар. Ул шунда ук тарала. Егермедән артык разведчик су эчендә кала. Ләкин коралларын кулдан ычкындырмыйлар. Бүрәнәләргә ябышып, ярга чыгып җитәләр һәм иптәшләренә кушылалар. Шуларның берсе разведчик Корбан иде.

Бу участокта яр буенда немецлар булмый. Разведчиклар, бер минутны да әрәм итмәстән, «тел» эзләп, ярдан эчкәрәк китәләр. Нәфселәре бик зурдан түгел: берничә, хәтта бер «тел»гә дә канәгать. Ләкин алай килеп чыкмый. Бара торгач, алар дошман оборонасының гаскәр белән мыжгып торган участогына килеп керәләр.

Көтелмәгән бу «кунакларны» күргәч, гитлерчылар башта каушап калалар. Шуның аркасында алар йөзләрчә кешеләрен югалталар. Сугыш төне буе дәвам итә. Разведчиклар көч-хәл белән бер генә гитлерчыны тотып алалар һәм аны үзебезнең якка озаталар. Димәк, аны исән-сау алып кайта алсалар, задание үтәләчәк. Җибәрелгән группага үзебезнең якка кире чыгарга да ярый. Ләкин бу мөмкин булмый. Чөнки дошманның һөҗүмен кире кайтарырга кирәк. Мондый хәл туганда чын патриотлар үлгәнче сугышалар, ләкин чигенмиләр.

Разведчиклар оборона сугышына күчәләр. Яраланган иптәшләрен яр буена ташыйлар, үзебезнекеләр ягына озаталар. Шул арада сызылып таң ата, кызарып кояш чыга.

Ярканат кебек, гел төнлә генә йөрергә гадәтләнгән разведчиклар, билгеле, моңа шатланмыйлар. Якты көн аларга җиңеллек китерми. Көндез разведчикларга дошманның тагы ике контратакасын кире кайтарырга туры килә. Кичкә таба дошман туп һәм минометлардан атуны көчәйтә. Аннары тагын да зуррак көч белән һөҗүмгә күчә.

Разведчикларның патроннары, гранаталары бетә, дошманга каршы торырлык көчләре калмый инде. Командир су аша кичәргә приказ бирә. Ләкин яр буендагы бердәнбер сал агып киткән. Исән калган сугышчылар суга сикерәләр. Кайберләре елганы турыга йөзеп чыкмакчы була, дулкыннар өстендә тирбәлә-тирбәлә, алар елга уртасына кереп китәләр.

Туган авылында үскәндә һәм Саба мәктәбендә укыганда да чишмә һәм инештән башканы күрмәгән Корбан язгы ташу белән тулы Нейсе елгасын йөзеп чыга алуына ышанмый. Ул үз язмышын яр кырыеннан ук үткән агымга тапшыра. Монда йөзү өчен көч куярга кирәк булмый, бетерелеп-бетерелеп аккан көчле агым Корбанны елганың түбән агымына таба алып китә.

Бераз баргач, елга кинәт борыла. Нәкъ шул урында агым елганың уң як ярына барып чыга һәм ул Корбанны да шунда алып килә. Аның артыннан шул ук агым белән тагы бер разведчик килеп җитә. Алар икесе дә ярга менәләр. Баштанаяк чыланган киемнәре тәннәренә ябыша. Коры җиргә аяк басу белән салкынлык үзен сиздерә башлый. Разведчикларның тәннәрә чымырдап китә. Ләкин йөрәк җылысы тышкы салкыннан көчлерәк булып чыга. Шатлыклары җылыта аларны. һәм үз юллары белән китеп баралар.

Ләкин разведчикларны монда да үлем сагалап торган икән. Берничә адым атлауга, Корбанның иптәше, үзебезнең саперлар куйган минага туры килеп, һәлак була.

Тимергалиев баскан урынында туктап кала. «Нишләргә?» дип үз-үзенә сорау бирә. Бераздан зур саклык белән кузгалып китә (минадан сакланам дип, кире суга сикереп булмый бит). Берничә адым атлый. Аяк астында тар гына сукмак күрә. Бу сукмак аны үзебезнекеләр янына илтә.

Икенче көнне безнең төп көчләр берничә урыннан Нейсе елгасы аша үтәләр һәм немецларны куып китәләр. Шул чакта разведчикларның бу бәрелештә күрсәткән батырлыклары ачыклана. Тигезсез сугышта безнең дистәләрчә разведчикларыбыз һәлак була. Ләкин дошман тагын да зуррак югалтуларга дучар ителгән икән. Аның дүрт йөздән артык солдат һәм офицерлары дөмектерелгән!

СССР оборона министрлыгы архивында саклана торган документларның берсендә бу операциядә катнашкан Тимергалиев турында болай диелгән: «Разведчик кече сержант Тимергалиев Бударозе районында Нейсе елгасын кичкәндә һәм дошман оборонасын өзгәндә беренчеләрдән булып елганы йөзеп чыкты һәм разведчиклар группасы белән дошманның беренче траншеясына бәреп кереп, гранаталар ыргытып, дошманның бер взводка якын пехотасын юк итте».

Һөҗүм дәвам итә. Дошманның оборонасы төрле җирдән өзелә. Безнең алдан баручы отрядлар бер участокта дошман оборонасына үтеп керсәләр, икенче участокта нык каршылыкка очрыйлар.

Тимергалиев хезмәт иткән часть та тукталып кала. Төнне яңа позициядә үткәрә. Командование, яңа һөҗүмгә көчү алдыннан разведчиклар җибәреп, дошманның «хәлен» белергә, ә иртәгесен һөҗүмне яңадан башлап җибәрергә уйлый.

Иртән кояш чыгып килгәндә, разведчиклар командиры бу турыда Тимергалиевкә әйтә:

— Әзерләнеп тор, кич белән «ауга» барасыз,— ди.

— Хәзер үк барырга мөмкин,— ди Корбан.

— Белмим шул,— ди командир, бераз уйлап.

Командирның икеләнүен күргәч, Корбан өстәп куя:

— Барып карыйк. Бәлки юлыбыз уңар...

Командир каршы килми.

— Кем белән барасың?

— Девиков белән,— ди Корбан.

Ике разведчик, дошман гаскәрләренең хәрәкәтен күзәтү максаты белән, гитлерчылар ягына кереп китә. Ләкин якында гына немецлар күренми. Тик кайдандыр туптан сирәк-сирәк аталар. Разведчиклар һаман эчкәрерәк керәләр. Бара торгач, бер үзәнгә килеп чыгалар, аннары бер траншеяга килеп төртеләләр.

— Киттекме? — ди Корбан, иптәшенә карап.

— Әйдә, киттек,— ди Девиков.

Алар траншея буйлап бара башлыйлар. Тиздән бер землянкага килеп җитәләр. Аның ишеге ябык. Эчтә гырлаган тавыш ишетелә. Девиков, бер кырыйга сырышып, ишекне акрын гына ача. Тимергалиев автомат көпшәсен төзәп:

— Анда кем бар? Чыгыгыз! Хенде хох! — дип кычкыра.

Ләкин җавап бирүче булмый. Корбан ишеккә башын тыгып карый. Күзләренә берничә пар ботинка ташлана. Аннары сузылып яткан немец солдатларын күрә. Корбан тиз генә эчкә керә. Немец солдатларының автоматларын бер почмакка җыя да бөтен көче белән кычкыра:

— Гитлер капут! Торыгыз! — ди. Немецлар күзләрен уа-уа сикерешеп торалар. Нәрсә булганын аңламыйлар. Каршыларында совет солдаты тора. Ул аларга автоматын төзәгән. Аз гына кыймылдасалар яки якын килә башласалар да аларның күкрәгенә атачак.

Шул арада ишек артыннан Девиков кычкыра:

— Тизрәк бул! — ди.

Немецлар камалуда калдык дип уйлыйлар һәм, кулларын күтәреп, берәм-берәм землянкадан чыгалар. Девиков аларны «лаеклы» рәвештә каршы ала.

Разведчиклар әсирләрне алып кайтырга чыгалар. Алдан Тимергалиев бара. Траншея буйлап барганда немецча сөйләшкән тавыш ишетелә. Тимергалиев, автоматыннан атарга әзерләнеп, алгарак китә. Менә борылыштан ике немец килеп чыга. Автоматларын җилкәләренә асканнар. Кулларында дүртәр-бишәр котелок. Корбан аларны күрү белән:

— Хенде хох! — дип кычкыра. Немецлар аптырап калалар, котелоклы кулларын күтәрәләр.

«Менә мәсьәлә» дип уйлый Корбан. Автоматларын ташлатыргамы, юкмы? Әллә котелокларын тоткан килеш барсыннармы? Әмма автоматларын үзләрендә калдыру куркыныч. Берәр уңай моментта файдаланулары мөмкин. Салганда да этлек эшләүләре бар.

Тимергалиев шулай да гитлерчыларны коралсызландырырга карар кыла. Моның өчен ул кулына граната ала да югары күтәрә. Әгәр дошман автоматын җилкәсеннән салганда атарга уйласа, шунда ук алар өстенә граната ыргытачагын белдерә. Немецлар моны аңлыйлар. Автоматларын җилкәләреннән алып ыргыталар.

Бу немецлар блиндажда йоклап калган иптәшләренә иртәнге аш алып кайталар икән. Тик фашистларга аны ашарга туры килми.

Нибары ике-өч сәгать вакыт үтә. Разведчиклар кире әйләнеп кайталар. Тимергалиев рапорт бирә:

— Иптәш командир! Без кайттык. «Кунакларны» кабул итегез!

Берьюлы унсигез әсирне күреп, командир аптырап кала.

— Молодец, Корбан! Молодец, Девиков! — ди ул. Ике разведчикның да кулларын кыса.

Алып кайткан гитлерчылар немецларның бу участоктагы көчләрә турында кыйммәтле мәгълүматлар бирәләр. Шул көнне безнең гаскәрләр дошманның бу участоктагы оборона үзәге Ношке авылын ала.

Сержант Тимергалиев Корбанның Нейсе елгасы буендагы сугышларда күрсәткән батырлыкларына Ватаныбыз югары бәя бирде. Аны I дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләде. Ул чакта әле егерме генә яшьлек егет солдат даны орденының тулы кавалеры булды.

* * *

Тимергалиев гитлерчыларны Франкфурд шәһәренә кадәр куып барды һәм сугыш беткәч бераз вакыт шунда торды.

Бер көнне ул шәһәр урамыннан бара иде. Бер немец русчалап:

— Исәнмесез, иптәш сержант,— дип эндәшә. Корбан аптырап кала. Ни дип җавап бирергә дә белми.

— Әллә танымыйсызмы? — ди теге.

— Юк,— ди Тимергалиев.

— Хәтерлисеңме? Син безне землянкада пленга алдың...

— Хәтерлим,— ди Корбан.

— Ничек син безгә атмадың, ничек безне исән калдырдың? Әйдә безгә рәхим ит, хатыныма күрсәтим үзеңне. Кунак булырсың,— ди.

Бу немец беренче империалистик сугышта Россиядә әсирлектә булган икән. Шул чакта ул бераз русча өйрәнгән. Тел белү аркасында ул икенче әсирлектән тиз котылган. Шәһәр комендатурасында тәрҗемәче булып эшли икән.

* * *

Сугыштан соң Татарстанда бай нефть ятмалары табыла. Бу хәбәр Килдебәккә дә килеп җитә. Колхозчы Тимергалиев шунда китәргә карар кыла. Язмыш аны Әлмәткә алып килә. Ул чакта Әлмәт, район үзәге булса да, гади татар авылыннан Серни белән дә аерылмый. Нефть промыселлары эшли башлау белән анда һәм шул тирәдәге бөтен авылларга илебезнең төрле почмакларыннан күп санлы эшчеләр артып тула. Ә торак шартлары чиксез кыен. Гади эшче Тимергалиевнең дә квартирасы булмый. Хатыны Хатимә моның өчен һаман ирен талкый:

— Кайларга алып килдең син мине, Корбангали? Шәһәргә алып барам диган идең бит. Безнең Саба да бу Әлмәттән яхшырак. Әллә тартәне борабызмы туган якларга?

— Сабыр ит, акыллым. Без шәһәр салабыз — нефтьчеләр шәһәре. Квартира да булыр, барысы да булыр. Мәскәүне дә бер көндә салмаганнар. Хәтта сезнең Евлаш тавын да! (Саба районындагы авыл.)

Әйе, Тимергалиев Әлмәт шәһәренә нигез ташы салучыларның берсе. Күп кенә торак йортлар, мәктәпләр, культура учреждениеләрен салуга аның да хезмәте кергән.

Шәһәрнең асфальт җәелгән һәм як-якларына агачлар утыртылган матур урамнарыннан үткәндә, ул, гүя үзе салган кирпечләрне танырга теләп, гаҗәп игътибар белән карап бара. «Шәһәрнең барлыкка килүендә минем дә өлеш бар бит»,— дип горурлана ул.

Гитлерчы яуларга каршы сугышта батыр пулеметчы, куркусыз разведчик, Дан орденнары тулы кавалеры, сугыштан соң эшче-төзүче, десятник, хәзерге көндә прораб Тимергалиев Корбангали бүген дә Әлмәттә яши. Коммунизм төзүчеләр сафындагы тырыш хезмәте өчен ул күп тапкырлар мактау грамоталары белән бүләкләнгән һәм республиканың Мактау тактасына кертелгән.

# ДАНЛЫ ЮЛ

Дәһшәтле еллар... Тарихи көннәр... «Аврора» залплары гомер-гомергә изелеп килгән хезмәт халкынын азат булуын белдереп сигнал бирде. Ул азатлык меи төрле дошманга каршы барган кискен көрәштә яулап алынды.

Идеология, мәгариф фронтында да көрәш җиңелдән түгел иде. Әнә шул тарихи көннәрдә, Бөек Октябрь социалистик революциясенең җиңүенә бер ел тулган чакта, Казанда татар телендә фәнни-педагогик журнал «Мәгариф» чыга башлый.

Совет дәүләте үзенең беренче елларында ук халык мәгарифенә, караңгылыкта җәфа чиккән халыкны агартуга зур көч куя. РСФСР Халык Комиссарлары Советының 1917 нче елның 9 нчы ноябренда һәм 1918 нче елның 26 нчы июнендә В. И. Ленин имзасы белән чыккан декретлары мәктәпләр һәм халык мәгарифе эшенең төп юнәлешен күрсәтте. «Мәгариф» журналы да үзенең төп кыйбласын әнә шул декретлар яктылыгыннан чыгып билгели. Журналның беренче санында ук бу турыда ачык әйтелә:

«7 нче ноябрьдан башлап Казанда Мәркәз Мөселман Комиссариаты янындагы «Гыйльми һәйәт»нең органы булган «Мәгариф» исемле журнал чыга башлады. «Мәгариф» журналы рәсми, тәрбияви, әдәби, фәнни бүлекләрдән гыйбарәт булып, айга ике тапкыр чыгачак.

Мәктәпләребезне эш мәктәбе нигезенә кору, аларны тормышка якынайту, тормышның гыйльми якларын төзү, татар пролетариатына киң рәвештә аң-белем тарату өчен бөтен көчен сарыф итәчәк.

«Гыйльми һәйәт»нең эшләгән эшләре, ясаган план һәм докладлары белән укучыларны таныштыра торачак.

Мәктәпкә чаклы тәрбия, мәктәптән соң тәгълим мәсьәләләренә, яңа рухтагы тәгълим, тәрбиягә мотагаллыйк[1] китапларны, гыйльми, фәнни әсәрләрне җентекләгән мәкаләләргә, гомумән, уку, укыту, мәгариф эшләренә баглы мәсьәләләргә киң урын бирәчәк.

Мәктәп, көтепханә, музейханә, укучы, укытучы һәм мәктәпкә баглы башка эшләр хакындагы декрет, лаихә һәм планнарның мөһимнәрен яза барачак»,— диелә журнал тышлыгының өченче битендә.

Югарыда күренгәнчә, журнал үз алдына әнә шундый зур планнар куя. Халык мәгарифе өлкәсендәге иң актуаль мәсьәләләргә: бердәм эш мәктәбе төзү, балаларга хезмәт тәрбиясе бирү, өлкән яшьтәгеләрне укыту, педагогика тарихын өйрәнүгә караган, үз чоры өчен бик муафыйк проблемаларга алга таба журнал битләрендә зур урын бирелә.

Бу журналны кемнәр оештырып җибәргән, кемнәр аның рухын билгеләгән дисезме? «Мәгариф»нең беренче редакторы революционер һәм галим, педагог һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе, татар совет әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов була. Аңа бу эштә актив җәмәгать эшлеклесе, күренекле педагог, журналист Шәһит Әхмәдиев турыдан-туры ярдәм итә.

Журналның беренче санында ук Галимҗан Ибраһимовның «Бөек Бәйрәм (1917—25 нче октябрь —1918—25 нче октябрь, яңача 7 нче ноябрь)» дигән үз мәкаләсе бар. Ул гаять әһәмиятле, тирән эчтәлекле мәкалә. «Бу бәйрәм — большевиклар яки эшчеләр бәйрәме генә түгел, бу — бөтен дөнья мазлумнары[2] бәйрәме, туачак нәтиҗәсе буенча бөтен инсаният бәйрәмедер.

Без өмет итәбез һәм ышанабыз — Россиядә милли, икътисади азатлык байрагын хаким иткән Октябрь революциясе үзенең бишегендә генә калмаячак, ел үсәсен ай үсә, ай үсәсен көн үсә торган тарихи каһарманнар рәвешендә тизлек белән үсеп...

[1] Мотагаллыйк — бәйләнешле.

[2] Мазлумнары — изелүчеләре.

золымнын, капитализмның актык нигез ташларын җимереп, юк итеп, иске, буржуаз мәдәниятне ватып, инсаниятне яна, якты, матур, тигез вә иркен хаяткә чыгарачактыр»,— ди автор. Һәм шуңа күрә дә ул, редактор буларак, мәгариф эшенә, халыкны агартуга, яшь буынны тәрбияләүгә багышланган һәм укытучыларның эшләрендә практик ярдәм күрсәтерлек материаллар урнаштыруга, аларны әдәби эшкәртүгә зур әһәмият бирә. Гомумән, журналның беренче адымнарында, ягъни иң мәшәкатьле, катлаулы көннәрендә, аңа юнәлеш бирүдә Галимҗан Ибраһимовның роле зур була. Ул «Мәгариф» битләрендә үзенең гыйльми, методик мәкаләләре белән еш чыгыш ясый, гомеренең соңгы көннәренә кадәр аның эшенә актив катнашып килә.

Галимҗан Ибраһимов белән бергә Шәһит Әхмәдиев тә бик актив эшли. Журналның беренче санында ук аның «Совет хөкүмәтендә мәгариф» дигән мәкаләсе басыла. Шушы ук санда «Әхмәд» псевдонимы белән урнаштырылган «Зилзилә көткәндә...» дигән мәкалә дә аныкы булса кирәк.

«Мәгариф» журналы үзенең башлангыч чорында ук татар теленең орфографиясе, аны камилләштерү мәсьәләләре белән кызыксына башлый. Журналның икенче санында Галимҗан Шәраф һәм Мөхетдин Корбангалиевләрнең «Татар имласы вә язуы турында» дигән мәкаләсе әнә шул турыда сөйли.

1918 нче ел... Бу чордагы укытучылар составын күз алдына китерик. Бик чуар ул. Әлбәттә, ул елларда күп кенә укытучыларны идея-политик яктан тәрбияләүгә, укытуны тормышка якынайтуга зур көч куярга кирәк була. «Мәгариф» журналы бу хакыйкатьне бер генә минутка да истән чыгармый. Журналның икенче санында ук укытучыларга юнәлтелгән махсус мөрәҗәгать чыга.

«Тарихыбыз укытучылар өстенә зур вазифа йөкли. Халыкның ачы тормышы өчен көенүчеләрдән булган шагыйрь Некрасов сезгә: «Мөмкин кадәр халык арасына күбрәк яхшылык орлыгы чәчегез!» дигән иде. Хәзер без дә сезгә шул ук сүзләр белән мөрәҗәгать итәбез һәм сезнең, бөтенегез бергә оешкан хәлдә, халык арасына барып мәхәббәт орлыгы чәчәсегезгә, халык белән кулга-кул тотынышып, әлегә кадәр безнен уебызга да кереп чыкмаган, гали, якты матур тормышның нигезен салу юлында хезмәт итәчәгегезгә ышанабыз...

Әгәр сез чынлыкта киң пролетариатны капиталның матди вә мәгънәви коллыгыннан коткарасыгыз килсә, әгәр сезнең хаяти юлыгыз инкыйлаби (революцион) идеалның нуры белән яктыртылсын дисәгез — пролетариат вә бөтен эшче галәм белән табанга-табан басып барырга тырышыгыз. Халыктан тыш хаят юк. Халыктан тыш иҗат-төзү дә юк. Һәрвакыт халык... белән бергә булырга тырышу укытучыларның иң гали, иң мөкатдәс бурычлары булырга тиеш»,— диелә ул мөрәҗәгатьтә.

Мәгълүм ки, «Мәгариф» журналы беренче саннарында ук күтәрелгән мәсьәләләргә ленинчыл күзлектән чыгып бәя бирә, халыклар дуслыгы, интернационализм идеяләрен алга сөрә. Беренче санда, мәсәлән, Мәскәүдә чыга торган «Народное просвещение» журналыннан Вольбергның «Мәктәпләрне яңарту хакында мәгариф комиссариатының эшләгән эшләре» дигән мәкаләсен тәрҗемә итеп урнаштыра. «Эш мәктәпләрен гамәлгә кую юлында» дигән мәкаләдә журнал Казан губернасындагы мәгариф эшләре белән таныштыра. Бу номерда шулай ук РСФСР Халык Мәгарифе Комиссариатының «Коммуналь мәктәптә эшле тәрбиянең әсаслары» дигән положениесен күрергә мөмкин.

«Мәгариф» журналында ул чор өчен иң актуаль темаларның берсе — эш мәктәбе төзү, мәктәпләрдә эшнең куелышы мәсьәләсе. Мәсәлән, журналның 1918 нче елда чыккан 3 нче санына күз салыйк. Анда «Эш мәктәбе» (Насих Мөхетдинов тарафыннан язылган булса кирәк), «Мәктәп янында балалар клубы», «Өлкәннәр арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү юлында» кебек чыгышлар, туган илне өйрәнү программасы, шулай ук «РСФСРда эш мәктәбе турында положение» бар.

...Гражданнар сугышы еллары. Бу чорда «Мәгариф» вакытлыча чыкмый тора. Моның сәбәбен көнчыгыштан Колчак бандалары якынлашып килүдән һәм илдәге кытлыктан, күп кенә экономик кыенлыклардан эзләргә кирәк.

Ләкин озак та үтми, ТАССР төзелгәч, Татарстан Халык Мәгарифе Комиссариаты органы буларак, 1921 нче елның апреленнән журнал яңадан чыга башлый. Бу елны аның редакторы булып Вәли Шәфигуллин эшли, ә Мөхәммәтхан Фазлуллин җаваплы секретарь була.

Бик кыен чор була бу. Идел буенда коточкыч ачлык хөкем сөрә. Мәктәпләр ябыла. Укытучылар төрле якка тарала башлыйлар. Шундый көннәрдә журнал мәгариф работникларын кыенлыкларны

жинеп чыгарга өнди, эшкә рухландыра. Бу чорларда редакция коллективы белән берлектә, Насих Мөхетдинов, Мөхетдин Корбангалиев, Хуҗа Бәдигый, Галимҗан Ибраһимов, Фазылҗан Хәмидуллин, Габбас Сәйфи һәм башка күп кенә иптәшләр журнал эшендә зур активлык күрсәтәләр. Журнал педагогларны төрле документлар белән таныштыра, үрнәк программалар, методик мәкаләләр бирә, укытучыларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләрен яктырта.

1922 нче елда журналның 1 генә яңа саны чыгып кала.

1923—1924 нче елларда Гаяз Максуд һәм Фатих Сәйфи-Казанлы журналның җаваплы редакторлары булалар. 1924 нче елның декабреннан 1925 нче елның октябренә кадәр журнал «редактор-редколлегия» имзасы белән чыга. Һәм шушы чор азагында редколлегиянең яңа составы раслана. Редактор итеп халык мәгарифе комиссары Мөхәммәт Таһиров билгеләнә. Ә Мөхетдин Корбангалиев, Галимҗан Ибраһимов, Насих Мөхетдинов, Хөснетдин Кәримов (Хөсни Кәрим) — редколлегия членнары. Мирсәет Сафин җаваплы секретарь булып эшлиләр.

Еллар уза. Журналның 1927 нче елгы 8 нче саныннан — редактор вазифасын Насих Мөхетдинов, ә соңга таба А. Биктаһиров, М. Вәлитова, Хәсән Хәйри, Фатих Махиянов иптәшләр үти.

«Мәгариф» үзенең яшәү дәверендә һәрчакны иң актуаль мәсьәләрне күтәрергә, укытучыларны шул проблемаларны чишүгә тупларга омтыла. Журнал битләренә күз салу аның бу бурычны шактый уңышлы хәл итүен күрсәтә.

Егерменче елларда өлкәннәр арасында грамотасызлыкны бетерүгә, авылда мәгариф эшен оештыруга, яңа укыту методларын аңлатуга зур урын бирелә. Үз чорында журнал битләрендә В. И. Ленин, Я. М. Свердлов, М. И. Калинин, А. В. Луначарский, М. Н. Покровский имзалары белән чыккан күп кенә документлар урын ала. Журналда, бигрәк тә беренче унъеллыкта, күренекле дәүләт эшлеклеләренең күп кенә мәкаләләре басыла. Мәсәлән, В. И. Ленинның «Көндәлектән битләр» дигән мәкаләсе татарча беренче мәртәбә «Мәгариф» битләрендә чыга. 1924—1925 нче елларда чыккан журнал битләрендә Н. К. Крупскаяның да дүрт-биш мәкаләсе белән танышырга була. 1925 нче елның апрелендә Н. К. Крупская үзенең «Чишелергә тиешле мәсьәләләр» дигән мәкаләсен турыдан-туры «Мәгариф» редакциясенә җибәрә. Ул биредә ана һәм рус телләрен укытуны яхшырту, дәреслекләрнең сыйфатын күтәрү турында сөйли. Гомумән, аның барысы егермедән артык мәкаләсе татарчага тәрҗемә итеп бирелә. Күренекле совет педагогы А. С. Макаренконың да күп кенә хезмәтләре шушы журнал аша татар укытучыларына үз вакытында җиткерелә.

«Мәгариф»нең (1936 нчы елда ул «Башлангыч мәктәп», 1937 нче елның дүртенче саныннан башлап «Совет мәктәбе» исемендә чыга) авторлар составы бик киң була. Күренекле язучылар, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре, мәсәлән, әйткәнебезчә, Галимҗан Ибраһимов, Шәһит Әхмәдиев, Мөхетдин Корбангалиев, Мөхәммәтхан Фазлуллин, Насих Мөхетдинов, Фатих Сәйфи-Казанлы, Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин, Хуҗа Бәдигый, Гыйбад Алпаров һәм башка бик күп иптәшләр журнал битләрендә еш кына чыгыш ясыйлар.

Бу традицияне хәзер «Совет мәктәбе» журналы уңышлы дәвам иттерә. Журнал укучылар язучы һәм галимнәрдән Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази, Хатыйп Госман, Гази Кашшаф, Мөхәммәт Гайнуллин, Мирфатих Зәкиев һәм башка күп кенә иптәшләрнең мәкаләләрен бик җылы каршы алалар.

РСФСР Мәгариф министрлыгының җаваплы работниклары, Мәскәү галимнәре дә (министр А. И. Данилов, аның урынбасары М. П. Кашин, СССР Педагогия фәннәре академиясе президиумы члены Ф. Ф. Королев, А. Янцов, И. Огородников һ. б.) «Совет мәктәбе»ндә еш кына чыгыш ясыйлар.

Укыту-тәрбия эше — бик җаваплы һәм шуның белән бергә бик катлаулы эш ул. Укытучыларга, мәгариф работникларына туктаусыз укырга, үз белемнәрен күтәрү өстендә эшләргә туры килә. Ярларыннан ташып аккан Идел дә, әгәр ул меңнәрчә вак елгалардан көч алып тормаса, бик тиз саегып бетәр иде. Укытучылар да шулай. Фән һәм техника, педагогика, психология өлкәсендәге яңалыклар белән эзлекле рәвештә танышып баралар алар. Ә яңалыклар исә бик күп. Хәзер һәр сигез ел саен фәнни информацияләр күләме ике мәртәбә арту факты да моны бик ачык раслый. Ул яңалыкларны укыту-тәрбия процессында ничек кулланырга? Яңа шартларда эшне ничек оештырырга?

Укыту процессын камилләштерү, укучыларның танып белү активлыгын һәм

мөстәкыйльлеген үстерү, проблемалы укыту буенча Татарстан мәктәпләрендә башланган хәрәкәт илебезнең күп мәктәпләрендә куллану тапты. Алдынгы педагогик тәҗрибәне барлык укытучыларга җиткерүдә, әлбәттә, «Совет мәктәбе» журналы зур роль уйнады.

Яңалыкка омтылу, иҗади эшләү киң колач алды. Хәзер, шәһәрдә һәм район мәктәпләрендә күп кенә укытучыларның дәресләренә кергәч, шатланып туя алмыйсың, укучыларның фикерләү сәләтен, танып белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерү буенча ничек матур эшлиләр безнең алдынгы укытучылар! Җыр кебек бара, поэма кебек тыңлана торган мондый дәресләр үткәрүгә ирешү өчен, укытучыга күпме түземлелек, күпме белем, күпме осталык кирәк! Энҗе бөртекләрен җыйган кебек, алар алдынгы педагогик тәҗрибәне туплый, аны иҗади үзләштерә баралар. Ә бу эштә укытучыларга педагогик-методик журналлар ярдәмгә килә. Соңгы елларда «Совет мәктәбе» журналында укыту-тәрбия эшендә зур әһәмияте булган, Татарстан укытучыларының алдынгы тәҗрибәсен яктырткан йөзләрчә мәкаләләр чыкты. Журналның авторитеты барлык татар мәктәпләре укытучылары алдында бик нык үсте. Хәзер «Совет мәктәбе» журналын Татарстаннан читтәге 6 автономияле республикада, 23 өлкәдә, 1 крайда, 6 союздаш республикада алдырып укыйлар.

«Совет мәктәбе» журналының алдынгы педагогик тәҗрибә таратудагы ролен үзәк матбугат, мәсәлән, «Народное образование», «Русский язык в национальной школе» журналлары бик уңай бәяләде.

Журналыбызны укучылар да укыту-тәрбия процессын оештыруда «Совет мәктәбе»нең әһәмиятен күрсәтеп, проблемалы укыту, укучыларның танып белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерү, программалаштырылган укыту, техник чаралардан файдалануга багышланган фәнни һәм практик мәкаләләрдән ничек файдалануларын күрсәтеп, редакциягә рәхмәт хатлары җибәреп, эшлекле киңәшләр әйтеп торалар. Менә әле яңа гына килеп төшкән хат белән танышып үтик. Аны Пермь өлкәсенең Барда районыннан Хәлимә Мансурова иптәш яза:

«Совет мәктәбе» — яраткан журналым. Балаларга тирән белем бирүдә һәм аларны югары коммунистик аңлылык рухында тәрбияләүдә, көндәлек эшемдә ярдәмчем һәм таянычым. «Совет мәктәбе» журналы — яшь буынга белем бирүгә ачкыч, укыту серләренә төшенүгә чыганак», — ди ул.

Билгеле, бу — укытучының ихлас күнелдән әйткән сүзләре редакция коллективын тагын да тырышыбрак, иҗат ялкынын салып эшләргә рухландыра. Шуның белән бергә, ул зур гына бурычлар да йөкли. Яшь буынны тәрбияләүчеләр журналга шундый тирән ышаныч белән карыйлар икән — аны акларга, заман таләбе югарылыгында атларга кирәк. Журналны укучылар белән төрле очрашулар, конференцияләр әнә шул максаттан чыгып эшләнә. Соңгы елларда редакция хезмәткәрләре Татарстан, Башкортстан мәктәпләрендә, төрле өлкәләрдән Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтына килгән педагоглар белән дистәләрчә очрашулар үткәрделәр. Әлбәттә, аларның берсе дә эзсез югалмый. Журнал укытучыларга якынайганнан-якыная бара. 1961—1968 нче елларда «Совет мәктәбе»нең тиражы 3 мәртәбә артуы һәм хәзер 19 мең данәгә якын тираж белән чыгуы үзе дә күп нәрсә турында сөйли. Бу елларда аның эчтәлеге дә, техник оформлениесе дә тамырдан үзгәрде.

Шулай да кайбер иптәшләр бераз канәгатьсезлек белдерәләр: журнал бик вак хәрефләр белән языла, диләр. Дөрес сүз. Ләкин аның сәбәбе бар. Укытучыларга мәкаләләрне күбрәк бирү өчен шулай эшләнә ул. Чөнки Татарстанда чын-чынлап алдынгы, иҗади эшләүче укытучылар бик күп. Алар тәҗрибәсен редакциянең журнал укучыларга тизрәк һәм күбрәк күләмдә җиткерәсе килә. Икенчедән, бу соңгы елларда күп кенә фәннәр яңа программалар нигезендә укытыла башлады, факультатив занятиеләр кертелде, тәрбия мәсьәләләренә зур урын бирелә. Һәммә яңалыкны да укытучыларга үз вакытында җиткерергә, татар мәктәпләренең үзенчәлекләрен исәә алган, эштә практик ярдәм итәрлек материаллар бирергә кирәк. Ә журналның күләме дүрт кенә табак. Мәкаләләрне вак хәрефләр белән бастыру исәбенә, редакция материалны ике мәртәбә диярлек артыграк урнаштыра.

«Совет мәктәбе» журналының һәр санында башлангыч, сигезьеллык һәм урта мәктәп укытучылары, класс һәм мәктәп җитәкчеләре, гомумән, барлык мәгариф работниклары өчен көндәлек эшләрендә ярдәм булырлык материаллар күп урнаштырыла. Алдынгыларның уңай тәҗрибәсе киң яктыртыла. Журналда шулай ук «Мәктәп һәм семья», «Врач киңәшләре», «Фән һәм тех-

ника яңалыклары», «Планета буйлап» һәм башка бүлекләр бар. «Консультация» бүлегендәге материалларда укытучыларның күп санлы сорауларына җаваплар бирелә.

Соңгы өч-дүрт ел эчендә журнал укытучыларга язучыларыбызны һәм сәнгать эшчеләрен пропагандалау буенча зур эш алып бара. Һәр номерда диярлек тышлыкның икенче битендә татар совет язучыларының, композиторларының, художникларының портретлары, сәнгать эшлеклеләренә багышланган материаллар урнаштырылу әнә шул чараның бер формасы. Ул портретлардан мәктәпләрдә стендлар оештырыла, альбомнар төзелә. Дәрестә һәм класстан тыш эшләрдә аларның нинди зур ярдәм итүен укытучылар бик яхшы беләләр.

Гомумән, «Совет мәктәбе» татар әдәбиятын, татар телен укытуга, болар буенча класстан тыш эшләргә зур әһәмият бирә. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил юбилейларына багышлап, мәсәлән, махсус номерлар чыгарылды. 1967 нче елда Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел тулу көннәрен билгеләп үткәндә, аның киң кырлы эшчәнлегенә багышланган утызга якын мәкалә урнаштырылды. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Әлмәт конференциясендә ясаган чыгышлары да журналда зур урын алды. Журнал системалы рәвештә төрле техник чаралардан һәм программалаштырылган укыту элементларыннан файдаланып үткәрелгән дәрес үрнәкләре бирә. «Безнең календарь» битендә һәр язучының туган көне билгеләп үтелә.

Сүз ахырында шуны әйтәсе килә, «Совет мәктәбе» журналы 50 ел эчендә зур һәм мактаулы юл үтте. Ул — халык мәгарифе өлкәсендә партия программасы куйган бурычларны үтәү өчен татар мәктәпләре укытучыларын туплауда, оештыруда КПСС-ның Татарстан өлкә комитетының һәм ТАССР Мәгариф министрлыгының якын ярдәмчесе. Күп меңләгән укытучылар шуңа күрә дә аны үзләренең якын юлдашлары итеп саныйлар.

КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Министрлар Советының «Гомуми урта белем мәктәпләренең эшен тагын да яхшырту чаралары турында»гы карары яктылыгында (1966 нчы ел, 10 нчы ноябрь) халык мәгарифе өлкәсендә зур һәм җаваплы эшләр алып барыла. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССР оештырылуга 50 ел тулу уңае белән укытучыларга дәрестә һәм класстан тыш эшләрдә файдаланырлык материаллар бирә бару да редакциянең игътибар үзәгендә тора. Бөтенсоюз укытучыларының II, Татарстан укытучыларының IV съездлары күрсәтмәләрен тормышка ашыру эшенә мәгариф эшчеләрен туплау, яңа программалар белән укытуга күчү уңае белән укытучы алдында торган кыен бурычларны үтәүдә ярдәм итәрдәй методик киңәшләр урнаштыру бик әһәмиятле көндәлек ихтыяҗга әйләнде. Юбилей көннәрендә «Совет мәктәбе» редакциясе коллективы үз алдында торган бурычларның зурлыгын аңлый һәм эштә яңадан-яңа биеклекләр билгели.

Ф. ИБРАҺИМОВ,
журналның баш редакторы, Татарстанның атказанган культура работнигы.

Ф. ШӘРИФУЛЛИН,
журналның әдәби сотрудниги.

Б. Әхмәтов

# ХӘЗЕРГЕ ГАРӘП ДӨНЬЯСЫНДА[1]



Җир шарының иң шау-шулы урыннарыннан берсе булган Якын Көнчыгыштагы вакыйгалар берничә ел дәвамында инде дөнья җәмәгатьчелегенең игътибар үзәгендә тора. Анда милли азатлык, прогресс һәм тынычлыкны яклаучы көчләр империализмга, реакциягә һәм сугышка каршы кискен политик көрәш алып баралар.

Соңгы ун-унбиш ел эчендә Якын Көнчыгыштагы конфликтлар әллә ничә тапкыр тынычлыкка реаль куркыныч тудырган җитди халыкара кризисларга әверелделәр. 1956 елдагы Суэц кризисын, 1958 елда көнбатыш державаларның Ливанга һәм Иорданиягә интервенциясен, 1967 елда гарәп илләренә каршы Израиль агрессиясен генә искә төшерик.

Моннан берничә еллар гына элек дөнья политикасында Якын Көнчыгышның роле ике фактор: аның стратегик урыны һәм гаять бай нефть запаслары белән билгеләнә иде. Ә хәзер исә андагы милли-азатлык хәрәкәтенең куәтле күтәрелешен исәпкә алмыйча, Якын Көнчыгыш илләренең дөнья политикасында тоткан урыннарын дөрес итеп күз алдына китерү мөмкин түгел.

Якын Көнчыгышның күп кенә илләре, бигрәк тә бу районның төп өлешен биләгән гарәп илләре, үзләренә азатлык яулап алдылар һәм бу аерым бер фактор, Якын Көнчыгышта политик юнәлешләргә, халыкара мөнәсәбәтләргә, мөһим халыкара проблемаларны хәл итүгә йогынты ясый торган фактор булып әверелде.

Якын Көнчыгыштагы бәйсез илләрнең милли-азатлык хәрәкәтенә һәм политик халәтенә торган саен кискенләшә барган эчке көрәш характерлы. Бу көрәштә ике тенденция калкып чыкты. Беренче тенденция империализмга, феодализмга каршы булган революцияне, халык массалары интересларыннан чыгып, экономик һәм социаль яңарышның төп бурычларын — «Җир — иген игүчеләргә» принцибы нигезендә аграр мәсьәләне, эшче сыйныфының тормыш хәлләрен яхшыртуны, дәүләт аппараты һәм хөкүмәтнең бөтен идарә системасын демократлаштыруны — үстерүгә, ахырына кадәр дәвам иттерүгә юнәлдерелгән. Ә бу тенденция якын арада милли-демократик революциянең Якын Көнчыгыш илләренең социализм юлы буенча үсешенә юл ача.

Мондый үзгәрешләрнең башлап йөрүчеләре — сул прогрессив демократик көчләр. Бу көчләр составына эшчеләр, крестьяннар сыйныфының бер өлеше, прогрессив фикерле милли буржуазия һәм халык массаларының милли-азатлык хәрәкәтен җитәкләгән алдынгы хәрби интеллигенция керә.

Икенче тенденция Якын Көнчыгыштагы бәйсез илләрнең политик үсешен, социаль-экономик һәм политик үзгәрешләрне капиталистик стройны ныгыту нигезендә дәвам иттерергә омтылудан гыйбарәт. Бу юнәлешне реакцион көчләр блогы — эре милли буржуазия (дөрес, алар күп түгел), фео-

[1] «Казан утлары» өчен махсус язылды. *Ред.*

даль-алпавыт элементларының бер өлеше, уң буржуаз-милләтчел даирәләр артыннан иярүче төрле вак буржуаз катламнар (реакцион фикерле офицерлар, чиновниклар, сәүдәгәрләр) алга сөрәләр.

Сыйнфый көрәш бигрәк тә Берләшкән Гарәп Республикасы, Сирия кебек илләрдә киң җәелде. Чөнки бу илләрдә соңгы елларда капиталистик элементларны чикләүгә юнәлдерелгән күп кенә социаль-экономик реформалар тормышка ашырылды. Бу көрәшнең йогынтысы Төркия һәм Иран кебек Якын һәм Урта Көнчыгыш илләрендә дә күренә. Бу илләрдәге экономик һәм социаль кризислар капиталистик үсеш юлының халыкның тормыш хәлен яхшыртуга сәләтсез икәнен ачык күрсәтәләр.

Якын Көнчыгыш илләрендәге эчке политик көрәшне, аларның үсеш юнәлешләрен АКШның, Англиянең, Германия Федератив Республикасының империалистик даирәләре даими күзәтеп торалар, алар һәрвакыт андагы вакыйгаларны кискенләштерергә һәм үз якларына аударырга, шуннан файда күрергә тырышалар.

Милли-азатлык хәрәкәтенең империализмга һәм капитализмга каршы юнәлеше хәзер инде заманыбызның характерлы үзенчәлеге булып әверелде. Политик бәйсезлек яулап алган гарәп халыклары моның ачык мисалы булып тора. Хәзер инде гарәп илләренең бик аз өлешендә генә турыдан-туры колониализм хакимлек итә.

Гарәп җирләренең яртысын диярлек тәшкил иткән Берләшкән Гарәп Республикасы, Сирия, Алжир капиталистик юлны читкә кактылар, социаль үсешнең прогрессив юлына бастылар һәм милли тезелештә шактый зур уңышка ирештеләр. Әйтеп үткәнчә, йөз миллионга якын халыкны тәшкил иткән гарәп илләре мөһим стратегик урынны билә торалар һәм аларда гаять зур нефть ятмалары запасы бар (билгеле булганча, нефть запасы — анда 20 миллиард тонна, бу — капиталистик илләрдә чыга торган нефтьнең 60 %-ы дигән сүз).

Гарәп илләрендәге вакыйгалар империалистларның омтылышларына чын-чынлап куркыныч тудыра. Шул ук вакытта гарәп илләрендәге яшәешләре куркыныч алдында калган феодаль-алпавыт һәм капиталистик элементлар да, берләшеп, революцион хәрәкәтне таркату өчен империалистлардан ярдәм көтәләр. Максатларына ирешү өчен алар һәртөрле алымнардан файдаланалар, яшертен рәвештә дә, ачыктан-ачык та эш йөртәләр, экономик яктан да, политик яктан да, дипломатик рәвештә дә басым ясыйлар, ислам динен һәм коммунизмга каршы пропаганданы астыртын омтылышларын гамәлгә ашыру өчен корал итәләр.

Багдад пакты, 1956 елда Мисырга агрессия, Эйзенхауэр доктринасы, 1958 елда Иордания һәм Ливанга Англо-Америка гаскәрләренең бәреп керүе, Американың алтынчы флотының Урта диңгезгә керүе, Сирия һәм Берләшкән Гарәп Республикасында прогрессив режимны бәреп төшерергә тырышулар — барысы да империалистик державаларның гарәп халыкларындагы прогрессив үсешне туктату, үзләренең нефть монополиясе интересларын тәэмин итү, югалткан позицияләрен кайтару өчен башкарыла торган заговорлар һәм агрессия актлары системасындагы бердәм чылбыр булып торалар. Хәзерге вакытта Сәгуд Гарәбстаны ярдәмендә империалистлар Ямән Гарәп республикасының эчке эшләренә коралллы рәвештә тыкшынырга маташалар. Ләкин, газеталардан күренгәнчә, аларның бу тыкшынулары бер-бер артлы җиңелүгә дучар итеlә.

АКШ, Англия, Көнбатыш Германия империалистларының гарәп илләренә каршы юнәлдерелгән планнарында хәрби плацдармга әверелдерелгән Израиль зур урын тота. Израиль, империалистик державалар белән һәръяклап бәйләнешкә кереп, Якын һәм Урта Көнчыгышта киеренкелекнең үзәге булып әверелде.

Империалистлар шулай ук Сәгуд Гарәбстанының, Марокконың, Иорданиянең һ. б. илләрнең реакцион режимнарына зур өмет баглыйлар. «Ислам пакты» ярдәмендә алар Көнчыгыштагы прогрессив көчләрне буарга омтылалар.

Гарәп илләрендә киң таралган реакцион ислам бердәмлеге идеяләрен империалистлар үз максатларын тормышка ашыру өчен файдаланалар. Сәгуд Гарәбстаны короле Фәйсал башка гарәп һәм мөселман илләрендәге политиклар белән элемтә урнаштырырга тырыша, бу идеяләрне гамәлгә ашырырга тырышучыларның хезмәтчесе ролен үти.

1965 елның декабрендә Фәйсалның Ирандагы визиты вакытында ике монарх — Сәгуд Гарәбстаны короле һәм Иран шаһы — мөселман дәүләтләре башлыкларының бөтен дөнья конференциясен җыярга килештеләр [1]. Шул максат белән Фәй-

[1] «Әл-Хәйят», Бейрут 3/II, 1966.

сал Кувайт, Судан, Иордания һәм Пакистан илләренә дә барды.

Озакламый алар тәкъдим итә торган бу союзның «Бөек Сурия», «Багдад пакты» һәм башка шундый империалистик пактлардан бик аз аерылып торуы күренде.

«Әл-Әхрам» газетасының баш редакторы Хейкал язганча, «Ислам пакты»н төзү планнары Вашингтонда 1952 елда ук тикшерелгән. Ул вакытта Пентагонда хәрби ярдәм мәсьәләләре буенча директор постын башкарган Америка генералы Олметид, — дип яза Хейкал,— «Ислам пакты»ның Төркия, Пакистан, Мисыр кебек илләргә таянырга тиешлеген әйтте. Бу пакт, диде Америка генералы, коммунизм өчен киртә булып кына калмаячак, хәтта Кытайдагы һәм Советлар Союзындагы миллионнарча мөселманнарны үзенә тарта торган көч булып әверелачак [1].

Соңыннан «Ислам пакты»н төзү идеясенә беркадәр үзгәртүләр кертелде. Сүәеш кампаниясеннән соң бу теркемгә Сәгуд Гарәбстанын да кертү хал ителде. 1957 елда король Сагуд, Вашингтонга ясаган визиты вакытында, Джон Ф. Даллес белән берлектә проект төзеде [2]. АКШ президенты Эйзенхауэр Сагудка «Ислам пакты»ның башлыгы булырга тәкъдим итте. Бу планнар 1964 елда Мәккә шәһәрендә Ислам лигасы сессиясендә тикшерелде [3]. Мөселман дөньясының реакцион көчләре тарафыннан чыгарылган бу җыелыш «ислам бердәмлеге» девизы астында үтте, һәм ул, асылда, прогрессив-социаль экономик үсеш юлына баскан гарәп илләренә каршы походка чакыру өчен җыйналды.

Гарәп илләре арасындагы иң артта калган, үзенең реакционлыгы, халкының дини фанатизмы һәм гарәпләрдәге һәр прогрессив идеяләргә, үзгәртеп коруларга дошманлыгы белән аерылып торган Сагуд Гарәбстанының феодаль монархиясе бу хәрәкәтне оештыруны юкка гына башлап йөрүче түгел. «Ислам пакты» инициаторлары аңа тагын Иранны, Әфганстанны, Ливияне, Иракны, Нигерияне, Бахрейн һәм Персия култыгындагы нефтькә бай башка князьлекләрне, шулай ук Индонезия һәм Малайзияне тартырга уйлыйлар [4].

Прогрессив гарәп матбугаты «Ислам пакты»ның чын политик һәм хәрби максатларын даими фаш итеп килә. Каһирәдә чыга торган атналык «Роз әл-Юсеф» газетасы «Ислам пакты»н төзү идеясенең агрессив СЕНТО блогындагы кризис нәтиҗәсендә барлык килүен әйтеп язды. Бу яңа пактның төп максаты: өстенлек алган прогрессив хәрәкәткә, Көнчыгыш Африка илләренә Советлар Союзы һәм социалистик илләрнең үскәннән-үсә барган йогынтысына каршы көрәшү [1].

Алжирда чыга торган «Әл-Мөҗәһид» газетасы болай дип язды: «Ислам пакты» дип исемләнә торган блокның проекты гарәп илләре лигасына каршы юнәлдерелгән «Багдад пакты»ның яңа бер төре булып тора» (12/II, 1966 ел).

Ливан газетасы «Әл-Җарида»: «Берләшкән Гарәп Республикасындагы, Сириядәге, Алжирдагы революцион социалистик тенденцияләргә каршы фронт булырмы ул, — дип язды, — яисә «коммунистик куркыныч»ка каршы көрәшү фронтына әверелерме, шулай да яңа заговорның гомуми юнәлеше инде ачык билгеле: Гарәп Көнчыгышын алар таркатырга, ә аннан соң гарәп илләре эчендә бер-берсенә дошман группировкалар оештырырга тырышалар» (Бейрут, 15/III, 1966 ел).

Мөселман илләре халыкларының бу панисламистик союзга гаять тискәре мөнәсәбәтләрен истә тотып, аның инициаторлары үзләренең хәрәкәтләрен, ниятләрен яшертен башкаралар.

Король Фәйсал үзенең речьләрендә башлыча «Мөселман илләренең үзара туганнарча бәйләнеше» турында авыз суы корыта, янәсе, империалистлар, сионистлар һәм коммунистлар гына аның тәкъдимнәренә каршы оппозициядә тора.

«Гарәп реакциясе, — дип язды «Әл-Әхрам» газетасында (24/II, 1966 ел) Берләшкән Гарәп Республикасы президенты Гамал Габдел Насыйр, «Ислам пакты»н фаш итеп, — халыкны, аның хезмәт җимешләрен талау, аңа карата үзенең йогынтысын яңарту максатын тотып, ислам диненнән корал итеп файдалану өчен яңа идеяләр эзләп, үзен империалистлар белән бәйли. Империалистлар да шулай ук ислам дине ярдәмендә гарәп илләренә үзләренең йогынтысын яңартырга һәм шул юл белән гарәп дөньясындагы азатлык хәрәкәтенә чик куярга исәп тоталар. Кайбер кешеләрнең: «Ислам пакты»ның нәрсәсе начар, ни өчен без аның белән хезмәттәшлек итүдән

[1] «Әл-Әхрам», Каһирә, 4/II, 1966.
[2] «Әл-Маса», Каһирә, 20/III, 1966.
[3] «Әл-Әхрам», Каһирә, 4/III, 1966.
[4] «Роз әл-Юсеф», Каһирә, 24/I, 1966.

[1] «Роз әл-Юсеф», Каһирә, 24/I, 1966.

баш тартабыз?» — дип сораулары мөмкин. Иң элек мондый хезмәттәшлек... Америка һәм Британия политикасы файдасына булмаска тиеш...

«Ислам пакты» — азатлык хәрәкатенә һәм социаль прогресска юнәлдерелгән империалистик пакт. «Ислам пакты» гарәп халыкларын нефтьбатыш йогынтысы зонасына тартырга исәпләнгән, ул — гарәп илләренә каршы заговор. «Ислам пакты» — берләшүгә дошман политика алып бара торган, барлык мөселман халыкларына каршы юнәлдерелгән заговор. Ул — гарәп дөньясында прогрессив гарәп революцияләре дулкынын туктату өчен империализм белән хезмәттәшлек итүче барлык реакцион көчләрнең берләшмәсе.

Без биредә, Берләшкән Гарәп Республикасында, динне һәм ислам исемен империализм һәм реакция максатларын тормышка ашыру өчен файдалануга каршы чыгабыз. Без «Ислам пакты»на һәм ислам конференциясенә, элек «Багдад пакты»на, Эйзенхауэр доктринасына һәм империалистларның барлык башка маневрларына каршы чыккан кебек үк, каршы чыгабыз».

Планлаштырыла торган «Ислам пакты»-ның идеологик базасы булып мөселманнарның дини асылы концепциясе, «Мөселман туганнар» оешмасы пропагандалый торган гарәп милләтенең аерымлыгы идеясе хезмәт итә. Бу оешма 1928 елда Шәех әл-Бонна җитәкчелек иткән реакцион мөселман руханилары тарафыннан Мисырда төзелә. 1932 елда ул, үзенең программасын игълан итеп, Мисырда актив рәвештә үзенең җимерү эшен җәелдерә, ә аннары Сүриядә, Сәгуд Гарәбстанында, Иранта, Иорданиядә һәм башка гарәп илләрендә үзенең филиалларын булдыра.

«Мөселман туганнар» оешмасына катнашучылар, политик власть яулап алырга омтылып, коммунизмга һәм демократиягә каршы көрәшне үзләренең төп максаты итеп куялар һәм ислам динен барлык халыклар һәм һәр заман өчен яраклы социаль институт итеп танытырга тырышалар. «Мөселман туганнар» корьәнне конституция, ә үзләрен бердәнбер политик оешма итеп белдерәләр һәм Мисырда, башка гарәп илләрендә яшәп килә торган барлык политик партияләрне, эшчеләр профсоюзларын, демократик оешмаларны таратуны таләп итәләр.

Оешманың башлыгы Хәсән әл-Бонна үзенең речьләрендә гарәпләрне, янәсе, кешелек дөньясын яңартырга һәм бөтен дөньяга хакимлек итәргә чакырылган «аллаиың сөекле милләте» дип белдерә.

Реакцион руханилар, халык массаларының дини фанатизмыннан файдаланып, бу оешма белән алпавытлар һәм капиталистлар диктатурасын ныгытырга тырышалар.

1952 елгы революция җиңеп чыкканнан соң, «Мөселман туганнар» оешмасы Мисырда тыелды. Халык массалары арасында үзенә таяныч таба алмаган бу оешманың вак буржуаз җитәкчеләре асылда чит ил империалистик разведкаларының агентлары булып әверелделәр. Яшертен рәвештә террористик эшчәнлекләре һәм республика режимына каршы юнәлдерелгән шпионаж өчен «Мөселман туганнар» оешмасы 1954 елда таркатылды һәм законнан тыш дип игълан ителде.

Шулай булса да «Мөселман туганнар»-ның калдыклары әлегә кадәр яшәп киләләр. Алар гарәп илләрендәге прогресска комачауларга телиләр. Дини фанатизм белән алдап, алар үтерүче, корткыч бандалар оештыралар. Алар берничә мәртәбәләр инде Берләшкән Гарәп Республикасының дәүләт һәм иҗтимагый строена һөҗүм ясарга маташалар.

Гарәп илләрендәге матбугат хәбәр иткәнчә, «Мөселман туганнар» оешмасы 1967 елның җәендә, Израильнең империалистик агрессиясе вакытында, Берләшкән Гарәп Республикасына тылдан удар ясау өчен, үзенең җимерү эшчәнлеген активлаштыра [1].

«Ислам пакты» планын күтәреп чыгу, Берләшкән Гарәп Республикасында реакцион-дини «Мөселман туганнар» оешмасының хөкүмәткә каршы заговорлары, 1967 елда Израильнең империалистик агрессиясе — барысы да бер агачның җимешләре: империализм, реакцион милләтчелек һәм антикоммунизм колониализмга каршы көрәшүче Азия-Африка халыклары белән социалистик илләр арасында упкын тудырырга телиләр.

Израильнең гарәп илләренә агрессиясе халыкара хәлнең җитди рәвештә кискенләшүенә китерде, Җир шарында тынычлык эшенә зур куркыныч тудырды.

Империалистлар, Израильне гарәп халыкларының милли һәм социаль азатлык хәрәкәтенә каршы жандарм итеп файдаланырга исәп тотып, бу илдә хәрбилаштерелгән дәүләт, агрессия базасы булдырдылар. 1967 елның июнь аенда Израильнең

[1] «Әл-Әхрам», Каһирә, 15/IX, 1967 ел.

гарәп илләренә басып керүе — империалистлар һәм сионистлар даирәләре аңлатырга тырышканча, гарәплар белән еврейләр, гарәп илләре белән Израиль дошманлыгының нәтиҗәсе генә түгел иде. Израильнең бу һөҗүме озак вакытлар дәвамында әзерләнде. Ул әзерлек, Суэцш авантюрасы тар-мар ителгәч тә, 1956 елда ук башланды.

Шунысы гаять мөһим факт: Суэцш кризисыннан соң социалистик илләрнең, бигрәк тә СССРның Якын Көнчыгышта халыкара абруе гаять үсте, прогрессив гарәп илләре белән аларның бәйләнеше һәм хезмәттәшлеге тагы да ныгыды. Якын Көнчыгышта Суэцш кризисыннан соң үткән вакыт зур политик һәм халыкара әһәмияте булган вакыйгалар белән характерлана: 1958 елда король Фәйсалның һәм Иракта Нури Сәетнең халыкка дошман, реакцион режимнары бәреп төшерелде. Берләшкән Гарәп Республикасы яңа үсеш юлына аяк басты һәм 1961 елда инде мөһим социаль-экономик үзгәртеп кору эшләренә керешә. Яманда 1962 елда халык революциясе җиңеп чыкты, 1966 елда Сириядә власть башына прогрессив хөкүмәт килде. Болар барысы да Гарәп Көнчыгышының политик йөзен тамырдан үзгәртте.

Әйтеп үтелгәнчә, нәкъ менә шуңа күрә дә инде Америка Кушма Штатлары, Англия һәм Германия Федератив Республикасының империалистик даирәләре тарафыннан рухландырылган Израиль экстремистлары 1967 елда Берләшкән Гарәп Республикасы, Сирия һәм Иорданиягә каршы сугыш башлап җибәрделәр дә.

Билгеле булганча, агрессорлар һәм аларны рухландыручылар Советлар Союзы һәм башка социалистик илләр, бөтендөнья прогрессив көчләре ягыннан халиткеч каршылыкка очрадылар. Империализмның төп максаты — прогрессив гарәп илләрендәге режимны бәреп төшерү, гарәп дөньясын бүлгәләү — барып чыкмады.

«Якын Көнчыгыштагы хәлләр турында Совет хөкүмәтенең белдерүе»ндә: «Халыклар Якын Көнчыгышта хәрби конфликт кабызуны теләмиләр, — диелгән иде. — Бу конфликт белән колониаль нефть монополияләре һәм аларның иярченнәре генә кызыксынырга мөмкин. Аның белән бары тик политикаларының фарватерында Израиль бара торган империализм көчләре генә кызыксынырга мөмкин» [1].

Аннан соңгы вакыйгалар Израиль агрессиясенә карата Совет хөкүмәтенең бу бәясен тулысынча раслады.

Империалистик державаларның җитәкче даирәләре Израильне гарәп дөньясының прогрессив көчләренә каршы көрәш өчен күптән инде трамплин итеп файдаланалар. Асылда бу агрессия 1967 елда түгел, моннан егерме еллар элек үк башланды. 1948 елда Израиль, Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясы карарына буйсынмыйча, Акаба култыгының Мисыр ягындагы ярын басып алды. Шушы егерме ел эчендә үткән тарих АКШ, Англия һәм ФРГ империалистларының Израильне коралландыру өчен бер дә саранланып тормаганлыкларын бик ачык күрсәтә.

АКШ матбугатында әйтелгән хәбәрләр буенча, 1948 елдан 1965 елга кадәр Израильнең җитәкче даирәләре үзләренең Америкадагы хуҗаларыннан заем формасында 226 миллион доллар, ярдәм формасында 278 миллион доллар, 320 миллион долларлык азык-төлек һәм экспорт-импорт банкысыннан кредит сыйфатында 221 миллион доллар күләмендә хәер алганнар [1].

Шулай ук Германия Федератив Республикасы да Израильгә зур гына ярдәм бирде һәм бирә килә. 1952 елда Израильнең чит ил эшләре министры Люксембургта Көнбатыш Германия реваншистлары белән килешүгә кул куйды. Бу килешү шушы ике агрессив ил арасында актив хезмәттәшлекнең нигезе булды һәм шул килешү буенча Израиль армиясен коралландыру өчен Көнбатыш Германия 660 миллион марка акча түләтты [2].

Израильнең буржуаз газеталарында язылганча, 1967 елда Кизингер-Брандт хөкүмәте Эшкол хөкүмәте белән якындагы ун ел эчендә ике миллиард марка (Көнбатыш Германия маркасы) күләмендә Израильгә ярдәм күрсәтү турында сөйләшүләр алып барды.

Израильнең җитәкче даирәләре Көнбатыш державаларыннан 19 ел эчендә 8 миллиард доллар күләмендә ярдәм һәм кредит алуларын үзләре дә яшереп тормыйлар.

Шулай итеп, империалистик державалар чагыштырмача кыска вакыт эчендә экономик яктан артта калган районда үзләренең Якын Көнчыгыштагы политикасын үткәрә

[1] «Правда», 3/VI, 1967 ел.

[1] «Роз әл-Юсеф», Каһирә, 27/IX, 1967 ел.
[2] Шунда ук.

торган хәзерге заман капиталистик дәүләте булдыруга ирештеләр. Израильнең гарәп илләренә булган агрессиясен алдан ук АКШ, Англия белән килешеп, аларның хәрби, материаль һәм дипломатик ярдәменә исәп тотып башкаруында һич тә шик юк. Империалистик державаларның ярдәменнән башка Израильнең бу агрессияне башларга һич тә кыюлыгы җитмәс иде.

Бу агрессия АКШның һәм Англиянең Якын Көнчыгыштагы киң стратегик планының бер өлеше булып тора. КПСС Үзәк Комитетының Генераль секретаре Л. И. Брежнев: «Империалистик пропаганданың бу агрессияне, янәсе, Израиль белән гарәп илләре арасында милли дошманлык нәтиҗәсе дип күрсәтергә тырышулары аның чын сәбәпләрен, вакыйгаларның сыйнфый асылын яшерүгә юнәлдерелгән. Якын Көнчыгыштагы кризисның асылы империализм көчләре белән милли бәйсезлек, демократия һәм социалистик прогресс көчләре арасындагы каршылыктан гыйбарәт», — дип бик дөрес күрсәтте[1].

Колониализм көчләре һәм алар артында торган эре нефть монополияләре Якын Көнчыгыштагы байлыкларның киләчәктәге үсеш юлларын үзләре билгеләүче гарәпләр кулына күчүләре белән килешергә теләмәделәр. Империализмның тышкы политикасы планнарында Израиль күптәннән инде гарәп халыклары арасындагы милли-азатлык хәрәкәтен бастыру, АКШ, Англия һәм алар белән тыгыз бәйләнештәге Көнбатыш Германия реваншистларының нефть монополияләре интересларын гамәлгә ашыру коралы итеп карала. Империалистик державаларның Израиль ярдәмендә нефтькә бай Якын, Урта Көнчыгыш районнарында хәзерге көндә дә эле хакимлек итү өметләреннән ваз кичкәннәре юк.

1967 елның мартында Багдад шәһәрендә нефть мәсьәләләре буенча гарәп илләренең VI конгрессы була. Анда чит ил компанияләре өстеннән техник һәм экономик контрольне көчәйтү кирәклеген әйтеп, милли нефть компанияләренә һәм предприятиеләренә ярдәм итәргә тәкъдим ясалды[2].

Якын Көнчыгышта һәм Төньяк Африкада нефтьнең гаять зур ятмалары бар. Соңгы ун ел эчендә табылган нефть запасы 15,6 млрд. тоннадан 29,8 млрд. тоннага кадәр, ягъни 91% ка үсте. Җ дөньяның башка районнарында бу үсеш тик 52% кына булды.

Гарәпләр Көнчыгышында нефть чыгаруның күләме дә үсте. Әгәр ул 1946 елда 16 млн. тонна тәшкил итсә, 1966 елда исә 470 млн. тоннага җитте. Соңгы ун ел эчендә гарәп нефтен читкә чыгару 3,2 тапкыр үсте...

Бу саннар АКШ, Англия, Көнбатыш Германия империалистларының Израиль экстремистларын ни өчен шулай коралландыруларын, Израиль белән гарәп илләре арасында дошманлыкны үстерергә тырышуларын ачык күрсәтәләр.

Эш бер нефтьтә генә түгел. Икенче яктан, Якын Көнчыгыш Көнбатыш илләрен Көнчыгыш Африка, Азия, Австралия һәм Океания илләре белән тоташтыра торган зур диңгез һәм һава юллары өстендә. Суэц каналы дөнья күләмендә гаять зур әһәмияткә ия булган транспорт артериясе булып тора. Менә шуңа күрә дә империалистик державалар кайбер гарәп илләре территориясендә хәрби-диңгез һәм хәрби-һава базалары тотуларын дәвам итәләр. Англия Кипр утравында стратегик авиациянең ике терәк пунктын тота. Бәхрәйн утравы районында, Англия хәрби-диңгез флотыннан тыш, Америка хәрби корабльләренең махсус отряды тора. Дәхрандагы база, формаль рәвештә Сәгуд Гарәбстанына тапшырылган булуына карамастан, чынбарлыкта исә һаман да АКШ кулында һәм аңа хәрби авиация базасы булып хезмәт итә.

Тагын шуны да әйтергә кирәк: хәзерге вакытта империалистлар Якын Көнчыгышны хәтта Советлар Союзына һөҗүм итү өчен уңайлы урын дип тә карыйлар. АКШ һәм башка Көнбатыш державалары күзлегеннән караганда, гарәп илләрендәге антиимпериалистик хәрәкәт нефть монополияләренә генә түгел, ә Советлар Союзына каршы аларның тоталь стратегик планнарына да куркыныч тудыра.

Империалистик державаларның Якын Көнчыгыштагы тышкы политикаларын характерлый торган үзенчәлекләр әнә шундый.

Империалистлар агрессиянең төп максатына ирешә алмадылар. Берләшкән Гарәп Республикасында һәм Сүриядә прогрессив режим сакланып калды. Аларны үз халыклары гына түгел, башка гарәп илләрендәге халык массалары да яклый. Гарәп шәһәрләрендә миллионлаган кешеләр, Гамәл Габдел Насыйрга һәм ул алып бара

[1] «Правда», 6/VII, 1967 ел.
[2] «Дөнья экономикасы һәм халыкара мөнәсәбәтләр» (рус телендә), 1967 ел, № 9.

торган революцион курска ышаныч белдереп, урамнарга демонстрациягә чыкканда бу яклау тагы да ачыграк булып күренде. Шуны да әйтергә кирәк, Советлар Союзының һәм башка социалистик илләрнең политик инициативасы, бик тиз күргән җитди чаралары нәтиҗәсендә Израиль гаскәрләре гарәп илләре җирләренә басып керүне туктатырга, атышларны туктату турында Куркынычсызлык Советы карарларына буйсынырга мәҗбүр булдылар. Шулай да һаман әле Якын Көнчыгыштагы хәлләр киеренке. Мөселман дәүләтләренең реакцион союзын оештырырга маташулар дәвам итә.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясының ике резолюциясе булуга карамастан, гарәп җирләрен оккупацияләүне дәвам итү, Израиль контрольлеге астында курчак гарәп дәүләте төзергә һәм шул юл белән Палестина мәсьәләсен хәл итәргә тырышу — болар Көнбатыш державаларның тактикаларына тулысынча туры килә. Империализм Израиль агрессиясен гарәп илләренә басым ясауны көчәйтүдә файдаланырга исәп тота.

Күптән түгел генә Израильнең премьер-министры Леви Эшкол һәм «оборона» министры Моше Даян гарәп илләренә каршы яңа сугышка әзерләнергә чакырып чыгыш ясадылар. Оккупацияләнгән районнарны 1967 елның маена кадәр булган хәлгә кайтаруга, янәсе, Израиль хөкүмәте һич тә ирек куя алмый. Чынлыкта бу — басып алынган гарәп җирләрен азат итүгә каршы чыгу. Алай гына да түгел, Израильнең «оборона» министры М. Даян: «Без корал сатып алырга тиешбез, без үзебездә корал җитештерергә тиешбез, без үз армиябезне ныгытырга тиешбез, без үз аэродромнарыбызны әзерләргә тиешбез[1],— дип авыз суы корыта. Израильнең җитәкче даирәләре, империалистик Көнбатыш державалардагы хуҗаларының теләкләрен үтәп, Якын Көнчыгыш конфликтында экстремистик позицияләрендә торуларын дәвам итәләр, әмма бу районда яңа сугыш уты кабызуга кадәр җиткерергә тырышалар.

Хәзер гарәп илләре алдында торган бурычлар: Израиль басып алган җирләрне кире кайтару, агрессиянең һәр актына каршы отпор бирү һәм сугыш нәтиҗәсендә туган кыенлыкларны бетерү.

Җир шарының бу өлешендә империалистларга максатларына ирешергә мөмкинлек бирмәс өчен, бу бурычларны хәл итү бер гарәп халыклары алдында гына түгел, ә барлык тынычлык сөюче илләр һәм халыклар алдында җитди проблема булып тора.

Гарәп илләренең җиңеп чыгуы, иң элек, алардагы революцион һәм прогрессив көчләрнең бердәмлеге, империализмга каршы әзлекле көрәш алып барулары, тынычлык һәм халыкларның үзара якынаюы өчен көрәшүче дөньядагы барлык прогрессив көчләр белән бердәм булуларына бәйле.

---

[1] «Известия», № 150, 29 июнь, 1968 ел.

Б ◇ Б

# Гарәп укымышлылары Советлар Союзы турында

Россиядә 1917 елның октябрендә булган революция, һичшиксез, моңа кадәр билгеле булган революцияләрнең иң зурысы. Ул кешелек җәмгыятенең хаятын, фикерен, юнәлешен тамырыннан үзгәртте. Туктаусыз үсеп, яңарып, үзгәреп торган дөнья барлыкка килде. Кешелек җәмгыятенең үсеше, иреге, күркәмлеге өчен көрәш мәйданы ачылды. Октябрь социалистик революциясе яңа кешелек җәмгыятенең нигезен корды. Халык наданлык, фәкыйрьлек, золым, хорафат богауларыннан котылды...

Марксизм-ленинизм тәгълиматы хәрәкәтсез теория түгел, туктаусыз үсеп, яңарып торган теория ул. Үсешнең чиге юк.

Ниһаять, географик, тарихи үзгәрешләр нигезендә җәмгыять тә үзгәрә, яңара...

Ләкин шунысы ачык: марксизм-ленинизм кешене кеше эксплуатацияләүгә кискен рәвештә чик куйды. Империализмның ерткыч йөзен үзенең кызыл нуры белән мәңгегә фаш итте.

ОСТАЗ МӨХӘММӘД-ЭН-НӘККАШ

«Әл-Әхбар» 5/XI, 1967. Бейрут.

Мин Мәскәүгә килеп җитү белән, яңа дөньяны өйрәнә башладым. Биредә барлык нәрсә яңа, хәтта кешеләр дә яңа. Аларның бөтен омтылышлары, теләкләре — уку, фәнне үзләштерү. Моның өчен аларга бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Советлар Союзында халык ирекле, тулы хокуклы. Алар вакытларын бушка үткәрмиләр. Үзләренең көче, белеме нисбәтендә халыкка хезмәт итәләр. Гаять дәрәҗәдә тәртипле халык.

Кеннәр бик тиз үтә. Мин дә яңа дөнья белән танышуымны дәвам итәм. Һичбер тарлык, тоткарлык, кыенлык күрмим. Хатын-кызлар белән дә очраштым. Алар сорауларыма ачык җавап бирәләр, кимчелекләрне дә яшермиләр. Аларның тавыш тибрәнүләрен ихлас күңел белән тыңлыйсың...

ЭМИЛИ НАСРУЛЛА.

«Әл- Әхбар», 5/IX, 1967, Бейрут.

Октябрь социалистик революциясенең 50 еллык юбилей бәйрәме Советлар Союзы халкының гына бәйрәме түгел, бәлки бөтен алдынгы кешелек җәмгыятенең, шул исәптән Ливан халкының да тантанасы ул. Шул уңай белән без Совет халкына чын дуслык һәм соклануыбызны белдерәбез.

Советлар Союзының Ливанга, гомумән, гарәп илләренә күрсәткән игелекләрен санап бетерергә мөмкин түгел. Безнең бик күп яшьләребез СССРның югары уку йортларында физика, математика, химия, медицина, агрономия һ. б. фәннәр буенча белем алалар. Укыган өчен түләү алынмый.

Мин Советлар иле белән кыска вакыт эчендә генә түгел, ун еллар буена таныштым. Советлар Союзы — фән-культура алдынгылыгы, халыкара тынычлык өчен көрәш нәтиҗәсендә яңа ачылган горизонт. Социалистик тәртип-система нигезендә яңа кешелекнең барлыкка килүе ул.

Советлар Союзында медицина ике мөһим бүлектән тора: беренчедән, медицина буенча ярдәм түләүсез башкарыла; икенчедән, гаять бай, тирән тәҗрибәгә ия, профилактик әһәмияте зур.

Хәзерге көндә Советлар Союзында ярты млн. табиб, ике млн. га якын медицина хезмәткәрләре бар.

Совет медицина өлкәсендәге бу зур казанышлар, һичшиксез, социалистик системаның уңышыннан, Совет халкының ерактан күрә белү сәләтеннән килә.

СБИРУ ФАХУРИ,
медицина докторы.

Мөхәммәт Мәһдиев

# ХАЛЫК ӘДӘБИЯТЫБЫЗГА БЕР КАРАШ

Татар халык иҗатының барлык жанрларын колачлаган теоретик хезмәтнең юклыгы үзен күптән сиздерә иде. Бу бигрәк тә югары уку йортларындагы тел, әдәбият бүлеге студентлары, галимнәре арасында күзгә ташлана иде. Дөрес, халык әдәбияты буенча соңгы ун ел эчендә шактый зур хезмәтләр дөньяга чыкты. Татар халык җырлары, әкиятләре, бәетләре, мәзәкләре һәм мәкальләре буенча соңгы вакытта бер-бер артлы китаплар чыга торды. Арада иң күләмлесе һәм теоретик яктан иң фундаменталь булганы, әлбәттә, Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» дигән өч томлык хезмәте. Болары билгеле хезмәтләр. Алар хакында тәнкыйть сүзе әйтелде инде.

Безнең сүзебез гомумән татар халык иҗаты буенча теоретик бер бөтен хезмәт турында иде һәм хәзер әнә шул хезмәтнең үзенә тукталып карыйк. Бу — күренекле фольклорист, филология фәннәре кандидаты Хәмит Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» дигән китабы. Ул китап 1967 елның ахырында гына дөньяга чыкты һәм җәмәгатьчелек алдында инде билгеле бер бәяне алырга да өлгерде.

* * *

Хәмит Ярми,— утызынчы елларның ахырыннан алып бүгенге көнгә кадәр татар халык иҗатын җыю, эшкәртү буенча зур хезмәт күрсәткән галим. Татар халык әкиятләрен, җырларын, бәетләрен туплаган күп китапларны күрүебез белән без нәкъ менә Х. Ярмигә бурычлы. Халык иҗатына булган самими мәхәббәте белән ул дистәләрчә еллар инде татар фольклорын туплау, эшкәртү мәктәбенең башында тора. Аның кул астында эшләгән кешеләр инде үзләре галимнәргә әйләнделәр, ел саен аларның аерым тикшеренүләре дөньяга чыгып тора. Фольклор буенча күп санлы хезмәтләр биргән өлкән галимнең бу соңгы китабы, бәлки, аның фәнни карашларының сыгынтысыдыр һәм халык иҗаты турындагы өзек-өзек фикерләребезнең галим тарафыннан системага салынган бер җыелмасыдыр дигән өмет белән китапның беренче битен ачабыз.

Татар халык иҗатын җыю һәм эшкәртү мәсьәләсе инде күптәннән көн тәртибенә куелган иде. Һәм бу уңайдан Х. Ярминең үз элгәрләренә мөнәсәбәтен күзәтү кызыксыз булмас. Мәгълүм булганча, фольклор тарихына тукталучы һәрбер галим беренче чиратта Каюм Насыйри исемен телгә ала. Безнең кулыбыздагы китапта да бу шулай. Авторның бик хаклы рәвештә билгеләвенчә, К. Насыйри халык иҗатының иң демократик өлешен, бары тик реалистик нигезгә корылган иҗат әсәрләрен генә җыйган. Гади хезмәт халкына булган симпатиясе К. Насыйриның фәнни эшчәнлегендә төп юнәлешне билгеләгән. Әнә шуңа күрә ул җыйнаган фольклор материаллары арасында дини эчтәлекле мөнәҗәтләр, реакцион рух белән сугарылган әсәрләр очрамый диярлек.

Татар халык иҗатының күп жанрлары тупланган беренче антология «Кырык бакча» исеме белән 1880 елда К. Насыйри тарафыннан чыгарылган иде. Х. Ярми бу китапның тарихи әһәмиятен дөрес билгели. «Кырык бакча» татар халык иҗатын гыйльми нигезгә салып карарга омтылуда беренче адым булып исәпләнергә тиеш.

К. Насыйри турында без күп язабыз, күп урыннарда аның китапларын телгә алабыз. Әйе, Казан университеты каршындагы тарих, этнография, археология җәмгыятенең членнары — бөтен Европага танылган профессорлар арасында татарның кырпу бүрекле демократ Каюмы да йөргән һәм ул бу танылган галимнәр сокланырлык гыйльми материал туплаган икән, шул заман шартлары өчен моны героизм дип атарга кирәктер. К. Насыйриның замандашы проф. Григорьевның: «Татарларны шактый әйбәт белә торып та, алар арасыннан мондый кеше килеп чыгуын башыма да китермәгән идем», дип әйтүе, әлбәттә, очраклы хәл түгел иде. К. Насыйри — үз заманының күпкырлы эшчәнлек алып барган алдынгы кешесе иде һәм аның к ү п к ы р л ы эшчәнлеген Х. Ярми билгеләгәнчә өч юнәлеш белән генә чикләү, ихтимал, дөрес үк тә түгелдер. Бигрәк тә авторның «икенче юнәлеш» дигәне (30 бит) К. Насыйри эшчәнлегенең үзенчәлеген тарайта. К. Насыйри, ди анда автор, «үз халкының ан-белемен күтәрү өчен культура ягыннан алда торган халыклардан үрнәк алуны мөһим бер чара дип тапты». Гомумән татар мәгърифәтчеләре өчен хас бу сыйфатны К. Насыйри эшчәнлегендәге төп юнәлеш итеп билгеләү, ничектер, хезмәтнең темасы белән дә, мәсьәләнең куелышы белән дә туры килеп бетми. К. Насыйри календарьларындагы халык сынамышлары турында да нинди дер ачык булмаган фикер уздырыла. Анда автор турыдан-туры: «1875 елгы календарьда... халык тәҗрибәләре матур рифмага салынып бирелә» (32 бит), дип яза. Мәгълүм булганча, К. Насыйри халык әсәрләрен җыючы һәм пропагандалаучы — ләкин һич тә үзлегеннән рифмага салучы түгел. «Март башы аяз — аяз килер бөтен яз» дигән халык тәҗрибәсе календарьга төшерелгән икән, бу тәҗрибәне инде гасырлар буена рифмалаштыручы кеше — халык булган, ләкин һич тә К. Насыйри түгел. «Эшләнеп бетмәгән җырлар» турындагы тезис та (35 бит) безне бераз шиккә төшерде. Безнең фикеребезчә, халыкның борынгы җырларыннан нәкъ менә эшләнеп беткәннәре генә сакланганнар, ә эшләнеп бетмәгәннәре онытыла барганнар. Һәм К. Насыйри:

Кашларың нечкә бик әйләнгән,
Казанда бөккән дугадай,—

дигән җырга тукталган икән, бу әле җырның эшләнеп бетмәве дигән сүз түгел. Җыр эшләнеп беткән һәм шуңа күрә ул халык хәтерендә сакланган. Халык гүзәл кызның кашын ат дугасына ошатмый, ә кашның ни дәрәҗәдә бөгелгәнлеге турында сүз алып бара.

Татар фольклорын җыюны үзмаксат итеп куймасалар да, XIX йөз татар мәгърифәтчеләренең күп кенә дәреслек-хрестоматияләрендә, уку китапларында халык авыз иҗатының үрнәкләре тупланган. Х. Ярми үзенең хезмәтендә бу китапларның барысы белән дә безне таныштырып чыга. Гомумән, «Октябрьга кадәрге чор» исемендәге бу бүлек материалга шактый бай булуы белән аерылып тора. Татар халык иҗатына кагылышлы бөтен материалларны барлап чыгу ягыннан Х. Ярми фольклорчылар арасында үзенә бер хөрмәтле урынга лаек.

Әлбәттә, бүгенге укучының галимнәргә таләбе зур, шуңа күрә аны санап чыгу белән генә канәгатьләндереп булмый. Мәсәлән, М. Иванов, Г. Ваһапов, Г. Балинт, Вамбери, В. Н. Витевский хезмәтләренә кинрәк тукталып, фәнни бәя бирелсә, ул китапларда ничә мәкаль, ничә җыр икәнен с а н а п ч ы г у д а н качылган булса, китап өчен отышлырак булыр иде. Татар мәгърифәтчесе Т. Яхин китаплары турындагы анализ да укучыны канәгатьләндерерлек түгел. Автор кинәт кенә Т. Яхинга «халык мәкальләрен үзгәрткән» дип гаеп ташлый. Имеш, Т. Яхин «Яман сыер яз бозаулар» дип язган, ә «Яман сыер ярда бозаулар» кирәк икән. Ләкин—фольклор бит ул, шайтан алгыры! Аноним әсәр бит, аны кем ничек әйтмәс! Әйтик, бер төбәктә аны чынлап да, «ярда» дип әйтәләр һәм Х. Ярми шулай ишеткән. Ә икенче бер төбәктә сыерның кыш көне бозаулаганын мактыйлар. Чөнки кыштан бозаулаган сыерның язга таба инде сөте була, көзгә бозавы зурайган була, иткә шәп була. Таип карт бәлки нәкъ шуны язып алгандыр?.. Шуңа күрә Х. Ярминең: «Менә бу фактлар Т. Яхинның халык иҗаты материалларына игътибар-

сыз каравын ачык күрсәтәләр», дигәне белән килешү кыен. Әгәр инде XIX йөз мәгърифәтчеләренә бу өлкәдә үпкә белдерәбез икән — анысына урын бар. Ләкин игътибарсызлык өчен түгел, талымсызлык өчен. К. Насыйрида да, Т. Яхинда да талымсыз рәвештә җыеп алынган, язылган халык әсәрләре шактый. Аларның бер өлеше матбугатка да чыккан, үтә порнографик, натуралистик характердагылары чыгарылмый да калганнар. Ләкин татар фольклористикасының беренче ташларын әнә шул Насыйрилар, Яхиннар салганын истән чыгармаска һәм аларга үз заманнары дәрәҗәсеннән чыгыбрак бәя бирергә кирәктер.

Бишенче ел революциясе алып биргән матбугат иреге татарларда китапчылык хәрәкәтен дә көчәйтте. Китап базарлары калынайды. Әлбәттә, демократик рухтагы бер әсәр янында милләтчелек рухындагы ике-өч әсәр басылып базарга чыкты. Бу хәл халык авыз иҗаты әсәрләренә дә кагылды. Х. Ярми бик дөрес күрсәтеп үткәнчә, унынчы елларда халык иҗаты әсәрләрен фальсификацияләп, милләтчелек сөреме белән ыслап китап чыгаручылар да булды. Ләкин бу китаплар халык арасында популярлык казана алмадылар. Чөнки алар рухлары белән халыкчанлык принципларына каршы киләләр иде.

Фольклор китаплары китап сәүдәгәрләре өчен дә бик табышлы булдылар. Татар халкының үсеш дәрәҗәсе буенча беренче чиратта ана нәкъ менә уз әсәре, үз иҗаты язылган китап кызыклырак, якынрак иде һәм базарда солы саткан агай укырга дип гарәпчә дин тарихын түгел, ә «Менә сезгә шәп җырлар» дигән биш тиенлек китап ала иде. Татар агаеның шул сыйфатын сизеп алган борадәран Кәримовлар әнә нәкъ шуна күрә Казан, Оренбург, Уфа һәм Минзәлә базарларын халык җырлары тупланган бишәр тиенлек китаплар белән тутырдылар. Китапларның рекламачыл исемнәре дә каты куллы китап магнатларының характерын, максатын билгели иде. «Менә сина шәп җырлар», «Менә сезгә шәп җырлар», «Менә тагын шәп җырлар», «Менә кайда шәп җырлар», «Менә монда шәп җырлар», «Менә бигрәк шәп җырлар» h. б. Ләкин шунысы да бар: халык җырлары хисабына табыш алу — Кәримовларның субъектив максаты булып калды. Ә халыкның шул китаплар аркылы үз иҗатына игътибар бирә башлавы, аң-белемгә, хәреф тануга омтыла башлавы бу субъектив максатның объектив нәтиҗәсе булып чыкты. Шуна күрә Х. Ярминең унынчы еллардагы халык китапларын җинел кулдан гына тәнкыйтьләп читкә ыргытуын, аларга тар бер сәүдә рамкаларыннан чыгып кына бәя бирүен күнел кабул итми.

Халык әдәбиятына үзенең бөтен тамырлары белән тоташкан Г. Тукай эшчәнлегенә Х. Ярми зур урын бирә. Чыннан да, кара реакция елларында кайбер язучылар адашып, революцион идеаллардан баш тарткан бер чорда егерме дүрт яшьлек татар егетенең аудитория алдында «халык зур ул, көчле ул» дип әйтүе, нәкъ шул елларда халык иҗатын пропагандалавы шагыйрьнең зирәклеген күрсәтә иде. Шуна күрә Х. Ярминең хезмәтендә Г. Тукай һәм татар халык иҗаты мәсьәләсенә аерым бер өзек багышлануы бик урынлы. Тик бу бүлектәге кайбер җитди булмаган фикерләүләрне алып ташлаганда хезмәт тагын да отышлырак буласы икән. Мәсәлән, Тукайның фольклорга мәхәббәтен шагыйрьнең авылда туып үсүенә бәйләп караучыларга каршы бер урында таш атыла. Бәйләсәләр ни! Әгәр кечкенә Апуш урманнарда ат саклап кунмаган булса, әгәр җәйнең эссе көнендә тал төбендә балык каптырып утырмаган булса, кем белә, бәлки «Шүрәле» һәм «Су анасы» дөньяга чыкмый калырлар иде! Аннан соң: «Ул вакытларда азмы-күпме фәнни нигездә төзелгән фольклор җыентыкларының булмавы Г. Тукайга фольклор өстендә тиешенчә тулы фәнни-тикшеренүләр үткәрергә мөмкинлек бирми», (51—52 битләр) дип суктырып үтүнең дә, безнеңчә, бер дә кирәге юк. Тукай фәнни тикшеренүне максат итеп тә куймаган бит! Ул болай, күнеленә җыелган хисләрне, фикерләрне бер көнне тоткан да «Шәрыкъ клубы»нда халыкка түккән һәм вәссәлам! Диссертация язарга йөрмәгән ләбаса Тукай!

Авторның «Чын белән ялган» шигыренә ясаган анализы да шактый сай. Ни өчен А. Н. Афанасьев (XIX йөз фольклорчысы) вариантында чын ялганны җиңә соң? Һәм ни өчен Тукай киресенчә эшли, аның шигырендә «Чын батып китә... чыкмаска, мәңгегә?» Хикмәт нәрсәдә соң? Х. Ярми бу ике вариантны чагыштыра, ләкин конфликтның төрлечә чишелешенең сәбәбен ачмый. Безнеңчә, монда Тукайның реалистлыгы төп сәбәп була. (Бу турыда филология фәннәре докторы И. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» дигән мәгълүм хезмәтендә тәфсилле анализ булса кирәк.) Әйе, әгәр

Тукай 1908 елда да әле мәгърифәтче булса, ул чынны жинүче итәр иде һәм безгә вәгазь сөйләр иде: менә карагыз, дияр иде ул, чын һәрвакытта да жинеп чыга. Ләкин Тукай-реалист алай дип әйтә алмый. Менә карагыз, ди ул, безнең җәмгыятьтә дөп-дөресе шулай була: хакыйкать аста ята. Афанасьев белән Тукайның бер үк мәсьәләне ике төрле чишүләре, безнеңчә, нәкъ менә мәгърифәтчелек реализмы белән критик реализмның нигез аермасыннан килеп чыга. «Тукай кәҗәнең хәйләкәрлек һәм башка сыйфатларын күрсәтүгә үзенең ике әсәрен багышлый» (57 бит) дигән җөмләне дә, нигәдер, укып булмый... Әллә нәрсәсе шунда күңелгә ятмый...

Октябрь революциясе алды елларындагы фольклористика фәне турында сүз алып барганда, фольклор теориясе белән шөгыльләнгән ике галимне телгә алып үтмичә һич тә мөмкин түгел. Болар — Гали Рәхим һәм Галимҗан Ибраһимов. Г. Рәхим 1914 елда «Аң» журналында «Халык әдәбиятымызга бер караш» дигән хезмәтен бастырган иде. Ул монда татар йола җырларын өйрәнүгә галимнәрнең игътибарын юнәлтте, К. Насыйри кебек, мәҗүсилек чоры халык иҗатына керергә омтылыш ясады. Ислам диненең халык иҗатына йогынтысын тикшереп Г. Рәхим шул чор өчен искиткеч кыю булган хөкем чыгарды. «Безнең ислам дине исә,— дип язды ул,— уен, җыр шикелле дөньяви күңел ачулар вә мәҗүсият заманыннан калган гадәтләр тугърысында бик каты дин. Ул муллалар аркылы халыкның иске гадәтләрен кыскан. Муллалар аны бетерүне үзләре өчен бер дини мөҗәһидлектән санап, ничек итеп булса да юк итәргә тырышканнар» («Аң» журналы. 1914 ел. 19 сан. 338 бит).

«Музыка вә җырлар шикелле һәртөрле күңел ачуларга каршы булган ислам дине татар җырларын да кыскан, аларны җырлауны намәшругъ дәрәҗәсенә төшереп, татар җырларының начарлануына иң зур сәбәпләрдән булган» (Шунда ук. 16—17 сан. 311 бит).

Буржуаз матбугатта, ислам дине хаким сыйныфларның идеологиясе булып хезмәт иткән бер чорда Г. Рәхимнең бу мәкаләсе фәндә кыю бер адым иде. Бу мәкаләсендә ул татар җырының, татар музыкасының үзенчәлеген дә билгеләргә омтылыш ясады. Революция алды еллары фольклористикасы турында сүз алып барганда, Г. Рәхимнең «Халык әдәбиятымызга бер караш» дигән зур күләмле тикшеренүен телгә алмыйча үтү, нигәдер, сәер тоела. Әйтергә кирәк, авторның Г. Рәхимгә карашы ни өчендер бөтенләй искечә. Ул аны тискәре яктан мисал кирәк булганда гына искә ала. Мәсәлән, егерменче еллар башында беренче совет мәктәпләре өчен (игътибар итик: беренче!) ашыгыч рәвештә чыгарылган уку китапларының да бер дә файдалы уңай ягы искә алынмый. Имеш, халык әдәбияты әсәрләре бирәбез дип, анда Г. Шәрәф һәм Г. Рәхим «фольклор әсәрләрен бозып биргәннәр» (64 бит). Г. Рәхим, Г. Газиз чыгарган «Татар әдәбияты тарихы» да «аклап булмаслык» ялгышлардан гына тора икән (65 бит) һ. б. Дөрес, Г. Рәхим фән өлкәсендәге гел шома юлдан гына бармады, ләкин аның фән дөньясындагы, бигрәк тә фольклористикадагы, файдалы хезмәтен дә телгә алырга кирәк бит! Мәсәлән, аның «Халык зарларыннан» дигән мәкаләсе лашманчылык хезмәте, лашман бәетләре хакында бүгенге фольклорчылар өчен нигез булып тора. Ә Х. Ярми менә шул мәкаләгә килеп җиткәч, «Г. Рәхимнең... мәкаләсен исәпкә алмаганда... бу елларда... бүтән материал күренми» (71 бит) дип кенә уза[1].

Октябрь революциясе алдыннан (1916) Г. Ибраһимовның «Әдәбият кануннары» дигән хезмәте басылып чыккан. Бу китапта фольклор турында да бер бүлек бирелеп, Г. Ибраһимов татар фольклористикасында беренче тапкыр дип әйтерлек халык жанрларының барысының да төшенчәсен билгели. Шул заман өчен шактый кызыклы фикерләр күтәрә. Мәсәлән, ул халык әдәбиятының әкияттән башкалары барысы да көйле икәнлекләрен исбат итә. Халык әдәбияты һәм язма әдәбиятның кайчан тууы турындагы фикерләре дә шактый кызыклы. «Язма әдәбият халык әдәбиятыннан үсеп киткән бер гөл булганга,— дип язды Г. Ибраһимов,— ул тышкы төзелеше белән әдәбиятның соңгы кагыйдәләренә муафыйкъ була. Әмма халык әдәбияты хакында моны әйтер хәл

---

[1] Бездә әле булса Г. Рәхимнең исемен уңай яктан телгә алудан шикләнүчеләр очрый. Безнең кулыбызда шундый бер документ бар: ТАССР Верховный суды Президиумының 1958 ел 20 февраль карары белән Г. Рәхим гаепсезгә кулга алынган дип табыла һәм аклана.

юк. Бу икенең берсен табигый урманга, икенчесен оста карачының дикъкатьле тәрбиясендә эшләнгән бакчага охшатырга мөмкин».· Әдипнең бу теоретик хезмәтен 1918 елгы икенче басмасы — совет чоры буенча телгә алу, шуның белән аның хронологик урынын бутау ни өчен кирәк булгандыр — аңлашылмый. Аннан соң бөек әдипнең бу хезмәте турында тулырак язганда да әйбәт буласы икән!

Мәзәк — безнең фольклорның моңарчы фәнни яктан тиешенчә өйрәнелмәгән үзенчәлекле жанры. Бу жанрны җыю, бастыру тарихы да кызыклы гына. Моны бастыру тарихыннан К. Насыйри, Т. Яхин, Шиһабетдин бине Габделгазиз кебек өч мәгърифәтчене телгә алып булыр иде. Болардан тыш XIX йөз ахыры, XX йөз башы календарьларында күп кенә халык мәзәкләре тупланган. Аннан соң безгә билгеле булмаган кешеләрнең мәдрәсә шәкертләреннән җыеп язган мәзәк китаплары булуы билгеле. «Лэтаиф» исемендәге аерым китап та бар. Бу жанрның кайбер үзенчәлекләре турында язучы Г. Бәширов үзенең «Туксан тугыз мәзәк» (1960), «Мең дә бер мәзәк» (1963) исемле китапларында язып та чыккан иде. Х. Ярминең бу китабыннан укучы мәзәк жанры турында нәтиҗәле фәнни сүз көтәргә хаклы. Ләкин монда: «Фольклорның... мәзәк дип аталып йөртелгән бер төре бар. «Ике ялкау», «Куркак солдат», «Куркак кеше», «Коры куаныч» кебек әсәрләрне һич тә шикләнмичә фольклорның әнә шул төренә кертергә мөмкин», (103 бит) диюдән узылмаган. Чыннан да, «Ике ялкау», «Куркак солдат» — бу исемнәр укучыга нәрсә бирәләр? Безнеңчә, берни дә. Мәзәкне халыктан җыеп алганда еш кына аның исеме бөтенләй булмый. Аңа исемне, гадәттә, китап чыгаручы галим — фольклорист бирә. Аннан соң мәзәк жанры турында сүз барганда бу жанр өстендә эшләгән, аны җыйган, аның турында фән сүзе әйткән әлгәрләренне бөтенләй телгә алмау — шулай ук аңлашылмый. Һәрхәлдә, мәзәк жанры турында сүз әйтергә тотынып та, бер сүз дә әйтмичә узып китү бу хезмәтнең дәрәҗәсен төшерә.

Алда искәртеп үткәнебезчә, безнең заманда татар халык иҗатын киң колач белән туплаучы, эшкәртүче, дөньяга чыгаручы галим — Нәкый Исәнбәт. Х. Ярми үзенең китабында әнә шуңа күрә Н. Исәнбәтнең бу хезмәтенә махсус туктала һәм аны «совет фольклористикасы тарихында зур вакыйга, уңышлы һәм мактаулы бер эш» дип атый. Чыннан да, Н. Исәнбәтнең бу өчтомлыкка биргән сүз башы фольклорчылар өчен генә булмыйча, тарихчылар һәм лингвистларга, әдәбият теоретикларына да кулланма булып хезмәт итәр.

Шулай итеп, Х. Ярми татар фольклоры буенча дөньяга чыккан иң беренче хезмәтләрдән башлап бүгенге көндә чыккан иң соңгыларына кадәр күзәтү ясый. Авторның әйтүенә караганда, «бездә зур гына фольклор фонды тупланган һәм аны фәнни принципларда өйрәнү-тикшерү өлкәсендә байтак кына әһәмиятле эшләр башкарылган». Шул ук вакытта автор фольклористика өлкәсендәге бурычларыбызны да билгели. Болар — халык жанрларының яшәү һәм үсеш юллары мәсьәләсе, татар халкының дастаннарын өйрәнү һ. б. мәсьәләләр икән. Шул ук вакытта «татар халкының поэтик иҗатын бүтән халыклар фольклоры белән, аеруча казакъ, үзбәк, башкорт, төркмән, әзербайҗан, каракалпак кебек тугандаш төрки халыкларының фольклоры белән чагыштырмача өйрәнү якын киләчәктәге иң мөһим бурычларның берсе булып тора»,— ди автор.

Х. Ярминең бу фикеренә кушылмый мөмкин түгел.

* * *

Китапның калган бүлекләре татар халык иҗатын жанрлар буенча тикшерүгә багышланган. Шулардан без ике генә жанрга — бәетләр һәм җырлар жанрына тукталуны мәгъкуль күрер идек. Татар халкы иҗатының үзенчәлекле жанры — бәетне телгә алуга Х. Ярми күз алдына килә. Чөнки бездә халык бәетләрен җыю, теркәү, эшкәртү, өйрәнү ягыннан соңгы егерме-утыз елда аның кадәр эшләгән башка бер генә кеше дә юк. Аның «Бәетләр» исемендә 1960 елда чыгарган җыентыгын китап базары йотып алды. Х. Ярминең бәетләр турында кызыклы гына гипотезалары бар. Мәсәлән, ул борынгы бәетләрнең барысы да махсус көйле булганнардыр дигән бер фикер әйтә. Бу — бик кызыклы һәм өметле фикер. Киләчәктә, бәлки, бу өлкәдә музыка белгечләре белән

берлектә тикшеренүләр алып барырга кирәктер? Һәрхәлдә, Х. Ярминең бу гипотезасы киләчәктә өйрәнү өчен бер өлкә билгели[1].

Бәетләр — Х. Ярми хезмәтенең иң зур өлеше һәм бу бүлек турында бәлки иркенләбрәк сөйләшкәндә дә ярар.

Иң элек бәетләрне кемнәр, кайсы катлау иҗат итү мәсьәләсе. Бу — бәетләр турындагы бүлекнең төп урынын алып тора. Автор бүлекнең буеннан-буена бәетләрне шәкертләр тудырмаган, аларны грамотасыз кешеләр тудырган дип исбат итә. Ярый, шулай дип уйлап торыйк. Ләкин шул ук вакытта авторга бер-ике сорау бирик.

Беренчесе: шәкертләр нинди катлауга керәләр?

Икенчесе: грамоталы кешеләрнең халыкның реакцион (эксплуататор) катлавына керүе зарурымы?

XX йөз башында Россиядәге башка вак милләтләр арасында Идел буе татарларының грамоталылыгы чагыштырмача югарырак иде. «Империализм буенча дәфтәрләр»дә В. И. Ленин Казан татарларында 1913 елда йөз җанга бер мәктәп туры килгәнлеген мисалга китерә[2]. Буби, Кышкар, Сатыш, Мәчкәрә, Курса кебек авыл мәдрәсәләрендә меңләгән крестьян егетләре грамотага өйрәнәләр, Татар мәгърифәтчеләренең әсәрләрендә (мәс. З. Һади әсәрләрендә) мәдрәсәдә укучы шәкертләр — гади крестьян уллары. Г. Ибраһимов әсәрләрендә, К. Тинчурин мәрҗәннәрендә шәкертләрнең зур күпчелеге крестьян егетләре икәнлеге күренә. Димәк, шәкерт массасы — крестьяннар арасыннан чыккан укучы яшьләр төркеме. Шулай булгач, шәкертләр дә бәет иҗат иткәннәр дип язган кемнеңдер, янәсе, «реакцион» фикеренә каршы көрәшү — җил тегермәненә каршы көрәшне хәтерләтә. Ни өчендер автор укымышлы кешеләр, һичшиксез, эксплуататор катлау вәкилләре дигән карашта тора. Татарның меңләгән мәгърифәтче мөгаллимнәре көнне-көнгә чак ялгап, ачлы-туклы гомер кичергәннәр. Ә үз имзасын куя белмәгән Хөсәенов татарның иң эре миллионеры булган. Аннан соң шунысы да бар. Немец профессоры Г. Вайльнең «Татар текстлары» дигән китабында («Tatarische Texte» Berlin — Leipzig. 1930) беренче бөтендөнья сугышында әсирлеккә төшкән татар егетләре турында мәгълүмат бирелә. Профессор Вайль аралашкан егетләрнең барысы да диярлек ике телдә укый-яза белә торган булалар һәм алар Вайльгә бик күп халык әсәрләре яздыралар. Вайль аларның кайсы өлкәдән, авылдан һәм нинди семьядан чыкканлыкларына игътибар иткән. Бәет, җыр яздырган егетләрнең барысы да авыл егетләре, крестьян уллары. Инде Х. Ярминең үз мисалына килик. Ул «Солдат бәете»ннән бер өзек китерә.

Тарих мең дә сикез йөздә
Җитмеш дүртенче елында
Китте бәнем газиз башым
Маһи сәфәр аенда.

*(113—114 битләр)*

«Маһи сәфәр» аенда дип әйтүче кем? Әлбәттә, бу гыйбарәне бары тик грамоталы кеше генә куллана ала. Яки, менә икенче мисал.

Иртә сәхәр вакытында әкрен генә җил егълый,
Карт солдатлар киткәндә, җилләр түгел, ил егълый.

*(135 бит)*

Бу өзектә дә (1914 елда иҗат ителгән «Кайгылы көннәр» бәете) укымышлы кешенең, Тукай шигыре белән таныш кешенең мәгълүм алымны

---

[1] Авторның дастаннар турындагы фикерләре дә игътибарга лаек. Без моңа кадәр халкыбызның борынгы дастаннары булуын, аларның әдәби яктан искиткеч көчле эшләнгән булуы өзек-төтек ишетеп кенә белә идек. Кайчандыр ниндидер дастаннарыбыз булган... Аларда мәкальләр, әйтемнәр, халык теленең энҗе-гәүһәрләре тулып ятканнар... Кайбер дастанның һәр юлында халыкның мең еллык тәҗрибәсе дүрт-биш сүз белән уеп куелган булган... Кызганычка каршы, дастаннарыбыз турында безнең фәндә мәгълүмат шулкадәр аз, булганнары да ниндидер сәбәпләр аркасында күмелеп яталар. Х. Ярми әнә шул байлыгыбыз турында сүз кузгата, аларны бәетләр белән чагыштырып тикшерергә омтыла. Бу — галимнең хезмәтендә бик отышлы урын, тик бу мәсьәләне тирәнәйтебрәк җибәрәсе иде.

[2] В. И. Ленин. Сочинения. т. 28. Рус телендә, 514—515 битләр.

бәеткә кертеп җибәргәнен күрү авыр түгел. Димәк, әгәр кара халык арасыннан чыгып хәреф өйрәнгән егетләр үзләренең чыбыктан үргән сандыкларында бәет дәфтәре саклап йөргәннәр икән яки җыелышып берәр бәет иҗат иткәннәр икән — монда бернинди крамола юк. Аннан соң, хикмәт әсәрне кем иҗат итүдәмени! Эчтәлеге кемнәр тегермәненә су коя? Кайсы катлау интересларын чагылдыра? Менә шул турыда уйланырга һәм шуннан чыгып «биергә» кирәк. Ә бәетләрнең грамотасыз крестьян халкы тарафыннан да иҗат ителгәнен берәү дә инкарь итәргә җыенмый. Мәсәлән, «Каҗә бәете» турында галимнәр арасында нинди фикер генә юк! Моны озак еллар буена Тукай әсәре дип тә йөрделәр. Аннан, ул бәет Кандалыйныкы икән диючеләр дә булды. Ләкин беренче чыганакка игътибар итик: Габделгаллəм Фәизхановның «Хикәят вә мәкалэт» (1896) дигән китабының 16 битендә бу бәет «бер авыл шәкертенең әсәредер» дип күрсәтелә. Димәк, бу очракта бер шәкертнең әсәре халыклашып киткән.

Фольклорчылар тарафыннан телгә алынып йөртелгән «Җыеннар бәете» дигән әсәрне дә гомумән халык түгел, ә Габделгаллəм Фәизханов үзе иҗат иткән («Хикәят вә мәкалэт» китабының 14 нче битендә Фәизханов моны шулай дип үзе күрсәтә).

Безнең уебызча, аерым кеше иҗат итеп шунын куен дәфтәрендә калган (шигырь дип әйтмик) тезмә әсәр белән халык күңеленә кереп урнашып т е л д ә  я ш и  т о р г а н  п о п у л я р  б ә е т л ә р н е аерып алып карарга кирәк. Шулай булганда «бәет» төшенчәсе шактый конкретлаша төшәр иде. Мәсәлән, XVI гасыр башында иҗат ителгән «Мөхәммәт Әмин» бәете шул чор шагыйренең әсәре түгелме? Халык телеме соң бу, әллә профессиональ шагыйрь телеме?

Я илаһи, әйлә ул бәндәнне син
Ахирәттә залим вә җаһил белән.

*(126 бит)*

XVI гасырда безнең халкыбыз шулай сөйләштеме икән? Монда шикләнергә урын бар. Шикләнергә урын бар икән, чыганакларга мөрәҗәгать итик. Иң беренче — текст дөрес бирелмәгән.

«Үзе аксак, акылы ахмак, фетнәдә» дип бирә Х. Ярми. Күренеп тора — текст аңлашылмый.

«Ни җавап бирер ходай каршында ул,
Сурса алла мәддәт вә гыйкаб белән»,—

дигән җөмлә шулай ук аңлашылмый. Хәлбуки, беренче очракта «фетнадар», икенче очракта «мәддәт» түгел, «шиддәт», ягъни катылык, кискенлек. Аннан соң, «Мөхәммәт Әмин» бәетенең «бәетләр» арасында йөрүе берничек тә аңлашылмый. Тарихчы Хөсәен Әмирхановның «Тәварихы Болгария» дигән әсәрендә (1883 ел, Казан. 60 бит.) бу әсәр тарихи шәхес Мөхәммәт Әмин ханның үз шигыре дип күрсәтелә. Бу әле бер генә мисал. Совет чоры бәетләре дип йөртелгән күп кенә әсәрләрне дә шул күзлектән карап чыгу комачау итмәс иде.

Бәетләр турында сүз алып барганда, без тагын бер сорауга җавап табар идек. Х. Ярми шәхси фаҗигагә корылган бәетләр «туганнары, якыннары кулында гына сакланып калучан була..., аларны гомумхалык тарихын яки халыкның югары идеалларын чагылдырган тирән эчтәлекле бәетләр белән бер рәткә куеп булмый» (116 бит) дип яза. Ярый, шулай да булсын. Менә «Суга баткан Гайшә» бәетен алыйк. Моның сюжеты, мәгълүм булганча, шәхси фаҗигадән гыйбарәт. Монда социаль мотивлар юк. Гайшә кебек суга батып үлүчеләрне һәр җирдә табарга була. Ләкин ни өчен нәкъ менә шушы бәет татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә популяр? (Без аның вариантларын Томск, Курган, Новосибирск өлкәләрендә дә очраттык.) Ни өчен бу бәетнең күе дә сакланган? Хикмәт нәрсәдә? Яки ни өчен Баламишкин турында махсус көе белән бәет (җыр) бар? Баламишкин (яшь Мишкин дигән сүз. Казанның бер татар сәүдәгәре, 24 яшьтә үтерелеп, Идел суына ташлана) кебек үтерелүчеләр аз булганмыни? Әлбәттә, бәетләрдәге шушы ч ы г а р м а л а р н ы ң  з а к о н ч а л ы к л а р ы н ачып биргән булса, Х. Ярминең «Бәетләр» дигән тикшеренүе тагы да отышлы чыккан булыр иде.

Бәет кайчан туа? Х. Ярми хаклы рәвештә иҗтимагый темаларга багышланган бәетләр халык күңелен кузгатырлык зур үзгәрешләр, вакыйгалар булганда туалар дип исбат итә. Моны безнең тарихыбыз үзе күрсәтеп тора. «Эчтәлек һәм художество ягыннан чын сәнгать әсәрләре югарылыгында торган бәетләр нәкъ әнә шундый зур иҗтимагый-тарихи үзгәрешләргә яки сугышларга карата иҗат ителгәннәр»,— ди автор. Мона мисал — «Рус-француз сугышы», «Урта Тигәнәле», «Рус-япон сугышы» бәетләре. Ләкин авторның бәет жанры безнең заманда да актив була ала дип тырышып-тырышып исбат итүе белән килешүе кыен. Бәетләр китап, газета-журнал, телефон, радио юк заманда, патриархаль авыл тормышында халык күңелендәге хисне туплаган коллектив сәнгать әсәре буларак туып һәм яшәп килделәр. Алар заманында халык күңелендә матурлык тойгысы («Хан кызы бәете»), сыйнфый тойгының чагылышы булдылар («Урта Тигәнәле» бәете) һәм халыкта шул тойгыларны тәрбияләделәр. Ә «Сак-Сок» бәетләре берничә йөз еллар буенча халык арасында бала тәрбияләүдә педагогик функцияләр үтәп килде. «Гөлсылу» бәете, «Кәчимский Ибрай» бәетләре дә әхлак тәрбиясе мәсьәләләрен алга куйдылар. Бәетләр шулай итеп гасырлар буе күп төрле функцияләр башкарган актив жанр булып килделәр дә хәзерге заманда бетүгә йөз тоттылар. Дөрес, алар туалар — ләкин актив жанр була алмыйлар, чөнки фән һәм техника заманында халык күңелендәге хисләрне белдерү өчен башка төрле каналлар бар. Мәсәлән, Тукай үлгәч, халык Тукай бәетен иҗат иткән. Халыкның икенче бер сөекле шагыйре М. Җәлил Тукайга караганда күп мәртәбә тирәнрәк фаҗига кичереп һәлак булды. Җәлил турында ни өчен бәет чыкмады? Чөнки аның турында китаплар, роман, фильм, мәкаләләр, спектакльләр тудырылды, халык хисләре әнә шул профессиональ сәнгать эченә кереп кушылды. Ватан сугышы елларында иҗат ителгән йөзләгән бәетнең берсе генә дә популяр булып китә алмады — чөнки халык кайгысы матбугат, радио, сәхнә, җыелышлар, митинглар аркылы ташыды, үзенә юл тапты. Ул чорда иҗат ителгән бәетләрнең бик күбесе иҗат итүче тол хатынның, карт ананың шәхси хәзинәсе, үз шигыре буларак аның дәфтәрендә, күңелендә калды. һәм хәзерге фольклор экспедицияләре вакытында болар табыла икән, бу әле һич тә бәет жанры безнең заманда актив булды дип әйтергә нигез бирми. Шуңа күрә Х. Ярминең бәетләр сүнүгә таба баралар дию-челәрне «нигилистлар» дип атавы (122 бит) һич тә аңлашылмый.

Бәетләр турындагы бүлекне укыганда, без анда бәетләрнең әдәби эшләнеше турында тикшеренү күрербез дип өметләнгән идек. Чыннан да, никадәр зур байлык! Кайбер бәетләрнең астына, Тукай әйтмешли, кайсы шагыйрь генә үзенең имзасын куймас иде икән?! Алардагы гипербола, гротеск, аллитерация!

Кояш чыкканда, кан тула күзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.

Менә моны, әти-әнисеннән аерылып, кошка әйләнгән ике сабый әйтә. Алар тәрәзә янында яктырганчы тилмерешеп очып йөриләр, ә таң атканда урманга китәргә мәҗбүрләр. Әнә шуңа күрә:

Кояш чыкканда кан тула күзгә...

Яки балаларның эчке дөньясын, аларның фаҗигасенен тирәнлеген халык ничек белдергәнен игътибар итик. Монда табигать сурәтләре параллель куела. Алар я контраст, я тәңгәл алыналар.

Өйгә кибәнне җилләр тарата,
Кавышабыз дигәч, хәзер таң ата.

Яки:

Су буйларында Идел камышы,
Урман эчендә — Сак-Сок тавышы.

Менә әдәбият белгечләре, шигырь төзелешен өйрәнүчеләр өчен бетмәс-төкәнмәс хәзинә. Шундый ук әдәби чараларны без «Хан кызы» бәетендә дә күрәбез. Анда су буендагы камыш кебек зифа буй, асламчыдагы энҗе кебек тешләр, кара ефәк кебек чәчләр һ. б. һич тә көнчыгышның классик поэзиясендәге әдәби чаралардан калышмыйлар. Халык, чыннан да, шагыйрь икән, әдип икән. Ләкин Х. Ярми — бәетләр буен-

ча белгеч — бәетләрнең сәнгатьчә алымнарын тикшерүне киләчәккә калдыра (148 бит). Урыны нәкъ менә шушы иде бит!

Бәетләрнең әдәби эшләнешенә күз йомып, аларның социаль янгырашы белән генә мавыгу авторны кайвакытта халык әсәрләрен вульгарлаштырып аңлатуга, текстлар белән саксыз эш итүгә китерә. Ул җәһәттән авторның «Хан кызы» бәете турындагы анализы бик характерлы. 1960 елда чыгарылган «Бәетләр» китабында автор:

— Бәнем кашым карасына ни диярсең,
Асламчыда кара сырма күрмәймесең? —
*(Бәетләр, 53 бит)*

дип биргән иде. Сырма — телогрейка. Бәеттә сүз кара сөрмә турында бара бит инде!

Бәнем сеңлем ялган кеше,—

дигәне һич тә халык гыйбарәсе түгел. «Ялган кеше» дип әйтү халыкта гомумән юк. «Яман кеше» кирәк. Шул ук игътибарсызлык без тикшерә торган китапта да киткән.

Инде бәетнең эчтәлегенә килик. Әсәрдә хан кызы турында сүз бара. Аның ишеге янына килгән егет кызның бөтен тышкы кыяфәтләрен сокланып мактый. Кыз да бу мактауларны горурлык белән кабул итә. Ләкин ишегеn ачмый. Х. Ярми аңлатканча, бәеттә «гәрчә ул хан кызы булса да, ир кешегә хәтта күренергә дә хокукы булмавы тасвирлана» (144 бит). Ата-ана белмәгәндә янына егет кертә, бу — нәрсә, хокукмы, әхлакмы? Безнеңчә, монда сүз әхлак турында бара. Халык иҗаты, гомумән, кызларның әдәпле, тыйнак булуын мактаган. Моңа безнең фольклорда мисаллар күп. Аннан соң хан кызы үзе кем? Ул, чыннан да, феодаль иерархиянең башында торган, дәүләт башындагы власть иясе ханкызымы? Әсәргә кереп карыйк. Егет үзенең сөйгәненә менә нинди тәкъдимнәр ясый:

— Абзыкаңа алып бирим ала юрга,
Иншаалла, чыгып китәр озак юлга.
— Җиңгәнә авыр балта бән бирәем,
Урман юлын күрсәтүбән җибәрәем.
— Сеңлеңә матур шәкерт бән бирәем,
Мәктәп юлын күрсәтүбән җибәрәем.
— Әнкәңә алып бирим алтын тарак,
Һәр җомгада утырыр ул чәчен тарап.

Икенче бер вариантта:

— Әнкәңә алтын тарак бән бирәем,
Мунча юлын күрсәтүбән җибәрәем.

Тексттан күрелгәнчә, монда гади кыз, гади патриархаль семья турында сүз бара. Монда сарай тормышына бер генә ишарә дә юк. «Хан кызы» төшенчәсе астына монда халык, ихтимал, матур кыз — затлы кыз төшенчәсен алгандыр. Авыр физик хезмәт крестьян кызын газаплаган, имгәткән, тупасландырган. Энгельс әйткәнчә, халык иҗаты әсәрләре һөнәрченең мастерскоен һәм җәфаланган өйрәнчекнең кызганыч чардагын поэзия дөньясына, алтын сарайга әйләндерергә хезмәт итә, һәм аның чибәр кәләшен гүзәл принцесса итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. (Ф. Энгельс. «Немец халык китаплары» дигән мәкаләдән.) Шуңа күрә безнең фольклорыбызда күркәм әхлаклы хан кызы, гүзәл патша кызы һ. б. очрый икән — бу әле һич тә халык конкрет тарихи шәхес — патша яки хан турында җырлаган дигән сүз түгел. Халык үз кызын, әнә шул авыр тормыш тарафыннан сытылган, изелгән кызын фантазиясендә принцесса итеп — ягъни нәзакәтле,назлы, чибәр итеп күз алдына китергән. Шуңа күрә «Хан кызы» бәетенең художество алымнарына кереп тормастан, социологик анализ ясарга омтылган авторның нәтиҗәсе, безнеңчә, урынсыз.

«Художество ягыннан бик матур иҗат ителгән бу әсәрдә,— ди Х. Ярми,— хатын-кызларның читлектәге кош кебек бикләнеп яшәргә мәҗбүр булулары һәм моңа хан сарае кешеләренең барысының да бертигез гаепле булуы һәркемне ышандырырлык

итеп тасвирлана. Шунын белән бергә, халыкның ханга һәм аның семьясына нинди мөнәсәбәттә торганлыгы да әсәрдә ачык күренә» (144 бит). Чыннан да, әсәрнең эчтәлегеннән никадәр ерак бу анализ!

Бәет жанры фәнни аппараты белән дә, җыелу тарихы белән дә Х. Ярми эшчәнлегенә бик нык бәйле. Бу жанр турында авторның әле безгә әйтмәгән фикерләре шактый булыр дип уйларга нигез бар. Китапның киләсе басмасында автор бу бүлекне фәнни яктан, һичшиксез, тирәнәйтер дип ышанабыз.

* * *

Х. Ярминең бу хезмәтендә җырлар жанрына багышланган бүлек тә фактик материалга бай. Бездә җыр китапларын чыгаручылар күп, әмма җырларыбызның сәнгатьчә үзенчәлеге турында язучы аз. Ниһаять, Х. Ярми И. Надировтан соң бу мәсьәләгә тагын бер тукталa. Татар җырларының үзенчәлеге турында Х. Ярми заманында К. Насыйри башлаган, Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Рәхим күтәреп алган фикерләрне дәвам иттерә. Җырлар жанры — фәнни анализ өчен халык иҗатының иң авыр төрләреннән санала. Чөнки монда җыр янында һәрвакытта да көй тора. Җыр турында нәрсә дә булса әйтер өчен, көй, музыка турында да азмы-күпме төшенчәң булырга тиеш. Автор үз өстенә әнә шундый авыр бурыч йөкләгән. Ул халыкның җырлы уеннарына бик югары бәя бирә. Җырлы уеннар, ди ул, «яшьләр өчен күңел ачу чарасы гына түгел, бәлки тәрбияви әһәмияте дә зур булган халык уеннары» (201 бит). Әйе, клуб, су буйларында уйналган җыр кичәләре яшьләребездә бер-берсенә ихтирам, хезмәткә, туган илгә мәхәббәт тәрбияләү ягыннан бер мәктәп булдылар. Кызганычка каршы, алар хәзер кимеп баралар.

Халкыбызның йола җырлары турында автор аерата зур җылылык, фәнни тирәнлек белән яза. Бигрәк тә, «Шәмчырак», Түбән татарларының кыз күчерү йолалары безнең алда бөтенләй яңа яклары белән ачылалар. Тик М. Акчурина мәкаләсеннән китерелгән йола җырында гына текст белән саксыз эш итү аркасында мәгънәгә зыян килгән. Автор анда:

Күзчегемдә минем күк нагыш,—

дип яза да «күзчек» — күлмәк якасы дип аңлатма бирә. Хәлбуки, «күзчек» түгел, ә күнчек, татар кызларының вак-төяк әйбер салып йөрү өчен күннән эшләнгән ридикюльләре.

Әлбәттә, бу бүлектә дә мәсьәләне тирәннәнрәк алган булса, автор өчен отышлырак булган булыр иде. Кайбер йола җырларының эчтәлеген сөйләп барулар (191—192 битләр) фәнни хезмәткә берни дә өсти алмыйлар. Авторның бу бүлектәге кайбер фикерләре дә бик урынсыз яңгырыйлар. Мәсәлән, ул «Таң кучат» h. б. җырларны кызны, аның ата-анасын е л а т у  ө ч е н җырланганнар, дип исбат итә (196 бит). Безнеңчә, һич тә алай түгел. Бу йолаларда кызны елату төп максат түгел, алар кызны озату кебек семьяда була торган зур эшкә халык сәнгате элементларын катыштыру формасында туганнар. Ләкин, соңгы заманнарда ислам дине көчәеп, хатын-кызның семьяда хокукы тарайган саен бу йолаларны үтәгәндә үзеннән-үзе елау катнаша башлаган. Тарихта мәгълүм булганча, бик борынгы заманнарда кызны кияүгә бирү зур тантаналы акт булган һәм ул бары тик феодаль, капиталистик җәмгыятьләрдә генә товар сатуга кайтып калган һәм драмага әйләнгән. Авторның йола җырларының иң матуры булган «Җимчәчәк»не дә кешеләрнең табигатькә тәэсир итәргә теләүләре дигән гипотезасы бик сәер яңгырый. Безгә калса ул — кыш буе караңгы өйләрдә ирегеп яткан яшьләрнең язны каршы алулары, бергә очрашулары. Моның нигезендә яшьлек, яз шатлыгы, мәхәббәт хисләре, хезмәт дәрте ята. Һәрхәлдә, Х. Ярми мисалга китергән текстта табигатькә тәэсир итәргә омтылуның эзе дә күренми. Табигатькә тәэсир итүгә корылган йолалар булганнар, ләкин алар икенче характерда.

Фән өчен никадәр кирәге бардыр, әмма автор «Җырлар» бүлегенең зур гына бер өлешен безнең дүртюллык җырларыбыз борынгы озын җырлардан таралып, адашып калган кисәкләр дип исбат итә. (Автор озын җырларны сюжетлы җыр дип атый, дүртюллыклар, димәк, сюжетсыз (?) булалар. Бу — никадәр фәнни классификациядер,

анысын фольклорчылар хөкеменә калдырыйк.) Берәүгә дә яшерен түгел, фольклор экспедицияләре вакытында мөһләгән дүртюллык янына ике-өч кенә озын җыр табып була. Димәк, дүртюллыклар күпчелек. Әнә шуңа күрә Г. Рәхим: «Безнең җырларыбыз һәрвакыт кыска гына, дүрт юллы гына җырлар булалар», дип язган иде. Х. Ярми аның әнә шул җөмләсен мисалга китерә дә (217 бит) шуның киресен исбат итәр өчен шактый уңышсыз гына дәлилләр эзли. Ләкин Г. Рәхим «Кара урман» кебек озын җырларыбыз барын гына белгән инде! Ихтимал, безнең җырларыбыз борынгы заманда шулай озын, аерым бер эчтәлекле җырлар булганнардыр. Ләкин автор китергән мисалларның («Салкын чишмә», «Газизәкәй балдыз» һ. б.) текстлары нәкъ менә корама төсендә теркәлгәннәр дә, автор үз теориясенә үзе каршы чыккан. Автор болай ди:

Утырдым ла көймәнең, ай, түренә,
Үрләп киттем суның үренә;
Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама,
Калдырмам ялгыз.
Сөйләгән дошманнар тик сөйләсен,
Кеше кермәс кеше түренә,
Һаваларда йолдыз...

«Бу борынгы җыр кай ягы белән сюжетлы җыр түгел соң?» дип чакыру ташлый автор. (220 бит.) Хикмәт шунда ки, бу даими кушымтага (һаваларда йолдыз) автор тоткан да ин гади бер дүртюллыкны ваклап салган. Бу җырның төп өлешендә нәкъ менә шушы сүзләр яткан дип кем исбат итә ала? Әйтүе кыен. Кушымта безгә исән-сау килеп җитә алган. Аның буенча без бер драматик вакыйганы чамалый алабыз. Ләкин мут җизнәкәй балдызына төп текстта нәрсәләр әйтте икән? Менә монысы инде безгә билгесез. Шулай итеп, авторның гипотезасы шактый кызыклы гына булса да, китергән мисаллары аның файдасына түгел.

Авторның мәхәббәт җырларына ясаган анализында да гадәттән тыш гадиләштереп фикерләүләр очрый. Мәсәлән, бер урында ул болай ди: «Яр сөю гадәти нәрсә. Ләкин кемне, нинди кешене сөяргә? Монда инде сөючә кеше бик сайланырга, уйланырга (!) тиешле» (Курсив безнеке). «Сөйма кешенен ярларын, яшь башларың хур булыр» кебек җырлар «кешегә практик киңәшләр бирү» өчен җырланалар (212 бит) дип язган урыннар да артык беркатлы. Мәҗлес җырлары, ди автор икенче бер урында: «XIX йөзнең азагында, XX йөз башларында, нәкъ менә хезмәт ияләренең дуслашулары, берләшүләре (һәм кара-каршы утырып фикер алышулары) иң кирәкле һәм иң мөһим бер мәсьәлә булып килеп баскан бер чорда туган булсалар кирәк» (213 бит). Монысы инде, әлбәттә, бармактан суырып чыгарылган фикер. Халык булган җирдә мәҗлес булган, изүчеләр булган җирдә аларга каршы сыйнфый ачу булган — ә сыйнфый ачу булган җирдә изелүчеләрнең бердәмлеге дә булган. Халыкның зур күпчелеге Пугачев артыннан алпавытларга каршы көрәшкә күтәрелгән, халык, үз ватанын саклап, бердәм рәвештә француз талаучыларына каршы күтәрелгән икән, бу эшләр, әлбәттә, бергәләп сөйләшү, киңәшүсез генә булмаганнар.

Дүртюллык җырлардагы мәгънә бәйлелеге турында берничә сүз. Бу турыда тәфсилле рәвештә Г. Тукай язган иде. Аннан шул ук мәсьәләгә, гәрчә Тукайны искә алмыйча гына булса да, Г. Рәхим дә тукталды. Бер уйлаганда монда инде бәхәсләшерлек принципиаль мәсьәлә дә юк. Әйе, Х. Ярми моңа йомгак ясый һәм хаклы рәвештә татар җырларының беренче ике юлы белән соңгы ике юлы бәйле һәм бәйсез булырга мөмкин дип нәтиҗә чыгара (243 бит). Ләкин нечкәләбрәк тикшереп караганда, күп кенә татар җырларының тышкы яктан күзгә ташланмаган мәгънәви бөтенлеге бар. Менә болары фольклор галимнәренә тикшерергә бетмәс-төкәнмәс хәзинә булып торалар. Халык җырларыннан бер-ике мисал өстендә тикшерү уздырып карыйк.

Лепер-лепер басып кила
Агыйделдә ак куян.
Күкрәгенә башым куям,
Сискәнмә, җаныем, уян.

Рифма бөтенлеге, жырның үзеннән-үзе жырлап торуы хакында сүз озайтмыйк. Болары — койган да куйган. Ләкин — мәгънәсез сүзләр, бәйсез строфа бит! Халык та инде — теләнә нәрсә килгән шуны жырга керткән. Куян турында әйтә дә кинәт кенә мәхәббәт хисләренә күчә. Куян һәм мәхәббәт... Аннан соң моңысы тагын нинди мәгънәсезлек? Су өстендә куян ничек йөрсен? Менә шундый сораулар тууы мөмкин. Ләкин, ләкин... Куян нинди? Ак. Димәк, кыш көне. Агыйдел өстен чиста, мамык кар каплаган. Әнә шуннан йомшак ак тәпиләренә басып куян килә. Ассоциация: чисталык, пакьлек, саклык. Жырчы баштагы ике юл белән безнең күңелне әнә шул хисләрне кабул итүгә әзерләде. Тагын ике юл. Ниндидер хәйлә табып сөйгән егет кыз янына кергән. Ул да әнә шулай сак. Аның хисләре дә шундый саф. Әнә ул ничек нәзакәтле итеп кызны уята. «Сискәнмә, жаныем, уян...»

Карлыганга бардым дисең,
Кайда карлыганнарың?
Болай булгач билгеле инде
Ятка калдырганнарың.

Мәгънә бәйләнеше юкмы? Бар икән шул. Тегесе карлыганга бардым дигән икән дә, бармаган — чөнки карлыганы юк. Әһә, бу егет (кыз) шулай алдый ала икән. Болай булгач, билгеле инде... Беренче ике юл безне әнә шундый күңелсез хәлгә әзерләп куйды. Менә мондый эчке мәгънә бердәмлеген без халыкның меңләгән жырларында таба алабыз.

Әнә килә автомобиль
Төягәннәр ал сабын...

Утын да, чүлмәк тә, көлтә дә түгел, ә нәкъ менә ал сабын төягәннәр. Ниндидер матурлык, хуш ислелек, чисталык турында ассоциация туды. Нәрсә әйтмәкче икән бу жырчы?

Бер сагынмасаң, бер сагын,
Онытып бетермә тагын...

Алга таба китик. Автор битләр буенча (235—238) татар жырлары рифмалы булалар дип исбат итә (?!) Без инде моны ишетүгә мохтаҗ түгел ләбаса. Ә менә безнең жырларыбызда сурәтләү чаралары турында без тирәнрәк анализ көтәр идек. Әйтик, ни өчен мәхәббәт жырларында «былбыл» еш кулланыла? Нигә күгәрчен, тургай бик еш очрый? Матур сайраганнары өченме, әллә тышкы кыяфәтләре матургамы? Алай дисәң, былбыл (сандугач) нәкъ чыпчык төсле. Ә саескан бик матур кош, ләкин жырда юк. Кара костюм, ак нейлон күлмәк кигән маһабәт егет кебек — ләкин макталмый. Бәлки, хикмәт тавыштадыр? Алай дисәң, сыерчык та бик матур сайрый. Ә безнең жырларда аның исеме юк дәрәжәсендә. Моның хикмәте нәрсәдә? Боларны беләсе иде. Яки агачларны алыйк. Мәхәббәт жырларында алмагач, чия, канәфер, шомырт бик еш телгә алына. Чыршы, нарат, имән, усак — юк дәрәҗәсендә аз. Чәчәге матургамы, җимеше тәмлегәме тегеләр күп очрый. Алай дисәң, тал-тирәк? Ул нинди хасиятләргә ия? Нинди хисләрне белдергән жырларда тал-тирәк телгә алына? Ә зирек? Ни чәчәге, ни җимеше, ни утыны дигәндәй... Ә үзе шулкадәр еш, уңышлы кулланыла.

Тибрән, зирек, тибрән, зирек,
Бирмә талларга ирек.
Ятларга кул салганыңны
Сайрады кошлар килеп.

Никадәр нечкәлек, никадәр бөтенлек! Менә халык жырларындагы безгә билгесез, ләкин фольклорчыларга мәгълүм булырга тиешле шул нечкәлекләрне, аларның закончалыкларын күрергә иде. Х. Ярми китабының бу бүлегеннән укучы нәкъ әнә шуларны көтә икән, бу бер дә комсызлык түгел. Фольклористика фәнендә хәзер жырның эчтәлегенә комментарий түгел, ә шул юнәлештә этнографик — тарихи — лингвистик — поэтик анализлар кирәк.

Халык жырларындагы әдәби сурәтләү чараларыннан аллитерация алымы турында

без битле бик кызык хезмәт язып булыр иде. Укучының бу өметен дә, кызганычка каршы, автор акламаган. Без бу урында бер генә җырны мисалга китерер идек.

Ап-ак кына, вак-вак кына
Урманда куак кына...
Күпсенмәгез — күп тормабыз,
Без монда кунак кына.

Хыялыбызны җигик... Күрше авылдан җиенга килгән кунак егетләр менә ничә көн инде кәеф-сафа корып йөриләр. Көзгә рекрут буласылар икән. Тары утар вакыт җиткән, көннәр корыга китте. Шул кунак егетләр аркасында бөтен кызларның тәртибе чуалды, алар типтерә дип, бу авыл егетләре дә чыгырдан чыктылар. Инде кунак егетләргә аксакаллар сүз дә ишеттерделәр. Бу нинди эш бу, минсинайтим... Ә тегеләр көн үзәгендә сиртмәгә төялгәннәр дә урам уртасыннан теркелдәтеп тальянга җырлап баралар. Нәкъ сиртмәле арба сикерүе төсле...

Ак кына, вак кына, куак кына...

Менә бит фольклорчылар тикшерәсе нечкәлекләр!

Йомгак ясап шуны әйтик: Х. Ярми татар җырларын тематика, төзелеш ягыннан тикшереп бик файдалы эш эшләгән. Киләчәктә бу бүлек халык җырларының гомумән тарихын, әдәби сурәтләү чараларының закончалыкларын яктырту хисабына тирәнәйтелсә, хезмәт тагы да отышлырак булыр иде.

* * *

Китап «Совет чоры татар халык иҗаты» дигән җиденче бүлек белән тәмамлана. Бу бүлектә Ватан сугышы чоры фольклоры автор тарафыннан аеруча зур планда язылган. Әйе, Ватан сугышы тематикасы безнең фольклорыбызның барлык жанрларында да үтеп керде. Халык иҗаты, Тукай, Такташ әсәрләре белән берлектә, окопларда дошманны кыйнашты, ул оештыручы, җиңүгә өндәүче булды. Х. Ярми фольклорның әнә шул сыйфатларын ачык мисаллар белән күрсәтә алган. «Сугыш елларында иң нык таралганы җыр булды,— дип яза ул.— Халык күңелендәге хисләрне, уй һәм теләкләрне, аның көндәлек вакыйгаларга карата мөнәсәбәтен бик үтемле төстә әйтеп бирү өчен гаять унайлы һәм һәрвакыт аңлаешлы булган җырлар сугыш елларында халыкның күңел юанычы да, аны нык торырга, бирешмәскә өндәүче рухи корал да булды» (272 бит).

Х. Ярми бу бүлектә Ватан сугышы чоры фольклорын дүрт региональ группага бүлеп карый. Бу — фольклорчылар арасында гомуми кабул ителгән бер норма булса кирәк. Шулай да татар халык иҗатында партизан отрядларында туган фольклор һәм вакытлы рәвештә дошман кулы астында калган районнарда туган фольклор бар дип карау белән килешәсе килми. Соңгылары рус, украин, белорус халыклары фольклорына хас бүленеш булып, безнең фольклор өчен туры килми. Фольклор — зур тәшенчә, һәм берничә дистә җыр иҗат ителгән икән (автор аларның язып алынмаганлыгын үзе үк әйтә), бу әле татар халкында партизаннар отрядында туган фольклор бар дигән сүз түгел. Алай вакланга китсән, госпитальдә яткан сугышчылар фольклоры, яраланып авылга кайтучылар фольклоры һ. б. кисәкчәләргә мәгънәсез рәвештә бүлгәләргә булыр иде.

Дошманның кабахәтлеген фаш итү, җиңүгә ышаныч, Совет армиясенә, ватанга, партиягә мәхәббәт Ватан сугышы чоры фольклорының төп сыйфатлары булдылар. «Фронт белән тылның бер уй, бер теләк белән яшәве, фронт һәм тыл йөрәкләренең бергә тибүе җырларда үзәк мотив итеп сурәтләнде», ди автор (272 бит). Һәм монә мисал итеп үсеннәрдә башкарылган җырларны мисалга китерә. Мәхәббәт лирикасы бу чорда шулай ук дошманны җиңүгә ышаныч белән сугарылды. Х. Ярми боларны бик уңышлы мисаллар белән исбат итә.

Сугыш илебез халкы өстенә зур сынау булып төште. Сугыш — ачлык, ялангачлык, үлем иде. Ул йорт-җирсез, баласыз, ата-анасыз калу дигән сүз иде. Халкыбызның Ватан сугышы елларында никадәр авыр сынау үткәнлеген без еллар узган саен ачыграк, тирәнрәк аңлый барабыз һәм совет халкының бу чордагы гүзәл сыйфатларына сокланабыз. Ватан сугышында халкыбызның җиңү тарихы киләчәк буыннар өчен дә

зур тәрбия мәктәбе булып. Х. Ярминең Ватан сугышы фольклоры турындагы тикшеренүеннән әнә шул нәрсә аңлашыла. Әлбәттә, авторга бу бүлектә дә халык иҗатын киңрәк планда тикшерү мөмкинлеге бар иде. Мәсәлән, ул Ватан сугышы чоры фольклорында бары тик оптимистик, югары пафослы җырларны гына мисалга китерә. Халбуки, тол калган солдат хатыны, баласын югалткан карт-карчык, сугыш газапларын үз җилкәсендә кичергән хезмәт халкы дүрт ел буе гел югары пафослы җырлар гына җырлады дип карау халыкның рухи дөньясына игътибарсызлык булыр иде. Бөек Ватан сугышы турындагы тарихи тикшеренүләр, мемуарлар, ниһаять, соңгы елларда чыккан романнар, повестьлар халыкның бу чордагы рухи дөньясын киңрәк планда күрсәтәләр. Солдаткаларның ирләренә язган хатларында нинди генә җырлар булмый иде!

Һаваларда очып йөргән
Аэропланнар микән,
Бар кеше дә безнең кебек
Аерым торалар микән?

Аклы күлмәкләр тектердем
Гел көрән булмасын дип.
Шиңгән гөлләргә су сибәм
Безнең күк булмасын дип.

Болар ирсез калган яшь солдатканың, халык әйткәнчә, «йөрәгеннән кайнап чыккан» кайнар хисләре иде, ул җырлардагы сүзләр солдатканың халәте рухиясенә туры килә иде. Боларны нигә исәпкә алмаска? Болар да бит пессимистик җырлар түгел! Халык күңеле — диңгез бит ул, анда сагышка, кайгы-хәсрәткә нигә урын булмасын?

Яки менә шундый хәлне күз алдына китерик.

Фәлән хатынның ире сугышта хәбәрсез югалды. Күз яшьләре кипкәннән соң, яшь хатынның күңелендә икенче бер кешегә карата җылы хис бөреләнде. Кем гаеп итә ала аны, кеше бит ул! Ләкин бераздан хатынның үз ире исән булып чыкты. Чолганышта яткан икән... Менә яшь хатын үз хәленең бөтен трагедиясен белеп йөри. Кырда арыш урганда үзенең учмаларын салган көйгә генә җир башыннан аның моңлы тавышы ишетелә. Җирен үлчәргә килгән бригадир аның җырын тыңлап бер читтә туктап кала.

Минем бәгырем кайтыр әле
Военный атлар белән лә,
Военный атлар белән.
Ул кайтса да миңа булмас,
Чуалдым ятлар белән...

Күренгәнчә, тыл фольклорын тикшергәндә халык күңеленең әллә нинди нечкәлекләренә керергә, өйрәнергә мөмкинлекләр бар икән. Әйе, Ватан сугышы чоры фольклоры ул клубларда түгәрәк уены җырлары гына түгел, ул — урак җирендәге тол хатыннарның күлтәләр белән аралашкан моңы, кичләрен бер-берсенә җыйналып яшь сыккан солдаткаларның йөрәк сере, кышкы озын төннәрдә йокысыз ятып, теләк теләгән аналарының иксез-чиксез хәсрәтенә уралган бәетләре, сагышы... Боларны өйрәнергә, эзләнергә, халык рухына керергә иде...

* * *

Х. Ярминең бу китабы халкыбызның авыз иҗатына күпкырлы анализ буларак фән өлкәсендә бер китапка тупланган беренче тәҗрибә. Шуңа күрә монда бәхәсле мәсьәләләр, теләкләр булуы бик табигый. Фольклористика — математика түгел, монда бик күп мәсьәләләрне укучы күрергә теләгәнчә төгәл кистереп әйтү мөмкинлеге юк. Шуңа күрә, югарыда телгә алынган кимчелекләр һич тә бу зур хезмәтнең культура тарихыбыздагы әһәмиятен киметә алмыйлар. Безгә алга табарак халкыбыз иҗатындагы аерым жанрларының киләчәк язмышы турында да сүз алып барырга кирәктер, ахрысы. Х. Ярминең бу зур фәнни хезмәтенең соңгы битен япканда киләчәктә бу галим әнә шул мәсьәләне дә безнең алда актыртып чыгар әле дигән өмет белән калабыз.

Гомәр Бәширов

# БЕЗ КЕМ ИДЕК, КЕМ БУЛДЫК?

«Туган ягым — яшел бишек» («Казан утлары» журналының 1967 елгы 5—8 һәм 11 саннарында басылды) повесте укучы һәм язучылар арасында төрле фикерләр уятты. Әсәргә уңай бәя бирүчеләр белән бергә, арада аны бик үк ошатып җиткермәүчеләр дә чыккалады. Кайберәүләр әсәрнең жанры турында бәхәсле фикерләр әйттеләр. Икенче берәүләрне аерым образларның бирелеше канәгатьләндереп җиткермәде. Шул сәбәпле журнал редакциясенең түгәрәк өстәле янында әсәрнең язылуына, аның жанрына һәм эчтәлегенә бәйләнешле мәсьәләләрне уртага салып сөйләшү, кайбер аңлатмалар бирү кирәк дип уйлаштык.

Әсәргә карата тәнкыйть фикерләренең күбесе журналның шушы саннарын тикшерүгә багышланган махсус җыелышта әйтелгән. Ул турыда «Казан утлары»ның 1968 елгы 1 санында язылды. Кызганычка каршы, мин ул көннәрдә Казанда юк идем.

Аяз Гыйләҗев, мәсәлән, болай ди: «Гомәр абзыйдан яхшы әсәр көткәнгәдерме, миндә әсәр канәгатьсезлек хисе калдырды». Моның сәбәпләрен А. Гыйләҗев болай аңлата: «Г. Бәшировның бу автобиографик повестенда мин авторның үзен күрмим. Ул чордагы вакыйгалар аңа ничек тәэсир иткән? Боларны мин күрмим... Миңа иң тәэсир иткән кеше Фазулла. Ләкин ул да югалып кала».

Барлас Камалов та шул ук фикергә кушыла яза. Шулай да ул бераз «рәхимлерәк». «Тел ягыннан, халыкның рухи байлыгын бирү ягыннан, образлар ягыннан чыннан да әсәргә сүз әйтеп булмый. Әмма... укыган өлешеннән язучының үзе күренә башлавын көткән идем мин».

Ихтимал, моңа әсәрнең журналда кыскартылып, яртысыннан бик аз гына артыгагы басылуы да сәбәп булгандыр. Чөнки әсәрне кыскартып басканда, билгеле бер бөтенлек һәм эзлеклелек саклау бик кыен булды. Шул ук сәбәп нәтиҗәсендә, мәсәлән, журнал вариантында Фазулла да бер генә мәртәбә күренеп калды. Хәлбуки, әсәрнең ахырына таба ул әле тагын берничә мәртәбә мәйданга чыга һәм, минемчә, ярыйсы ук ачыклана төшә. Әсәрнең соңгы өлешенә таба, үсмер яшенә җиткәннән соң, шулай ук Гомәр исемле малай да вакыйгаларның үзәгенә кереп бара, миңа калса, ул да төрле ягы белән һәм ачыграк күренә башлый. Ләкин анда да Б. Камалов теләгән канәгатьләндерү мөмкин түгел иде. Чөнки ул авыл малаена язучы булганчы бик күп дөнья күрергә, утлар, сулар кичәргә кирәк иде әле.

Бу әсәр шушы елның ахырына таба Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып тулысынча басылып чыгачак. Шул китапны рәхим итеп укып чыга алсалар, иптәшләрнең югарыда әйтелгән канәгатьсезлегенә, шәт, урын калмас дип уйлыйм.

Аяз Гыйләҗевка, күрәсең, халыкның эчке тормышын, аның борынгыдан килгән төрле гореф-гадәтләрен киңрәк планда, эзлекле рәвештә тасвирлап бирү дә ошамаган булса кирәк. Әлеге җыелышта бу хакта сүз кузгалгач, ул шундый сорау куя: «Алай булгач, ник соң ул этнографик новеллалар язмаган? Ник автобиографик повесть дип куйган?»

Бердән, әдәби әсәрдә тегә яисә бу элементның азмы, күпмә булуын беркайчан да метрлап яки килограммлап үлчәп булмый. Ул язучының үзалдына нинди максат куюына да, осталыгына да, хәтта характерына да бәйләнешле мәсьәлә. Шуның өстенә, бу зәвык мәсьәләсе дә. А. Гыйләҗевкә ошамаган шул ук этнографик детальләрне бик яратып укучылар да күп булды.

Шулай да ни сәбәпле мин бу әсәремдә халыкның гореф-гадәтен, аның эчке культурасын тулырак күрсәтергә тырыштым икән соң? Бу сорауга тәфсиллерәк җавап бирергә телә́р идем.

Беренче сәбәп. Мин Көнбатыштагы кайбер «ультра яңача» язучы әдипләр кебек, хәзерге заман героен җирсез һәм илсез, милләтсез һәм мәсләксез итеп, кыскасы, үзенең халкыннан да, аның культурасыннан да ваз кичүче ниндидер нигилист-космополит итеп күрсәтү белән һич килешә алмыйм. Кеше үз мохитында матур, ул үз җирлегендә, үз халкының улы итеп күрсәткәндә генә тулысынча ачыла. Кеше кадәр кешене, табигатьнең күзе өстендә кашы булган шушы гали затны җир-суыннан, халкына хас сыйфатларыннан, үз мохитыннан азат итеп күрсәтү андый әсәрләрдә аны роботка охшаш чикләнгән бер примитивка әверелдерә. Ихтимал, бу әсәргә минә шушы карашымның йогынтысы булгандыр.

Моның икенче сәбәбе дә бар.

Мәгълүм ки, без халыклар дуслыгы җәмгыятьнең этәргеч көченә, аның мөкатдәс бер принцибы дәрәҗәсенә күтәрелгән илдә яшибез. Бу дуслык бары тик коры лозунг кына булмаска тиеш. Дуслык хисе бер-береңә тирән ихтирам нигезендә генә көннән-көн ныгый барырга мөмкин. Кем булуың, ничек яшәвен, нинди үзенчәлекләре булуын бөтенләй белмәгән халыкны чын-чыннан дус һәм ихтирам итү мөмкинме?

Хәлбуки, мең еллар буе Россиянең уртасында яшәвебезгә карамастан, татарларны әле һаман да бик аз беләләр. Моның шулай икәнлеге кайбер кинофильмнарда һәм дәреслекләрдә аеруча күзгә бәрелә.

Инде чит илләргә килгәндә, анда безне бигрәк тә начар беләләр. Өлкән язучыбыз Афзал Шамов сугышның соңгы елларында Польшаның бер шәһәрендә шундый бер мәзәк хәл булуын сөйли. Ул, Совет армиясенең офицеры сыйфатында, татар газетасында эшләүче хәрби иптәшләренә квартиралар кайгыртып йөри. Шунда аннан: «Безгә теләсә кемне квартирага куегыз, ләкин зинһар өчен татарларны гына куя күрмәгез!» дип үтенәләр. Чөнки алар карашында татарлар иң кыргый һәм иң еркыч халык икән. Моның һәм иптәшләренең татар икәнлеген белгәч, поляклар хәйран калалар.

Менә тагын бер мисал. Өченче ел Чехословакиянең Карлова Вары курортында безгә, совет язучыларыннан Евгений Поповкинга, Рәсул Гамзатовка, миңа һәм тагын бер-ике иптәшкә, төрле ил кешеләре җыелган әдәби кичәдә катнашырга туры килде. Мин Муса Җәлил турында һәм Көнбатышта кайберәүләрнең роман жанрына җеназа уку белән мәшгуль булулары турында сөйләдем. Бездә исә бу жанрның чәчәк атуы турында мисаллар китердем. Кичәдән соң безнең янга килгән Австрия кешесе белән бер француз үзләренең бик гаҗәпләнүләрен әйттеләр. «Без татарны Себер урманнарында яшәүче ярым кыргый бер кабилә дип белә идек. Татардан Муса кебек батыр шагыйрь чыгуы, татар язучысының Европа уртасында романны яклап сөйләве безнең өчен көтелмәгән хәл», диделәр.

Мондый «сюрпризларны» башка вакытта да еш кына очратырга туры килә.

Яисә менә хәзерге көндәлек тормышыбызны алыйк. Газета битләрендә булсын, радио тапшыруларда булсын, Татарстан нефте турында аз ишетмибез. Кайвакытта хәтта «Дружба» нефть үткәргеченең Миңлебай авылы яныннан башланып китүен дә телгә алгалыйлар. Ләкин ул Миңлебайда һәм аңа охшаган йөзләрчә авыл һәм шәһәрләрдә яшәүче шул татар дигән халык ниндирәк? Ул ничек яши, аның нинди гореф-гадәте, үзенә хас нинди сыйфатлары бар, культурасы ниндирәк баскычта тора? Менә ул яклары, кызганычка каршы, әле һаман да укылмаган китап булып кала. Әгәр татар халкы тормышыннан кинофильмнарның бөтенләй булмавын, безнең бу тармакта берни дә эшләмәвебезне дә искә алсак, мәсьәлә тагын да ачыклана төшәр.

Менә ни сәбәпле бу әсәремдә халыкның эчке тормышын киңрәк күрсәтергә омтылдым. Бу әсәрне язганда мин шушы китап ярдәмендә татарның көмлеге белән башка халыкларны да таныштырып булмасмы икән (русча тәрҗемәсе аша, билгеле),

бу китап халыклар арасындагы дуслыкны тагын да ныгыта төшәргә ярдәм итмәсме икән дигән уй белән яшәдем.

«Моның өчен төрле белешмәлекләр бар бит» дип, минем бу дәлилемнә кире кагарга теләүчеләр дә булырга мөмкин. Дөрес, андый белешмәлекләр дә бик кирәк. Ләкин халыкның рухи дөньясын, аның эчке культурасын аңлау өчен коры саннар гына һич тә җитми.

Халыкның эчке культурасы... Моны ничегрәк аңлатырга икән?

Әйтик, дөньяның «тоткасы» һәм нигез ташы, яшәешнең төп этәргече булган эш, хезмәт бар, яшәү өчен көрәш бар, боларның һәммәсен дә үз эченә сыйдыра торган иҗтимагый тормыш бар. Әмма халыкның шушылар белән аралашып, бөтенләй үзенчәлекле бер өлеше кебек, бергә үрелеп баручы үз эчке тормышы, борынгыдан бирле гел үзгәрә һәм камилләшә килгән үзенә генә хас гореф-гадәте, аның уңай һәм тискәре күренешләре, үз психологиясе, тормыш фәлсәфәсе һәм, ниһаять, мең еллардан бирле саклап, үстереп, камилләштереп килгән үз теле бар. Боларга тагын халыкның башка ысуллар белән аңлашып булмастай иң катлаулы, иң эчкәрге һәм иң газиз уй-тойгыларын сурәтләп бирүче үз шигърияте, музыкасы һәм эстетик зәвыгы килеп өстәлә. Минемчә, халыкның халык буларак нинди югарылыкта торуын, аның рухи байлыгын, эчке матурлыгын формаль белешмәләргә караганда матур әдәбият һәм сәнгать тулырак күрсәтә ала. Көчем җиткәндерме, юктырмы, бераз гына булса да мин әнә шул эчке байлыкны күрсәтергә тырышып карадым.

Кардәш халыкларга күршеләрен белү кирәк икән, нигә хәзерге урта һәм яшь буынга үз туган якларын, халкының гореф-гадәтен белергә кирәк булмасын икән? Бу хакта рус әдәбиятының танылган тәнкыйтьчесе Вера Смирнова күптән түгел генә ифрат дөрес һәм тирән мәгънәле акыллы фикер әйтте: «Туган җиреңне сөймичә, туган табигатеңне үз итмичә, халкың белән тыгыз элемтәдә булмыйча, туган телеңне белмичә һәм күңелеңдә халкың белән горурлану хисе булмыйча торып яңа тормыш коручы да, кешеләр бәхете өчен көрәшче дә, башка халыкларның дуслары булу да мөмкин түгел».

Аяз Гыйләҗевнең тагын бер искәрмәсенә җавап бирергә кирәк, ахрысы. Шул ук чыгышында ул мондый фикер дә әйткән: «Аннары әсәрдә инде әдәбиятта сурәтләнгән вакыйгалар да бар. Әйтик, тегүче турында Ф. Хөсни язган иде инде».

Никадәр тырышып эзләп карасам да мин «Туган ягым — яшел бишек»тә моңарчы әдәбиятта сурәтләнгән «вакыйгаларны» таба алмадым. Чөнки андыйлар юк. Бәлки А. Гыйләҗев «безнең әдәбиятта тегүче образы моңарчы булган иде инде» дип әйтергә теләгәндер? Менә монысы дөрес, ул чыннан да шулай. Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы»нда читтә йөреп тегүчеләр аңа хас осталык белән иста калырдай итеп сурәтләнгән. Ләкин ул бит бөтенләй башка мохит, бөтен төрле яшәеш, башка образлар. Ул Сафәргали белән аның атасына хас дөнья. Анда минем әсәремдәге Ямашурма авылы да, зимагур да, Сафа агай да, Мәзгумә да, бүтәннәр дә юк. Мин берәүне дә кабатламыйм шикелле. Алайга китсә, әдәбиятта балта осталары, тракторчылар, комбайнчылар, укытучылар турында да күп язылды, әле һаман да язылып килә. Ләкин бу бит әле андый һөнәрләр турында бүтән язарга ярамый дигән сүз түгел. Хикмәт ничек язуында. Әгәр язучы элеккене кабатламыйча, үзенчә күреп, үз образларын бирә икән, бу кимчелеккә саналмаска тиештер, бәлки аның әдәби кыйммәте турында гына сүз булырга мөмкиндер.

Үз авылың һәм үзеңә якын кешеләр тормышы турында сүз барса да, билгеле, утырдың да яздың да ташладың гына түгел. Әдәби әсәр иҗат итү ул күп уйлану, халык тормышына бәйләнешле күп төрле мәсьәлә һәм сорауларга җавап бирү дигән сүз.

Шундый мәсьәләләрнең берсе — кайбер кешеләрнең революциягә кадәрге татар халкын, чыны ничек булуын тарихның үзеннән өйрәнеп тормастан, ни сәбәпледер, тоташ надан һәм томана итеп күрсәтергә тырышулары. Без бит реалистлар. Бөек Ленин тәгълиматы безне һәр эштә гадел һәм тугры сүзле булырга өйрәтә. Аерым кешеләргә ошавына яки ошамавына, фәлән ситуациягә шулай кирәк булуына карап кына тарихны «төзәтеп» күрсәтү нигә кирәк, аннан ни файда? Киресенчә, ул кайберәүләрдә мескенлек хисе һәм нигилистлык тууга сәбәп була.

Мәгълүм ки, патша хөкүмәте татар авылларында мәктәп ачтырмады, хәтта, кире-

сенчә, татарча укыткан өчен элек-электән әзәрлекләп килде, халык ачкан мәдрәсә һәм мәктәпләрне көчләп яптырды. Тарихта 1744—1755 еллар эчендә генә дә хөкүмәтнең Казан губернасында 418 татар мәктәбен җимертүе билгеле[1]. Ләкин тагын йөз ел узганнан соң, 1858 елда Казан губернасында гына да мәктәпләрнең саны 430 га, мәдрәсәләр саны 50 гә җиткән була[2]. Зуррак авылларның байтагысында, мәсәлән, Байлар Сабасы, Кышкар, Түнтәр, Мәңгәрдәге мәдрәсәләр XVIII нче гасыр башында ук ачылган булалар. Башка губерналарда да мәктәп һәм мәдрәсәләр аз булмаган. Әгәр аларның кайберләрендә 200—300 шәкерт укуын искә алсак, ул заман өчен моның кечкенә сан түгел икәнлеген танымыйча мөмкин булмас. Дөрес, аларда кадимчә укытканнар. Шулай да мәдрәсәдә 5—6, хәтта 10 ел укып гарәп һәм фарсы телен, мантыйкны h. б. белеп чыккан шәкертләрне, шәт, наданга санап булмыйторгандыр бит?

1905 елгы беренче рус революциясеннән соң исә халык үзенең аң-белемгә сусавын тагын да дәртләнебрәк канәгатьләндерергә кереште. Аңарчы яшәп килгән мәдрәсәләрдән тыш авыл саен яңа мәктәпләр ачып, халык аларда да балаларны элеккечә үк үз исәбенә укытты. Һәрхәлдә, XX нче гасыр башында, бигрәк тә Бөек Октябрь революциясе алдыннан, яшьрәк буын арасында бөтенләй надан калучылар күп түгел иде.

Шулай ук татар хатын-кызлары да тоташ надан булмады. Мәгълүм тарих галиме һәм этнограф мәрхүм Н. О. Воробьев китергән мәгълүматларга караганда, 1897 елда укый-яза белүче һәр 100 ир кешегә 93 тән артык укый-яза белүче хатын-кыз туры килгән[3].

Халык арасында бәетләрнең күп иҗат ителүе, аларның бер дәфтәрдән икенчесенә күчерелеп, буыннан-буынга тапшырылып килүе дә, моннан алты-җиде йөз ел элек язылган кайбер әдәби әсәрләрнең утыздан артык күчермәсе саклануы да халыкта укый-яза белүчеләрнең аз булмавы турында сөйләмимени?

Революциягә кадәрге халыкны үтә надан га санаучылар моның кайвакыт дошман тегермененә су коюы икәнлеген онытып җибәрәләр. Билгеле булганча, патша заманында байлар, морзалар хезмәт иясе халыкны мыскыллап, гадәттә, «кара халык, кара сарык», «кара мужик» дип атыйлар иде. Аларның чит илләрдәге калдыклары башка көйгә җырласалар да, асылда хәзер дә шул ук җырны кабатлыйлар. Алар шуңа нигезләнеп хәтта Бөек Октябрь революциясенә тел-теш тидерүдән дә тайчынмыйлар. Аларның раславынча, имештер, Октябрь революциясе тарихи яктан һич тә зарури бер хәл булмаган, бәлки аны очраклы шартлар гына китереп тудырган. Чөнки, имештер, ул елларда әле Россия халкы революциянең нәрсә икәнлеген дә аңлый алмаслык дәрәҗәдә надан һәм томана булган, э революцияне, имештер, бер төркем большевиклар халыкка көчләп такканнар...

Бу нигезсез сафсатага мин, революция көннәрендә алпавыт биләмәсен тузгытуга катнашучы, алпавыттан тартып алган җиргә үзебезнең казыкларны кагучы бер крестьян малае буларак, китабымда болай диебрәк җавап бирергә тырыштым:

— Юк, әфәнделәр! Октябрь революциясенә, большевиклар җитәкчелегендә, барлык хезмәт иясе катнашты. Чөнки элек изелеп яшәгән халыкларның милли азатлык өчен көрәшләренә революция сулышы дәрләп торган ялкын өстәде. Шунлыктан минем якташларым, Казан арты игенчеләре, революция көрәшенә Мәскәү һәм Казан белән бер үк көннәрдә күтәрелеп чыктылар. Бу хәл үзе үк халыкның иҗтимагый аңы да, гомуми культурасы да түбән булмауны расламыймыни? Надан халык шундый катлаулы һәм чуалчык шартларда иң тугры һәм бердәнбер дөрес юлны шулкадәр тиз һәм икеләнмичә сайлап ала белер идемени? Милли азатлык өчен көрәш идеясеннән һәм гомумән политикадан ерак торган халык гражданнар сугышы елларында революция казанышларын саклап калыр өчен шундый тиңсез фидакарьлек һәм каһарманлык белән көрәшер идемени?

Бу хакта без горурланып яза алабыз. Чөнки бу халкыбызның туган илнең революцион тарихына керткән иң мактаулы һәм ихтирамга лаеклы бер өлеше. Бәкер Белоусов, Йосфый, Әхтәмов, Мулланур Вахитов, Якуб Чанышев, Шамил Усманов һәм

---

[1] «Татары среднего Поволжья и Приуралья», Москва, 1967 г. Стр. 378.
[2] Шунда ук. 380 бит.
[3] «Казанские татары», Казан, Таткнигоиздат, 1953 ел. 53 бит.

йөзләгән башка каһарманнарның тиңсез батырлыгы әле һаман да үзләренең язучыларын көтәләр.

Тагын бер мәсьәлә.

Фикер алышу вакытында «Туган ягым — яшел бишегемнең теленә җил-яңгыр тимәде тиюен. Шулай да, кайбер иптәшләрнең әйтүенчә, аңлашылып җитмәстәй сүзләр әсәрдә сирәк булса да очраштыргалый икән. Күрәсең, бу хәл әсәрне моннан ярты гасыр элек булган һава белән сугарырга, әсәрдә катнашучы кешеләрне үз заманының телендә сөйләтергә тырышудан килә торгандыр. Әмма мондыйрак әсәрдә шунсыз мөмкин түгеллеген искә төшерер идем. Табигый, әсәрне шул заман сулышы белән сугару, баштан узганнарны ул заманга хас мохитта итеп тасвирлау өчен авторга, ярты гасыр артка чигенеп, алпавытлар хөкем сөргән чакка, комбайннар, телевизорлар дөньясыннан сукалы-тырмалы, оек-чабаталы яшь чагыбызга кире кайтырга, шул заман теленә яңадан колак салырга ихтыяҗ чыкты. Хәзерге авыл халкының күпчелеге әдәби телдә диярлек сөйләшә. Моннан 50—60 ел элек исә авыл кешесенең, бигрәк тә халыкның керәшен дип йөртелгән өлешенең, Бикәби һәм Кирушларның теле ифрат та үзенчәлекле яңгырый иде. Күрәсең, керәшеннәр теленә көнчыгыштан килгән гарәп һәм фарсы сүзләре күп керә алмаганлыктан, аларда борынгы тел элементлары күбрәк саклангандыр. Ләкин бу ярты гасыр эчендә әдәби телебез дә, халык сөйләме дә шундый үсте, шулкадәр баеды һәм үзгәрде ки, хәзер инде Бикәбиләр теле анахронизм булып яңгыраса, һич гаҗәп түгел.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар.

Әсәрнең телен эчтәлек, композиция һәм сюжет кебек үк иң җитди һәм хәлиткеч компонент итеп караучы һәр әдип зур әсәр язарга керешкән саен, үзенә ифрат җаваплы бер сорау һәм талап куя: син бу әсәреңдә халкың бишектә чагында ук өйрәтә башлаган үз ана телеңә нинди яңа бизәкләр өстисең, аны укучыга тагын да баетыбрак кайтару өчен ниләр эшлисең?..

Моңа кадәр язылган мәкаләләремдә әйтелгәнчә, мин әдәби телебез барыннан да элек һәм беренче нәүбәттә халыкның үз сөйләм теленнән кергән яңа сүзләр исәбенә баерга тиеш дигән карашта торам. Минемчә, әдәби телләр үсешендә бу иң прогрессив һәм бердәнбер табигый юл. Үзен-үзе ихтирам итә торган телләр нәкъ менә шушы юл белән үсәләр. Әгәр кайсы да булса бер шивәдә (диалектта)— мишәрдәме, Казан артындамы яки элек керәшен дип йөртелүчеләрдәме, моңарчы әдәби телдә булмаган кирәкле бер төшенчәне аңлатырга сәләтле сүз килеп чыга икән, нигә аны әйләнешкә кертеп җибәрмәскә?

Шул караштан чыгып мин бу әсәремдә әдәбиятта бик сирәк очраган яки бөтенләй булмаган сүзләр дә кулландым. (Мәсәлән, раван, тияк, соян). Тегe яки бу фикернең яисә төшенчәнең халыкча әйтелешен, халыкча тәгъбирен дә биргәләдем. (Мәсәлән, күплек формасы: т а н ы м ы й л а р да торам, т а у л а р шуды, к и ч л а р утырды h. б.). Гомумән, халыкның поэтик сүзлеген, тел кагыйдәләре сыйдыра алган кадәр күбрәк, киңрәк кулланырга тырыштым. Ләкин кабатлап әйтәм, бу үзмаксат түгел, бәлки әсәрнең эчтәлеге шуны сорый иде. Әгәр кайбер сүзләр яки әйтелешләр соңыннан әдәби телгә кереп китә алмыйлар икән, үпкәләштән булмас. Алар үз вазифаларын үтәп, автор әйтергә теләгәнне укучыга чәчми-түкми җиткерә алсалар, мин шул кадәресенә дә шат булырмын.

Шул рәвешчә, бу әсәрне мин «Без кем идек һәм кем булдык?» дигән сорауның беренче өлешенә җавап итәрәк яздым. Җавабым канәгатьләндерерме, юкмы, анысын укучы әйтер, киләчәк күрсәтер. Инде бу сорауның икенче өлешенә тулы һәм ачык җавапны, бүтән китаплар чыкканга кадәр, укучы тормышның үзеннән табар дип уйлыйм.

Фикер алышуда катнашучыларга һәм әсәр турында фикерләрен хатлар аша белдерүчеләргә чын күңелдән зур рәхмәт.

◊ ◆ ◊

**Нәби Дәүли**

# ОЛЫ ЮЛГА ЧЫККАНДА

Соңгы елларда татар совет әдәбиятына талантлы, эшкә сәләтле яшьләр килде. Бигрәк тә поэзиядә без күп кенә үзтавышлы яшь шагыйрьләр белән очраштык. Алар үзләренең беренче әсәрләре белән үк укучыларның игътибарын яулап алдылар. Тагын шунысы шатлыклы, бу яшьләр оядан чыгуга ук: «Карагыз, менә мин киләм!» дип әтәчләнмичә генә, «мин талант» дип үз исемнәренә атап ода җырламыйча гына шигърият мәйданына килеп керделәр, сафка бастылар һәм алгы елларга карап юлга чыктылар. Хәерле сәгатьтә булсын! диясе килә аларга.

Заманында шулай да булгалый иде бит. Кемдер ашыга-ашыга кулына каләм ала да шатыр-шотыр поэма язып ташлый. Беренче әсәр буларак, бу поэма дигән нәрсә хәтта кемнәргәдер ошап та куя, кемнәрдер аның авторына зур өметләр баглыйлар, аңа мактау сүзләрен әйтүдән дә тартынмыйлар иде. Шундый зур «шедевр» иҗат иткән кеше ахырдан «вак-төяк» шигырьләр язып та маташмый иде. Ни өчен? Чөнки ул андый шигырьләрне яза белми иде. Һәм озак та үтми, без ул «авторны» бөтенләй оныта да идек. Килгәндә бик нык дөбердәсә дә, киткәндә ул мыштым гына сыза иде. Һәм бик яхшы итә иде, әлбәттә. Бәлки, инде ул кулына башка һөнәр алгандыр да, бик җайлы гына эшләп гомер итәдер. Без аңа да үз эшендә уңышлар телибез. Аңа да хәерле сәгатьтә дибез.

Кечкенә күләмле шигырьләрне «вак-төяк» эш дип караучылар тирән ялгышалар. Булачак шагыйрь үзенең иҗатын әнә шул кечкенә генә шигырьләрдән башларга тиеш тә инде. Бу бердәнбер дөрес һәм ышанычлы юл, дип әйтер идем мин. Исегезгә төшерегез, булачак рәссам алдына беренче дәрестә бары тик ак балчыктан ясалган дүрт почмаклы шакмак кына куялар. Баксаң, һәр кыры тигез булган бу шакмакны кәгазьгә дөрес төшерүләре генә дә ай-һай кыен икән. Бу дәрестә «бишле» алучы шәкертләр күп булмый диләр. Шакмакны дөрес, тәгәл итеп рәсемгә төшерергә өйрәнгәннән соң гына, бу өйрәнчекләр алдына тагын шул ук ак балчыктан ясалган я бер бармак, я бер колак китереп куялар. Шулай итеп яшь рәссамнар, кеше гәүдәсенең аерым әгъзаларын рәсемгә төшереп, еллар буенча үзләренең кулларын осталыкка, күзләрен зирәклеккә күнектерәләр. Аннан соң натюрмортлар, натурадан пейзажлар башлана. Ә портретлар, композицияле рәсемнәр, этюдлар инде бу кешеләрнең башларында сирәк-мирәк кенә көмеш укалар күренә башлагач кына пәйда була.

Үзенең табигате белән дә, тәсмерләү, сизенү һәм фикерләү үзенчәлеге белән дә поэзиягә бик якын торган рәсем сәнгатенең осталары әнә шулай дөньяга киләләр. Минемчә, булачак шагыйрьнең дә үсеш юлы шундый четерекле һәм авыр. Хәер, теләсә нинди сәнгатьтә, теләсә нинди һөнәрдә дә кеше шундый баскычларны узып кына осталыкка күтәрелә ала. Әйе, башта рәссамга — шакмак, шагыйрьгә — кечкенә шигырь, җырчыга — до-ре-ми-фа-соль!

Бу хакта ни өчен яздым әле? Сүз бит яшь шагыйрьләр турында барырга тиеш иде. Соңгарак бу аңлашылыр дип уйлыйм. Чөнки әлеге яшь авторларның беренче китапларын укып чыккач та, минем күз алдыма бик тырыш, тыйнак шәкертләр килеп басты. Чыннан да, инде нык әзерләнеп, кирәк белемне туплаганнан соң гына

һәм моңа кадәр байтак шигырьләр яза-яза кул җайландыргач кына, алар үзләренең шигырь дәфтәрләрен безнең алга ачып куйдылар.

Шундый шагыйрьләребезнең берсе — Г. Рәхим, икенчесе — Т. Камалиев, өченчесе — Ф. Шәфигуллин. Билгеле, тагын башкалар да бар әле. Әмма бу юлы мин, инде югарыда әйткәнчә, әнә шул өч яшь автор турында гына берничә сүз әйтмәкче булам.

Быел бу яшь шагыйрьләрнең «Карлыгачлар»[1] оясыннан очып чыгып, беренче китапчыклары безнең кулларыбызга килеп кунды. Әйе, беренче карлыгач — беренче китап. Моның яшь автор өчен нинди шатлык, нинди зур бәхет икәнлеген мин үз йөрәгем белән аңлыйм. Заманында, үземнең дә беренче китабым чыккач, башым күккә тигән кебек булган иде.

Әмма ул шатлык кайбер очракларда шактый авыр борчулар да алып килә. Бу, гадәттә, ашыккан шагыйрь белән була. Атна-ун көн дә узып өлгерми, ул карлыгачны тәнкыйтьче тотып алып, йоннарын йолка башлый һәм: «Карагыз, бу карлыгач түгел. Бумы? Бу — кара карга!» дип әйтә дә сала.

Ләкин Г. Рәхимне дә, Т. Камалиевны да һәм Ф. Шәфигуллинны да мондый куркыныч көтми. Чөнки бу яшь шагыйрьләр бары язар өчен генә язмыйлар. Алар поэзия алдында торган бурычларны яхшы аңлап эш итәләр. Барысыннан да элек, авторлар нәрсә турында язарга кирәклеген беләләр. Бу — иҗат кешесе өчен беренче шарт.

Чыннан да, шигырь белән теләсә нәрсә турында каләм тибрәтеп булмый. Шагыйрьнең үз темасы булырга тиеш. Ә ул тема нинди? Аны ничек табарга? һәм тагын: ул тема кешеләрне дулкынландырамы? Ул әсәр кирәкме? Авторны борчыган мәсьәләләр башкаларны да борчыймы? Моны кайдан белергә? Менә бу урында яңадан рәссамнәр төшерә торган әлеге шакмакны искә алырга туры килә. Өйрәнергә, укырга, үз заманыңның белеме белән, идеяләре белән коралланырга! Ачкыч менә шунда. Бу ачкыч бу өч яшь шагыйрьнең кулларында инде. Шунысы шатлыклы, безнең башка яшь шагыйрьләребез дә поэзиягә югары уку йортларының бусагаларын үтеп киләләр. Мондый бәхет олы буын шагыйрьләренең күбесенә татымады. Аларның яшьлекләре фронтларда, гражданнар сугышында, төзелеш мәйданнарында узды. Аларны яңа туып килгән чор үз бишеге янында тотты. Аларның яшьлекләре революция тарафыннан мобилизацияләнгән иде. Бу мәсьәләдә хәзер җир белән күк арасы. Шуңа күрә дә, безнең яшь авторларыбызның әсәрләрендә культуралылык, җыйнаклык, эзләну үзен сиздереп тора.

Г. Рәхим дә эзләнә һәм таба. Ул беркемне дә кабатларга теләми. Яшь шагыйрь һәрбер шигыренә диярлек үзенә хас форма булдыра. Шуны да әйтик, ул, кайберәүләр кебек, форма белән генә мавыкмый, форманы идеягә, әсәрнең эчтәлегенә буйсындыра. Шуңа күрә бу яшь авторның шигырьләрендә форма кычкырып тормый, ул үзен сиздерми дә хәтта. Беренче чиратта фикер! Г. Рәхим менә шул турыда кайгырта.

Без, тема дидек, әмма мәсьәләне бер тема гына хәл итми әле. Шагыйрьнең позициясе кайсы якта? Ул кемне яклый. Кемгә хезмәт итәргә тели? Бездә бу мәсьәлә ачык. Без Ленин идеяләре белән тәрбияләнгән кешеләр. Димәк, шул идеягә тугрылык шагыйрьнең позициясе, эш мәйданы, йорты, туган туфрагы булырга тиеш. Г. Рәхим моны ачык әйтә. Яшь шагыйрьнең «Буыннан буынга» дигән кечкенә генә бер шигырен укып үтик.

Бабам сөргән.
Хәлдән таеп сөргән.
Ул тәм табып сөргән.
Буразнага ятып җан биргән,—
Туймаганга туган җирдән.

Атам сөргән.
Штык белән йөргән.
— Фашистларга тиздән
Үлем килер дигән.
Танк астына кергән,—
Туймаганга туган җирдән.

Киерелеп эшлим,
Тир таммасын димим.
Кирәк булса,
Кан да тамар миннән.
Бабам бетермәгән
Буразнаны сөрәм,—
Туймаганга туган җирдән.

Бу бер кеше, бер автор — Г. Рәхим әйткән сүзләр. Әмма бу шигырь астына илен, туган җирен яраткан һәркем үз имзасын бер дә икеләнмичә куя ала. Чөнки бу юллар безнең заман кешесенең узганы, хәзерге көне һәм киләчәге турында сөйли-

---

[1] Татарстан китап нәшрияты яшь авторларның шундый исемдә шигырьләр җыентыгын чыгарды.

ләр. Ни әйтерсең, шәп шигырь. Бу үзенә күрә шагыйрьнең үз халкы каршында анты да булып яңгырый. Әйе, туган җирен яраткан кешегә гомер буе буразна сөрәсе бар. Менә бит, шайтан алгыры, берниндиунпыш сүзләр дә юк, бик гади юллар, ә мәгънәсе — бер зур китап кадәр! Менә сиңа кечкенә шигырь!

Туган илне яратуы, аңа үзен аямыйча хезмәт итәргә теләве турында Г. Рәхимнең башка бик күп шигырьләреннән дә өзекләр китерергә мөмкин. Һәрбер шигырьдә шагыйрьнең гражданлык хисе алгы планда. Ул фәкать үз иленең бер кешесе буларак кына фикер йөртә ала. Нәкъ менә шушы сыйфатны без талант дип атыйбыз да.

Тәүфикъ Камалиев та шундый ук рух белән поэзиягә килеп керде. Ул — үзенең характеры һәм табигате белән дә тыйнак кеше. Үзенең әсәрләрендә дә шул тыйнаклыгы белән башка яшь шагыйрьләрдән аерылып тора. Юк, ул да әллә нинди баскычлы, керделе-чыктылы юллар белән язмый. Ул да үз иҗатын кечкенә шакмактан башлый. Бу яшь шагыйрь дә күктән йолдызлар алып төшәргә җыенмый. Ул җир тормышын ярата, гади кешеләрне ярата. Яшь шагыйрьнең иҗатында бу төп юнәлеш. Моны әдәби телдә лейтмотив дип тә әйтәләр бугай.

Әйе, Т. Камалиев — тыйнак һәм шул ук вакытта ашкынучан автор. Ул үз фикерләрен әйтеп өлгермәм дип борчыла кебек. Бу яхшы сыйфат. Заманның ракетага утырып барган бу чорында кем ашкынмый да, кем тизрәк атларга теләми? Бу табигый хәл. Ләкин шул ашкыну аркасында без кайбер хәлләрне, кайбер моментларны күз карашыннан төшереп калдырмыйбызмы? Андый хәлләр дә бар икән шул. Яшь шагыйрь менә шул ашкынулы юлда бераз туктап калган да, уйга сабышкан. Һәм үзенең беренче шигырьләренең берсендә «Әйтеп калыйк» дип сүз башлаган [1].

Сөйгән кызлар елаганда көйлибез,
Булган хәлне,
Булмаганны сөйлибез.
Көлдерәбез,
Юатабыз барыбер.
Юанмаса,
Иркәлибез тагын бер.
Тик дәшмибез,
Яшь түккәндә әниләр,
Дәшкән өчен,
Гүя тотып әрлиләр.
Матур сүзне
Эзләвен дә эзлибез,
Әмма шуны
Баштук әйтә белмибез.

Берәм-берәм
Китә бара аналар
Китеп күмелә...
Ерагая аралар.

Назлау сүзен әйтик алдан шуларга,
Юкса, мөмкин бөтенләй дә соңларга.

Кызларга да әйтербез бер — ара бар:
Кызлар әле безнең белән калалар.
Берәм-берәм китә бара аналар.

Я әйтегез, бу шигырь кемгә ошамас икән? Билгеле, бу шигырьне кабат аңлатып торасы калмаган. Мондый чакта комментарий кирәкми диләр. Чыннан да, поэзиядә безнең әле әйтелми калган фикерләр, сүзләр азмыни? Телгә алынмаган яхшы эшләребез, исемнәре җырга лаеклы кешеләребез азмыни? Чыннан да, без үзебезнең сөекле аналарыбызга әле чын йөрәк сүзен, рәхмәт сүзен әйтеп өлгердекме? Яшь шагыйрь әнә шул сорауларга җавап эзли. Бу инде — уйга нәрсә килсә, шуны язып карыйм әле, бәлки, берәр нәрсә чыгар, дип эш итү түгел. Бу — үз бурычыңны алдан ук аңлап, алга куелган теләккә ирешү дигән сүз. Шагыйрьне кешеләр язмышы борчый. Үз заманының шатлыгы, кайгысы, мәхәббәте һәм нәфрәте шагыйрьнең каләме астына куелган. Ул бу темаларны эшкәртә, эзләнә, эзлекле рәвештә поэзия баскычына күтәрелеп килә. Шунысы шәп, Т. Камалиев та форма белән генә мавыкмый. Ул татар поэзиясенең инде иҗат ителгән формаларына, халык иҗатына таяна. Аның киләчәктә булачак уңышлары да шул тарафта дип ышанасы килә. Шагыйрьнең беренче әсәрләрен укыгач та күңелдә шундый хис кала.

Инде өченче яшь шагыйрь Ф. Шәфигуллин турында сүзне башлардан элек, бер мөһим мәсьәләгә кагылып үтәсе бар. Без һәр җыелыш саен диярлек эшче сыйныфка багышланган әсәрләр турында сөйләшәбез. Безне бу темага язылган әсәрләрнең бик аз булуы нык борчый. Дөресен әйтергә кирәк, сүздән эшкә күчкәнебез юк әле. Чөнки безнең олы шагыйрьләребез дә шәһәрдә яшәп тә авылны язарга яраталар.

---

[1] Т. Камалиев. Сабыр канатларым сынмый. Шигырьләр. Казан, 1968 ел.

Билгеле, бу һәркемнең үз эше. Тик шунысы гаҗәп, шагыйрь елына бер айга командировка алып, авылга чыгып керә дә, бер китап шигырьләр язып ташлый. Араларында әйбәтләре дә була, әлбәттә. Ә менә гомер буе үз күршесендә генә дөбердәтеп эшләп яткан заводны яки фабриканы телгә дә алмый, күрми дә кебек. Гомер буе очрашып, күрешеп, сөйләшеп, хәтта кунакка йөрешеп, хәтта бер йортта яшәгән эшчене исенә дә төшерми! Кызык бит! Өйрәнергә теләк булганда, мин ышанам, безнең язучыларыбыз эшчеләр турында да әйбәт әсәрләр иҗат итә алырлар иде. Бигрәк тә хәзерге яшь шагыйрьләр арасында эшчеләр хезмәтенә, тормышны әйдәп баручы эшчеләр сыйныфына ни өчендер игътибар җитми кебегрәк сизелә. Хәтта «Социалистик Татарстан» битләрендә поэзия турында алып барылган бәхәстә дә бу темага беркем дә кагылып узмады. Күрәсең, бу безнең гомуми кимчелегебез булса кирәк.

Ф. Шәфигуллин үзе дә яшь эшче һәм аның язган шигырьләре дә эшчеләр тормышына багышланганнар. Бу яшь шагыйрь дә ни өчен һәм нәрсә турында язарга кирәклеген белә. Чөнки инде ул да тегe шакмаклар өстендә шактый озак кул җайландырып поэзиягә килгән яшьләрнең берсе. Аның биографиясе дә озын юллы. Ул күп якларда булган, диңгез суын да татыган, төзелешләрдә дә эшләгән, җир сөргән, иген чәчкән. Кыскасы, яшь дигән шагыйребез инде картларча бай тормыш тәҗрибәсен туплап өлгергән. Шуңа күрә дә ул хезмәткә бөек ихтирам белән карый. Һәм бәлки нәкъ менә шул хакыйкатьне аңлагачкына, автор кулына каләм алгандыр да. Бу хис аны тыныч калдырмаган, әлбәттә. Хезмәттә ул кешенең горурлыгын күрә. «Эшче горурлыгы» дигән шигырендә нәкъ шул хакта сөйли дә ул. «Алтын эзләүчеләр» исемле шигырьдә дә Фаил Шәфигуллин бу фикерне тагы да кискенрәк итеп, тагын да ачыграк итеп гамәлгә ашыра. Менә ике иптәш алтын табыла торган якларга эшкә китеп баралар.

...Ә бер көнне иптәшемнең бәхете
Кинәт тулып ташты:
Йодрык чаклы булыр — бер шурфтан
Ул саф алтын тапты...

һәм моңа тәмам шатланган егет инде мин баедым, миңа дөнья ни почем дип, эшен ташлап китеп тә бара. Автор:

Алтын тапты... Әмма шул ук көнне
Ул югалтты үзен,—

ди. Егет, «бөлеп» булса кирәк, яңадан эшкә кайта. Әмма аннан ни файда.

...Ә саф алтын аңа (ни үкенеч)
Очрамады бүтән.
Ул үзе дә табылдыгы белән
Онытылды күптән...

Хезмәтнең әнә нинди яклары да бар бит. Эшче горурлыгына хыянәт итсәң, бик түбәнгә төшүең дә мөмкин икән. Бу — Фаил Шәфигуллинның үз ачышы һәм ул аны алтын эзләүче кебек үк бик нык казынып тапкан. Бу хисләр, бу фикерләр бер эшче өчен генә түгел, гомуми кешелек фикеренә әйләнәләр, инде болар теләсә кем өчен дә уртак фикер була алалар. Конкрет образдан һәркемгә яраклы уйлар шулай туа. Осталыкның көче әнә шунда да инде. Димәк, хезмәт темасы бер эшчегә генә караган тема түгел, кешелек, дөнья, тормыш ул. Шуны аңлап эш иткән шагыйрьнең киләчәге — ышанычлы.

Бәлки, бу авторларның шигырьләрендә кимчелекләр бер дә юкмыни! дип сорарлар. Әлбәттә, казынсаң, тырнак астыннан да кер табыла диләр. Әмма бу мәкаләдә андый бурыч куелмады.

Быел яшь авторлар конференциясе вакытында, шагыйрьләр секциясендә дә бу өч авторның әсәрләре укылды, тикшерелде, һәм бер тавыштан алар Язучылар союзына тәкъдим ителделәр.

Гадәттә, кешеләр олы юлга чыгар алдыннан бер минут тынып утыралар. Мин дә хәзер шул минутны кичерәм шикелле. Һәм бу яшь дусларга, бу олы юлга чыгар алдыннан хәерле сәгатьләр теләп калам.

# ҖИР ХУҖАСЫ

Безнең язучылар авыл тормышын сурәтләгән әсәрләрне шактый күп иҗат итәләр. Ул яктан тел тидерерлек түгел. Ләкин шунысы бар: аларның күбесе үткән чорны чагылдыруга кайтып кала торган иде.

Мәсгут Шәрифуллинның әле шушы көннәрдә генә Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыккан «Җир хуҗасы» исемле повесте дә колхоз һәм аның кешеләре тормышын тасвирлауга багышланган. Әмма, шул ук вакытта, бу повесть башкалардан бик нык аерылып та тора. «Җир хуҗасы»нда б ү г е н г е авыл кешеләре, б ү г е н г е колхоз тормышы сурәтләнгән. Иң элек игътибарны ул әнә шул ягы белән җәлеп итә. Повестьның тагын бер аерылып торган сыйфаты шунда, анда колхоз председателе уңай герой буларак сурәтләнгән. Югыйсә безнең әдипләр арасында председательләрне тискәре тип итеп тасвирлау гадәткә әйләнеп бара иде. Бактың исә әйбәт, эшлекле председательләрне дә хәйран кызыклы итеп күрсәтеп була икән ләбаса!

«Җир хуҗасы»нда алай искитәрлек вакыйгалар да, гадәттән тыш хәлләр дә юк. Анда «Уңыш» колхозы председателе Айдарның гадәти бер эш көне генә тасвирланган. Повесть Айдарның иртән йокыдан уянуы белән башлана һәм кичен ятып йокыга китүе белән тәмамлана. Әмма автор әсәрне Айдарның көнлек эшен сурәтләптеркәп бирүгә генә кайтарып калдырмаган. Вакыйга барышында ул Айдарның үткән тормышын да, бүгенге уйларын да, киләчәккә планнарын да шактый тулы ачып бирүгә ирешә. Аны җәмәгать эше башкаручы буларак кына түгел, шәхес буларак, характер буларак та шактый тулы сурәтли.

Бүгенге колхозлар моннан ун ел элекке колхозлардан экономик яктан да, культура ягыннан да бик нык аерылып тора. Аларның авыл хуҗалыгы машиналары да күп, җирләре дә бик зур хәзер. Айдар җитәкчелек итә торган «Уңыш» колхозы да шундый. Сигез мең гектар җир биләүче, тугыз авылны берләштергән колхоз ул. Андый колхоз белән идарә итү өчен зур оештыру сәләте, зур белем, һәм, иң мөһиме, җирне, кешеләрне ярату кирәк. Айдарда бу сыйфатларның һәркайсы бар. Аны гади колхозчылар да, идарә аппаратында эшләүчеләр дә хөрмәт итә. Чөнки Айдар уйлап-үлчәп эш итә торган председатель, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган тәҗрибәле белгеч. Үз республикабызда гына түгел, Советлар Союзында гына да түгел, хәтта бөтен җир шарындагы һәр гектар чәчүлек җир ничә кешене туендырып торуын да, кайсы илдә һәр гектардан күпме иген җыеп алынуын да ул үзенең биш бармагы кебек белеп тора. Колхозчылар белән мөнәсәбәте дә әйбәт. Аны тыңлый, аңа ышана колхозчылар. «Уңыш» колхозының экономик хәле шулай ук яхшы. Ул колхозның Бөгелмә, Октябрьск шәһәрләрендә җиләк-җимеш сата торган үз ларекларына тикле бар. Үзенең йорт салырга вакыты булмаган колхозчыларга стандарт йортлар төзеп бирү эше дә җайга салынган. Авыл клубы әлегә яхшы булса да, киләчәктә зур клуб салдырып, аның каршына агачлар утыртырга һәм киң мәйдан ясарга хыяллана Айдар. Аның хыялы тор-

мышка ашачагына шик юк, чөнки ул ниятен тормышка ашыра торган кеше. Кыскасы, председатель буларак эшләре көйле Айдарның...

Әмма аның шәхси тормышы гына ал да гөл түгел шул. Тугыз авыл халкы белән бик әйбәт идарә итеп килә торган ул кеше, утыз алты яшькә җитсә дә, шәхси тормышын җайга сала алмаган әле. Башта, бер дә юкка бәйләнеп, аны хатыны Асия борчып торган. Аннары, кыз баласын ияртеп, Айдарны ташлап ук киткән. Хәзер Айдар күрше авылда эшләүче врач кыз Римма белән танышкан. Алар бер-берен яратышалар. Соңгы очрашуларында кавышырга сүз дә куешалар. Әмма, әлеге дә баягы, Асия һаман Айдарны борчып, тынгысызлап тора. Аннары Айдар бала атасы да бит әле... Четрекле, ай-һай четрекле аның шәхси тормышы!

Айдар образына шуңа болай озаклап тукталдык, чөнки ул повестьта төп фигура. Вакыйгалар да, башка персонажлар да аңа бәйле рәвештә сурәтләнә. Аннары, дөресен генә әйткәндә, «Җир хуҗасы»нда авыз тутырып сөйләрлек персонажлар да юк. Колхоз парторгы әсәрдә шактый еш очрый, әмма ул характер буларак Айдар кебек үк тулы сурәтләнмәгән. Ә менә аерым эпизодларда чагылып-чагылып киткән аерым персонажлар характерындагы аерым моментларны автор шактый уңышлы чагылдырган.

Җыеп кына әйткәндә, Мәсгут Шәрифуллин бу әсәрендә хәзерге колхоз тормышын һәм аның кешеләрен бик әйбәт белеп, дөрес итеп сурәтләгән. Повестьның теле дә М. Шәрифуллинның моңа кадәр язылган әсәрләре белән чагыштырганда шактый шома һәм образлы. Шик юк, «Җир хуҗасы»н укучылар яратып укырлар һәм ул авыл темасына багышланган әсәрләр арасында тиешле урынын алыр. Тик шунысы гына кызганыч: «Җир хуҗасы» повесте — мәрхүм Мәсгут Шәрифуллинның соңгы әсәре. Исән булса, ул тагын да әйбәтрәк әсәрләр иҗат итәр иде әле. Аның таланты ныгып, канатланып кына килә иде.

ВАКЫЙФ НУРУЛЛИН.

# ҖЫРЛАР АША СӨЙЛИ КҮҢЕЛЛӘР

Татарстан язучыларының кайсыдыр бер җыелышында халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көнен һәр ел саен «Шигырь бәйрәме» исемле җыентык чыгарып каршылауны практикага кертергә кирәк, дигән фикер әйтелгән иде. Бу матур фикер кәгазьгә генә язылып калмады. Китап нәшриятыбыз андый җыентыкны бастырып чыгаруны ике куллап хуплады һәм аны үзенең перспектив планына кертте. Әлеге җыентыкка тупланган шигырьләрнең беренче бәйләме 1968 елда инде басылып та чыкты [1].

«Шигырь бәйрәме»ндә үзләренең шигырьләре, җырлары, мәсәлләре һәм яңа тәрҗемәләре белән илледән якын шагыйрь катнаша. Алар арасында без поэзия сөючеләрнең ихтирамын казанып өлгергән шагыйрьләребез Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Салих Баттал, Мөхәммәт Садри, Нури Арсланов, Зәки Нури, Галимҗан Латыйп, Гамил Афзал, Нәби Дәүли, Әдип Маликов, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеевлар белән берләттән, шигърият мәйданына әле күптән түгел генә аяк баскан Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Камил Мостафин, Рөстәм Мингалимов, Салисә Гәрәева, Фанис Яруллин, Рәдиф Гатауллин кебек яшь әдипләребезнең дә исемнәрен күрәбез.

Җыентыкта төп урынны бүгенге көннең иң актуаль темаларына язылган әсәрләр алып тора. Туган җир, планетабызның иминлеген саклап калу өчен алып барыла торган көрәш, халыклар дуслыгы һәм хезмәт темаларына язылган шигырьләрне укыганда тынгысыз тормышның күп төрле яклары күз алдына килеп баса. Сибгат Хәкимнең «Уналты йорт безнең тыкрыкта», Әдип Маликовның «Яндырылган хатлар», Хисам Камаловның «Сугышларда күп кан койгангамы» шигырьләрендә сугышка каршы көчле нәфрәт хисе дөрли. Шул ук хис Нәби Дәүлинең «Вьетнам солдатына» дигән шигырендә лирик геройның уйлануары,

[1] Шигырь бәйрәме. Төзүчесе Илдар Юзеев. Редакторы Рәдиф Гатауллин. Тиражы 5000. Бәясе 21 тиен.

эчке кичерешләре аша безнең дә күңелләребезгә күчә.

Ил чакырса, без китәрбез,
Булсын тик набат кына.
Без әзер алмаш булырга
Вьетнам солдатына,—

ди шагыйрь ирек сөюче барлык дусларыбызның уртак теләген белдереп. Бу шигырьнең, басылып чыгу белән көйгә салынып, күңелләрнең яраткан җырына әверелеп китүе һич тә очраклы хәл түгел. Хәрби-патриотик темаларга багышланган мондый әсәрләрне укучы ярата, аларны үзенә юлдаш итеп ала. Әмма андый характердагы шигырьләр һәм җырлар бездә әле берән-сәрән генә күренгәли. Бу кимчелек «Шигырь бәйрәме» китабында да үзен нык сиздерә.

Туган җирне ярату, еракларга китеп гомер кичергәндә аны сагыну, соңгы сулышкача аңа турылыклы булып калу турындагы шигырьләргә безнең поэзиябез шактый бай. Җыентыкка соңгы берничә ел эчендә иҗат ителгән шундый шигырьләрнең иң уңышлылары сайлап алынган. Гамил Афзалның «Җанга якын урыннар», Шәүкәт Галиевнең «Җир баласы идем»..., Рәшит Гатауллинның «Күл буенда үскән ак каеннар», Мөнир Мазуновның «Туган як», мәрхүм шагыйрьләребез Әхмәт Ерикәйнең «Пейзаж», Әнвәр Давыдовның «Ватан! Соңгы минутыма кадәр...», Гали Хуҗиевның «Рөхсәт ит син миңа» шигырьләрендә совет кешеләренең туган илгә булган кайнар мәхәббәте, эчкерсез хисләре һәм теләкләре гәүдәләнә. Г. Хуҗиев шигыре, мәсәлән, һәркемне дулкынландыра, уйландыра торган тирән мәгънәле юллар белән тәмамлана. Гражданины һәм солдаты буларак, Россиягә мөрәҗәгать итеп, шагыйрь болай ди:

Тырыштым мин ихлас бу тормышта
Бары синең өчен янарга.
Рөхсәт ит син миңа соң сулышта
Кулларыңа синең аварга.

Шигырь бәйрәмнәре уздырылганда, поэзиянең иҗтимагый роле, кешеләргә эстетик тәрбия бирүдәге әһәмияте, көрәш ялкыны белән сулаган бу заманда шагыйрьнең тормыштагы урыны, аның өстенә йөкләтелгән бурычлар турында кат-кат искә төшерү бик табигый. Салих Баттал, Илдар Юзеев һәм Камил Мостафинның җыентыкка кертелгән шигырьләре нәкъ әнә шул хакта язылганнар. Ул шигырьләр безнең күз алдыбызга «шигъри казанышлар рәнжырында» уң як сафка баскан Җәлилләрне, Фатих Кәрим һәм Демьян Фәтхиләрне китереп бастыра. Әйе, С. Батталның «Син — политрук» шигырендә әйтелгәнчә:

Тукай клубына үткән чакта
мәрмәр исемлектә кемнәр бар —
һәммәсе дә безнең ирек өчен
сугышып үлгән Байрон бит алар!

Сугышчан һәм патриотик рух белән сугарылган мондый юлларны «Шигырь бәйрәме»ндә катнашкан башка шагыйрьләрнең шигырьләрендә дә очратырга мөмкин. Шуның белән бергә, бу җыентыкта укучыларга сатирик һәм юмористик планда язылган шигырьләр дә тәкъдим ителгән. Габдулла Шамуковның «Аптыраш» һәм Маннур Сатаровның «Малай класста калгач» шигырьләрендә кайберәүләрнең аңында әле һаман да яшәп килгән тискәре яклар оста тотып алынган поэтик детальләр аша ачып салына.

Җыентыкны төзүче бүгенге укучыны яңа табылган истәлекләрдән Дәрдмәнднең «Җырлыйм әле...», «Таулы матур илләрендә...», «Аның янында кичкә котлы көндә...», «Ят илнең яд итеп якты кояшын» шикелле шигырьләре, бөек үзбәк классигы Гомәр Хәйям һәм татар әдипләренең якын дусты, казакъ халкының күренекле шагыйре Җакан Сыздыков иҗаты үрнәкләре белән дә таныштырырга онытмаган. Ләкин, беренче белен төерле була дигәндәй, «Шигырь бәйрәме» китабын укып чыкканнан соң кайбер кимчелекләр дә күзгә ташлана. Беренчедән, Нур Гайсин, Зәет Мәҗитов, Марс Шабаев кебек кайбер өлкән һәм урта буын шагыйрьләребезнең исемнәрен җыентыкта бөтенләй күрмибез. Икенчедән, колачын көннән-көн киңрәк җәеп тагын да биегрәк үрләр яулаучы татар совет поэзиясе вәкилләренең яңа әсәрләрен халыкка тулырак җиткерү өчен китапның күләме бик кечкенә. «Шигырь бәйрәме» җыентыгы быелдан башлап һәр ел саен чыгарылачак. Аның күләмен шагыйрьләребезнең иң яхшы әсәрләре бәрабәренә арттырганнан арттыра барганда, җыентык үзенең йөзен һәм күп санлаган даими укучыларын тизрәк табар иде. Чөнки күңелләр тормышта көн дә булып тора торган шатлык һәм кайгыларны, сөенеч һәм көенечләрне бер-берләренә барыннан да элек җырлар аша җиткерәләр. Менә шуңа күрә дә Тукай һәм Җәлилләр калдырган эстафетаны югары тотып баручы шигъриятебез җыр бәйрәмнәрендә үзенә киңрәк мәйдан сорый.

РӘШИТ ГӘРӘЙ.

Әхәт Фазылҗанов

# АЛТЫН

оптимистик хикәя



Капка баганасы утырту өчен чокыр казырга гына тотынган идем, янымa күршем Гыйззәт чыгып чүгәләде. Кулына бөгәрләп газета тоткан.

— Сәлам күршегә! Яңа нигезне үзләштерәбезме?

— Шулайрак иде шул.

Бераз сүзсез утырганнан соң:

— Көйрәтеп алыйк булмаса,— диде. Тиз генә китәргә исәбе юк иде, ахры. Булачак чокыр урынынпан мин кубарып аткан ташка барып утырды. Авызына капкан папиросын бер-ике тапкыр суырды да газетаны җәеп җибәрде.

— Укыдыңмы?

— Бүгенгеме?

— Әйе.

— Өлгергән юк әле. Күрәсең, эш тыгыз. Берәр кызык нәрсә юктыр ич?

Шул сорауны гына көткән икән, күршем кинәт җанланып китте. Әле менә монысын миннән башка берәүнең дә укыганы юктыр дигәндәй кабаланып, газетаның дүртенче битендәге иң соңгы колонкага бармагы белән төртеп күрсәтте.

— Укы!

Үзе миннән күзләрен алмый. Я, син нәрсә диярсең, янәсе.

Берәү иске йорт урынын бульдозер белән чистартканда бер чүлмәк алтынга юлыккан. Газетада шул хакта язылган икән. Дөресен әйтим, әллә ни кызыгын тапмадым. Беренчесе түгел ләбаса, андый хәлләр гел булгалап тора. Гыйззәтне әйтәм, исе киткен иске чикмән итәгенә.

— Шәп булган,— дидем үтә битараф кыяфәт белән һәм газетаны кире суздым.

— Шәбен шәп тә, сиңа түгел бит ул,— диде күршем, кинаяле елмаеп. Һәм шунда ук ярым пышылдауга күчте.— Беләсеңме нәрсә, бу нигездән дә алтын чыгуы ихтимал бит.

— Кайдан килсен ди ул монда?

— Әйткәнне тыңлап бетер. Кем нигезе икәнен беләсеңме син моның? Революциягә кадәр бик зур сәүдәгәр торган монда, беләсең килсә. Теге вакытта бөтен байлыгын үзе белән алып бетергәндер дисеңме? Үз колакларым белән ишеткәнем бар: әле менә биш-алты ел гына элек сәүдәгәрнең малае кайтып, төпле нидер эзләнеп йөргән, ди. Билгеле, әтисенең алтынын эзләгән.

— Алайса чәлдереп киткәндер инде.

— Тапмаган ди шул. Аннан соң да әллә ничә тапкыр күргәннәр инде ул малайны бу тирәдә. Әтисе аңа алтын яшергән урынны тәгәл әйтеп бетермәгән, ахры.

Алтын шайтанны да аздырган, ди, минем дә күңел кытыкланып китте бит әле. Кеше булмастайны сөйләмәстер. Әгәр шул хәзинәне мин табып куйсам, ә? Әле яңа гына оя кора башлаганда ярап куяр иде шул. Әһем! Шушында бер чүлмәк алтын килеп чыкса, нишләр идем икән! Иң әүвәл бурычлардан котылыр идем. Хәер, анысы күпме генә инде аның. Алтын бик кыйммәт йөри диләр түгелме соң? Үз гомереңдә тотып бетерә алмавың да бардыр әле. Чүлмәге белән чыкса дим. Исән киткән икән, бетмәсә, балаларга калыр, оныкларга. Чыксын гына, урыны табылыр иде әле. Җиңел машина алып җибәрәсең. Эх! Миләүшәгә теш куйдырыр идем. Үземнең алтын тешкә исем китми анысы... Ул чагында йортның да иркенрәген саласың инде...

Минем инде тизрәк эшкә тотынасым гына килеп тора хәзер. Әмма Гыйззәткә сер бирмәскә тырышам. («Тапкансың кеше кызыктырыр нәрсә».) Казый башлаган чокырга ашыкмыйча гына төшәм. Болай да тирләгән учларыма төкергәләп маташам. Көрәкне тыгыз балчыкка сабыр гына батырам. Янымда кеше басып торганда казыйсы килми. Ул карап торганда килеп чыкса, урталай бүләргә туры киләчәк бит хәзинәне. Китми бит кереп Гыйззәте дә. Ул да алтын чыгасына тәмам ышанган, ахры. Әзергә хәзер буласы. Моңарчы нәрсә карагандыр. Ике күзе минем чокыр төбендә. Ит тураганда ялманып утырган мәче шикелле. Ачу килә башлады. Арыдым дип кереп китәр идең, әле генә эшкә тотындым. Шикләнүе бар.

Ярый әле хатыны чакырып алды.

Менә хәзер дөньясын актарып ташларга була. Тәмәке көйрәтергә дә туктаган юк. Казуым казу. Көрәккә китереп типкән саен, көрәк лепелдәп куя. Менә хәзер теге сәүдәгәр күмеп калдырган хәзинә ялтырап килеп чыгар төсле. Кайвакыт өметне өзеп (дөресрәге, өзгән булып), алтын турындагы уйларымны баштан куарга да көчәнеп карыйм. Ә алар көзге чебен белән бер, аз гына югалып торган булалар да тагын баш түбәсенә килеп куналар. Тагын дәртләнеп казырга тотынам. Чокыр кырыена килеп баскан Миләүшәмне дә күрмим, ишетмим икән.

— Саңгырауландың мәллә югыйсә? Кайчаннан бирле янында эндәшеп торам... Абау, чамалап казыйсыңмы моны? Багана үзе төшеп утырырлык булган ич инде бу.

Артык мавыгып киткәнмен икән шул. Чыгарып аткан балчыкның бер өлешен чокыр төбенә кире салырга туры килде.

Мөгаен, хәзинә дигәннәре бу урында түгелдер. Ул кадәр тирән күмелмәгәндер инде. Шулай да өметне өзеп бетергән юк әле. Тагын ике багана чокыры казыйсы бар.

Кадалып кына китсен, алары да бирмәде көткәнне. Гайрәтем сүрелә башлады.

Капка белән эшне төгәлләгәч, тегесен-монысын утырту өчен түтәлләр ясарга алындым. Койма аркылы Гыйззәт тагын газета болгый.

— Укыдыңмы?

— Нәрсә бар?

— Алтын тапканнар.

— Китсәнә?!

Гыйззәтнең сүзләренә генә ышанып бетмичә, барып газетаны йолкып дигәндәй үз кулыма алдым. Дөрес, әй. Берәү, нәкъ минем шикелле, алма бакчасында казына икән, бер көрәк балчык алып ташлаган, икенче тапкыр җиргә китереп тыгуы булган, көрәге ниндидер каты әйбергә килеп төртелгән. Караса — алтын. Ярты потлы! Бар бәхетле кешеләр дөньяда.

Безнең бакчада көрәк төрткән саен әллә нинләр шатыр-шотыр килә. Алып карасаң — кирпеч. Иске мич урыны булды, ахры. Арындырып бетерә торган эмәл юк.

Алтынны әйтәм, әллә нинди кешегә генә очрый шунда. Көн саен диярлек табып торалар, көн саен диярлек язып торалар.

Ташкентта жир тетрәгәннән соң, жимерек йортларның чүп-чарын машиналарга төяп шәһәр читенә ташыйлар икән. Кайсыдыр шул машиналарның берсен бора да әлеге чүп-чарны ишек алдына аударта. Тарата башласа, ни күзе белән күрсен — алтын акчалар! Насыйбыдыр инде, үз аяклары белән килеп кергән бит.

Мәскәүдәге бер йортның хәтта капка бастырыгы да алтын булып чыккан, ди. Ничә еллар шуны белмәгәннәр, әй. Капкасы нинди металдан булгандыр тагын. Мөгаен, анысын ук сүтеп карарга өлгермәгәннәрдер. Әллә ул кадәресенә башлары житмәде микән?

Кайсыдыр калада домна миченә иске тимер-томыр китереп аударганнар. Шул чак күгәреп беткән караватт аягы эченнән бер куш уч алтын коелган, ди.

Өйгә кайтып кулга газета алуга бер могжиза көт тә тор. Ул алтын дигәннәрен төшләремдә күрә башладым инде. Күршем Гыйззәт вәсвәсәләнеп йөри тагын. Беркөн шулай тиктомалга миннән сорап куйды:

— Алтын тапсаң, нишләр идең?

Әллә, чыннан да, миннән нигез хужасының хәзинәсен кулга төшерде дип шикләнә инде.

— Кеше котыртып йөргән журналистларга өләшер идем,— мин әйтәм, ачуымны яшерә алмыйча. Һәм кулымдагы газетаны ачу белән читкә ташладым. Ә эчемнән үземчә план корам: инде актармаган жир калмады, хәзинә дигәннәре йорт астында түгел микән? Йортны икенче урынга күчереп саласымы әллә...

## ...ЕЛДАН СОҢ

Дөнья мәшәкатьләре өстән төште. Картайдык. Мин дә, Гыйззәт тә күптән пенсиядә. Көн саен диярлек, сакал салпырайтып, су буенда балык каптырабыз. Бүтән эш юк. Беләк хәтле бәртәсләрне суырып кына торабыз, мин сиңа әйтим.

Чираттагы бәртәс авызыннан кармакны ычкындыра алмый маташканда, читтәрәк уйнап йөрүче оныгым йөгереп килде. Нәни учын жәеп жибәрде. Ә анда нидер ялтырап ята. Нәкъ алтын төсле. Мин танымый торам. Юньлерәк әйберме дисәм...

— Бабай, менә нинди матур таш таптым.

— Ташла, улым, кәкәй ул,— мин әйтәм.

— Ул бер нәрсәгә дә ярамый, неме?

— Ярый да, тик аннан бәдрәф кенә ясыйлар, улым. Кирәк кеше алыр әле, ташлыйбыз аны.

Алтын кисәге «чуп» итеп минем калкавыч янына ук барып төште. Ә оныгым уч төбен ыштанына ышкып куйды.

— Менә шулай.

## СОҢГЫ СҮЗ

Килер андый заманнар да. Һичшиксез, килер. Еллар гына имин торсын.

# ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## АБДУЛЛА АЛИШ ЮБИЛЕЕ

Немец фашистлары тарафыннан җәзалап үтерелгән язучы һәм көрәшче Абдулла Алишка 60 яшь тулу көнен Татарстан хезмәт ияләре һәм язучылар җәмәгатьчелеге зурлап үткәрделәр.

Язучының туган җирендә — Куйбышев районы үзәгендә һәм шушы районның Көек авылында патриот язучыны искә алу кичәләре үткәрелде.

12 сентябрьдә Көек авылында үткәрелгән кичәдә Пискәч совхозы эшчеләре, укытучылар, Казаннан килгән язучылар һәм журналистлар катнашты.

Кичәне урта мәктәп укытучысы Г. Хөсәенов ачты. А. Алишның тормыш һәм иҗаты турында С. Шакир доклад ясады. Язучының сеңелесе Закирә Алишева, җизнәсе Галиулла Яруллин һәм КПССның Куйбышев райкомы секретаре Камил Лотфуллин, алдынгы комбайнчы Х. Вафин, шагыйрь М. Хөсәен чыгыш ясадылар. Укучы балалар һәм совхоз эшчеләре А. Алиш һәйкәленә чәчәкләр салдылар.

Казан шәһәре хезмәт ияләренең А. Алишка багышланган тантаналы кичәсе 16 сентябрьдә Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрында үткәрелде. Кичәне юбилей комиссиясе председателе Г. Кашшаф ачты. Тәнкыйтьче Р. Мостафин язучының иҗаты һәм тормыш юлы турында доклад ясады. А. Алишның туганнары Г. Алишев һәм С. Алишев, Көек мәктәбе укытучысы С. Садриева, Куйбышев райкомы секретаре К. Лотфуллин истәлекләр сөйләделәр. С. Шакир һәм М. Хөсәен А. Алишка багышлап язган шигырьләрен укыдылар. Кичәнең сәнгать бүлегендә Казанның А. Алиш исемендәге Пионерлар сараеннан килгән пионерлар чыгышы халыкка аеруча ошады. Спорт киемнәре кигән, чук кебек бизәнгән балалар — А. Алиш китапларының геройлары — кочак-кочак чәчәк күтәреп, үзләре үстергән алмаларны кәрзин-кәрзин алып килделәр, биеделәр, җырладылар.

Соңыннан Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт Опера һәм балет театры, Татар дәүләт филармониясе, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары көче белән зур концерт бирелде.

Шундый ук кичәләр Казанның А. Алиш исемендәге Пионерлар сараенда, мәктәпләрдә һәм Әлмәт шәһәренең нефтьчеләр клубында үткәрелде.

Мәскәү газеталарында һәм республика матбугатында патриот язучының тормыш юлына, иҗат эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр басылды.

Казанның 68 нче мәктәбендә А. Алиш музее ачылды.

## ӘДӘБИ АТНАЛЫКЛАР

Сентябрь аенда Татарстанның Сарман һәм Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районнарында әдәби атналыклар үткәрелде.

Горький өлкәсендәге атналыкта Г. Минский, Х. Туфан, М. Әмир, Р. Төхфәтуллин, Ш. Галиев, Г. Мөхәммәтшин, А. Сәләхетдинов, М. Шабаев, К. Фәсәхов һәм Ә. Шамил катнашты. Алар игенчеләр, терлекчеләр, авыл интеллигенциясе, мәктәп балалары белән очраштылар. Автографлар белән китаплар саттылар.

Сарман районы әдәби атналыгында А. Гыйләҗев, Г. Афзал, С. Рафиков, Ю. Әминов, С. Кальметов, М. Хәсәнов, Р. Фәйзуллин, С. Сөләйманова, Р. Батуллин, К. Булатова катнашты. Республикабызда югары иген үстерү буенча дан алган Сарман хезмәт ияләре Татарстан әдипләрен якты йөз белән каршы алдылар. Әдәби кичәләрдә, аерым очрашуларда сүз В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстанның төзелүенә 50 ел тулуга хәзерлек турында, язучыларның яңа китаплары турында барды.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» — КОЛХОЗЧЫЛАРГА БҮЛӘК

Буа районының Социалистик Хезмәт Герое Рәүф Әһлиуллин җитәкли торган «Память Ленина» колхозы идарәсе 40 алдынгы механизаторны һәм терлекчене «Казан утлары» журналына еллык подписка белән бүләкләү турында карар чыгарды. Районның «Чулпан», «Коммунизмга», «Маяк», «Марс» авыл хуҗалыгы артельләрендә дә алдынгы колхозчыларга еллык подпискалар бүләк ителде.

Бу матур традиция Апас районының күп кенә колхозларында берничә ел дәвам итә. Энгельс исемендәге, «Спартак», Ленин исемендәге, Тукай исемендәге, «Байрак», Горбунов исемендәге, Крупская исемендәге, Куйбышев исемендәге колхоз идарәләре быел да күп кенә хезмәт алдынгыларына, төрле кыйммәтле бүләкләргә өстәмә итеп, 1969 ел өчен «Казан утлары» журналын яздырдылар.

## ТУКАЙНЫ ХӨРМӘТЛӘҮ

Апас районының Тукай исемендәге колхозында быел халкыбызның бөек шагыйренә һәйкәл салынды. Һәйкәлнең авторы — скульптор Адилов. Шул ук колхозда хезмәт алдынгыларын Г. Тукай исемендәге премияләр белән бүләкләү турында карар чыгарылды. 100 сум күләмендәге беренче һәм 75 сум күләмендәге икенче премияләр алдынгыларга һәр елны бөек шагыйрь туган көнне — 26 апрельдә тантаналы рәвештә тапшырылачак.

## СЕНТЯБРЬДӘ ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Сантехприбор заводында Валерий Синев эшчеләр белән очрашу үткәрде.

• • •

Журналист Заки Әхмәтҗанов, яшь шагыйрә Клара Булатова Бөгелмә районының кооператив училищесында, Муса Җәлил исемендәге, Куйбышев исемендәге, Свердлов исемендәге колхозларда Бөек Ватан сугышында һәлак булган батыр якташларыбыз турында әңгәмә үткәрделәр, шул темага шигырьләр укыдылар.

• • •

Кави Латыйпов, Валерий Синев «Васильево» санаториясендә дәваланучыларны бүгенге әдәбият яңалыклары белән таныштырдылар. К. Латыйпов Васильево мәктәбе укучыларына «Безнең Чапай» исемле повестенең ничек язылуын сөйләде.

• • •

Язучы Мәлик Хәмитов Апас районында булып кайтты. Аның катнашында район китапханәсендә һәм Г. Тукай исемендәге колхоз клубында «Казан утлары» журналы буенча укучылар конференцияләре үткәрелде.

• • •

Яшь язучы Котдус Дәүләтшин Татарстанның Биектау районында булып, «Казан утлары» журналын тарату буенча эшләде.

• • •

Ф. Мансуров Буа шәһәрендә булып, «Байрак» район газетасы каршында оештырылган әдәби түгәрәкнең эше белән танышты. Берничә яшь авторның хикәяләре һәм шигырьләре республика матбугатына тәкъдим ителде.

• • •

Роберт Әхмәтҗанов Түбән Кама шәһәрендә булып, яшь әдипләр иҗаты белән танышты. Соңыннан Р. Әхмәтҗанов, Р. Хисмәтуллин Чаллы районының «Якты юллы» һәм М. Вахитов исемендәге колхозларында чыгыш ясадылар. Шигырь һәм тормыш турындагы әңгәмә бергә үрелеп барды.

• • •

Ш. Рәкыйпов һәм Р. Гәрәй Балтач районында булып яшь язучыларның һәм мәктәпләрдәге әдәби түгәрәкләрнең эше белән таныштылар. Н. Мадъяров җыентыгы буенча фикер алышу үткәрелде. Мәктәпләрдәге башлап язучыларга әдәби консультация бирелде.

• • •

Татарстанның төрле районнарыннан республика киңәшмәсенә җыелган пропагандистлар һәм агитаторлар язучылар һәм композиторлар белән очраштылар.

Язучылар союзының җаваплы секретаре Гариф Ахунов татар язучыларының ике

бөек датага — В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССРның төзелүенә 50 ел тулу бәйрәменә ничек әзерләнүләре турында сөйләде. Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен яңа шигырьләрен укыды.

Композитор Рөстәм Яхин яңа җырларын рояльдә уйнады. Артист Эмиль Җәләлетдинов Р. Яхин көйләрен башкарды. Яшь композиторлар Фасил Әхмәтов һәм Рафаэль Билялов яңа әсәрләреннән берничә көй уйнадылар. Музыка белгече, Татарстан Дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов татар совет музыкасының үсеш тенденцияләре турында сөйләде.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ КИТАПЛАРЫ РУС ТЕЛЕНДӘ

1968—70 елларда Мәскәүнең «Советский писатель», «Советская Россия», Гослитиздат, «Восточная литература», «Молодая гвардия», «Детская литература» һ. б. нәшриятларында татар язучыларының кырыктан артык китабы басылып чыгачак. Аларның кайберләре инде укучылар кулына тапшырылды. Быел С. Хәкимнең «Через кручи» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы, Г. Мөхәммәтшинның «Мой характер» исемле хикәяләр җыентыгы, М. Садриның «Песня дружбы» җыентыгы, М. Ногманның В. И. Ленинга багышланган «Кокушкино таңнары» поэмасы, З. Нуриның «Разговор с подснежником» җыентыгы дөнья күрделәр. Якын арада М. Әмирнең «Грехи моей молодости» (хикәяләр), Х. Туфанның сайланма шигырьләре, Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы басылып чыгачак.

Классикларыбыздан Г. Тукай, Г. Ибраһимов, һ. Такташ әсәрләре, бүгенге заманның проза осталары Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Г. Гобәй китаплары төрле нәшриятларда русчага тәрҗемә ителә.

В. И. Ленинның тууына 100 ел һәм Татарстан АССРның төзелүенә 50 ел тулу уңае белән «Советская Россия» нәшрияты «Татарские рассказы», «Короткие повести» китапларын, «Великий земляк» исеме белән татар язучыларының Ильичка багышланган әсәрләре җыентыгын бастырып чыгаруны планлаштырды.

## НЕФТЬЧЕЛӘР БҮЛӘГЕ

Татарстанда нефть чыга башлауга 25 ел тулды. Шушы зур бәйрәм хөрмәтенә Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсе, нефть чыгару осталары белән бергә, бер төркем язучыларны (иҗатларында нефтьче образын тудырган өчен) Мактау грамоталары һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләде.

Алар арасында М. Хәсәнов, Ә. Маликов, Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Г. Афзал, С. Сөләйманова, Ш. Бикчурин, С. Кальметов иптәшләр бар.

## МАРИНА ЦВЕТАЕВА ИСТӘЛЕГЕ

Сентябрьнең кояшлы бер көнендә Алабуга педагогия институтының укытучылары һәм студентлары Марина Цветаева каберенә чәчәк салып, аның хатирәсен билгеләп узарга җыелдылар. Казаннан килгән язучы Р. Мостафин шагыйрәнең иҗаты һәм тормыш юлы турында сөйләде, студентларны М. Цветаеваның яңа гына басылып чыккан шигырьләре белән таныштырды.

Шул ук көнне студентлар шагыйрәнең соңгы көннәре узган йортта булдылар. Квартир хуҗасы А. И. Бродельщикова М. Цветаеваның Алабугадагы тормышы турында сөйләде.

Шигъри митингта язучы Э. Касыймов, Алабуга пединститутының проректоры Т. Галиуллин, КПССның Алабуга шәһәр комитеты секретаре иптәш Митрофанов һ. б. катнашты.

Шул ук көнне язучылар Р. Мостафин, Э. Касыймов һәм Алабуга пединституты укытучылары Алабугада озак еллар яшәп, иҗат итеп үлгән кырым татар шагыйре Кәрим Җәманаклы каберенә чәчәк салдылар.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР СЕМИНАРЫ

Татарстан язучылар союзы идарәсе һәм Союзның әдәби консультация бүлекләре ел саен яшь һәм башлап язучыларның семинарларын үткәреп килә.

Әле җәй айларында Питрәч районыннан Павел Апушев, Түбән Кама шәһәреннән Мизхәт Хәбибуллин Казанга индивидуаль семинарга чакырылганнар иде. Тәҗрибәле язучылар бу яшь шагыйрьләрнең әсәрләренә тулы, киң анализ ясадылар. Павел Апушев, Мизхәт Хәбибуллиннарның шигырьләрендә тирән хис белән язарга зур омтылыш барлыгын билгеләп үттеләр.

Сентябрь ахырларында индивидуаль семинарга яшь прозаиклар чакырылды. Башкортстаннан Радик Исаев, Замир Низам, Мәскәүдән Миргазиян Юнусов, Әлмәттән Азат Ганиев килде. Радик Исаев

һәм Азат Ганиев хикәяләре, Миргазиян Юнусовның зур күләмле повесте семинар житәкчеләре тарафыннан хуплап каршы алынды, кайбер житешсезлекләрен төзәткәч, матбугатта бастырып чыгарырга лаеклы дип табылды. Замир Низаминың юмористик-сатирик планда хикәяләр язуы игътибарны жәлеп итте, аңа шул юнәлештә эшләргә киңәш бирелде. Яшь шагыйрьләрдән Түбән Камадан килгән Фәннур Сафин, Уфадан килгән Альберт Закировның күпчелек шигырьләре кичерешләргә бай шигъри нечкәлекләр белән язылган дип табылды.

Яшь рус язучыларыннан семинарда Виктор Радзиевский (хикәяче, студент), Алексей Королев (хикәяче, педагог), Евгений Сойкин (шагыйрь, завод эшчесе), Мария Аввакумова (шагыйрә, студент), Лидия Григорьева (шагыйрә, Казан мәктәбе укытучысы), Геннадий Бабаев (хикәяче) катнаштылар.

Соңгы айларда үткәрелгән индивидуаль семинарлар яңа, өметле яшь авторларны хәерле юл теләп әдәбият мәйданына юнәлтү булды. Үзләренең тәжрибәләре белән уртаклашып, яшьләргә киңәшләр биреп, семинарлар үткәрүдә актив катнашкан язучылардан Х. Туфан, Г. Бакиров, Ә. Еники, А. Расих, З. Мәжитов, Ә. Баян, Х. Сарьян, С. Сабирова, С. Радзиевская, Л. Топчий, Т. Журавлев, В. Синев, Я. Винецкий, Ю. Белостоцкий, А. Булгаков, Р. Кутуй иптәшләргә әдәби консультация бюролары рәхмәт белдерәләр.

## МУСА ЖӘЛИЛ ОБРАЗЫ ЭКРАНДА

Советлар Союзы Герое һәм Ленин премиясе лауреаты, курку белмәс көрәшче Муса Жәлил турында «Ленфильм» коллективы тудырган «Моабит дәфтәре» фильмы экранга чыкты.

Фильмның премьерасы Казанда башланды. Октябрь аенда Казанның күп кенә урамнары «Моабит дәфтәре»нә багышланган афишалар, киноактерларның рәсемнәре, утлы белдерүләр белән бизәлде.

12 октябрьда Казанга Ленинградтан һәм Мәскәүдән бер төркем кунаклар килде. Алар арасында Муса Жәлил ролен башкаручы РСФСРның халык артисты Петр Григорьевич Чернов, режиссер Леонид Александрович Квинихидзе, картина директоры Борис Григорьевич Гринер, оператор Вячеслав Ксаверьевич Фастович, Муса Жәлилнең гомер юлдашы Әминә ханым Жәлиловалар бар иде.

Ленинградтан килгән кунаклар һәм фильмны тудыруда катнашучы татар артистлары Рәфкать Бикчәнтәев, Әзһәр Шакиров һәм Илдар Хәйруллин 12 октябрьда «Моабит дәфтәре» фильмын күрсәтер алдыннан «Татарстан», «Тукай», «Дружба» кинотеатрларында тамашачылар белән очраштылар.

* * *

«Моабит дәфтәре» фильмын тудыручылар Татарстанның төрле шәһәрләрендә һәм район үзәкләрендә — Апаста, Бөгелмәдә, Әлмәттә һәм Түбән Камада тамашачылар белән очраштылар.

П. Чернов, Л. Квинихидзе, Б. Гринер, В. Фастович, Ә. Шакиров, Р. Бикчәнтәев, Х. Мингашудинова сәяхәттә йөреп кайтканнан соң Казанның Актерлар йортында фильм турында сөйләшү үткәрелде. Анда Татарстан культура министры Б. Гыйззатуллин, Ленин орденлы Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Р. Жиһаншина, язучылардан Н. Дәүли һәм Г. Ахунов катнаштылар.


Фильмның уңышы һәм кимчелекләре күрсәтелде. Соңыннан фильм режиссеры Л. Квинихидзе һәм Муса ролен башкаручы РСФСРның халык артисты П. Чернов республика белән танышуда туган хисләре белән уртаклаштылар.


— Без чын мәгънәсендә халык белән очраштык, жанлы кешеләрне, Жәлил өчен күз яше коючыларны күрдек,— диделәр алар.— Олы яшьтәге агайлар һәм апалар безгә килеп рәхмәт әйттеләр, кимчелекләргә көенделәр. Без колхоз председательләре, район, шәһәр житәкчеләре, нефть предприятиеләре житәкчеләре белән очраштык. Татарстанда сугыштан соң туган яңа шәһәрләрне, илнең чын хужаларыча уй-фикер йөртүче нефтьчеләрне күреп сокландык. Татарстанның иҗат союзлары белән «Ленфильм» арасында башланган элемтә Муса Жәлил турындагы фильмны тудыру белән генә тукталмаска, чын иҗади дуслыкка кадәр үсеп житәргә тиеш. Ә ул яңа әсәрләр иҗат иткәндә, республика ирешкән уңышларны зур һәм катлаулы образлар аша экранга чыгарганда гына була ала.

# АНДЫЙ ПАРТИЯ БАР!

АЛЕКСАНДР КЛЮЧАРЕВ
музыкасы

НУРИ АРСЛАНОВ
сүзләре






Тетрәүдән таулар да җимерелә,
Ярыла кыялар яшеннән.
Купты дау Россия җирендә —
Төште таҗ падиша башыннан.

Азатлык давылы айкады дәүләтне,
Әйттеләр: бездә юк андый көч сәләтле,
Дәүләткә кирәк бер лаеклы хөкемдар...
Шунда Ленин сүзе
Күкрәтте җир йөзен:
— Андый ПАРТИЯ бар!
Ул — Большевиклар партиясе!

Без Ленин байрагын илтәбез
Көрәштә югары, югары!
Яшибез иң матур илдә без —
Андый ил дөньяда юк әле.

Үрлибез биеккә — йолдызлар янына,
Юлыбыз бер генә — коммунизм ягына!
Бармы шул зур юлны кичәрлек батырлар?
Ленинча бергә без:
Андый көч бар! — дибез,—
Андый ПАРТИЯ бар!
Ул — Коммунистлар партиясе!

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210